# ЧИШМӘЛӘРНЕҢ КӨМЕШ ЧЫҢЫ



УДК 821 (470)
ББК 84 (2 Рос.Тат)
С88

**Суфияров, Ф.С.**
С88 Чишмәләрнең көмеш чыңы. Әдәби әсәрләр җыентыгы. – Уфа : Матбугат дөньясы, 2013. – 292 бит.
**ISBN 978-5-9613-0231-8**

**УДК 821 (470)**
**ББК 84 (2 Рос.Тат)**

**ISBN 978-5-9613-0231-8** © Ф.С. Суфияров, 2013



Татарстанның халык шагыйре Илдар Юзеев,
Яңавыл язучылар оешмасы
активистлары белән очрашу вакыты.
1997 ел. Яңавыл.

## ИҖАТ ДӘРТЕ СҮНМӘСЕН

Халыкның культура кимәле үсә барган саен аның әдәбияткә һәм сәнгатькә игътибары арткannan-арта бара.

Тормыш ничек кенә катлаулы, авыр булмасын, кешеләр әдәбиятсез, сәнгатьсез яши алмый. Тормышның бөтен кире якларын фаш итеп, ачып салган, шуның белән бергә изге той-гылар уяткан, яшәү дәрте биргән, кеше күңеленә хозурлык китергән бердәнбер чара — ул әдәбият. Шушы таләпне төп иҗат принципы итеп алып, язучылар, сәнгать әһелләре илһамлы иҗат эшенә тотына. Бу омтылыш урыннарда оештырылган әдәби берләшмәләрнең эшендә дә ачык күренә.

1970 елда район газетасы каршында әдәби түгәрәк төзелә, матур гына эшли башлый. Тәүдә Яңавыл районындагы яшь һәм башлап язучыларны берләштерә. Аларның шигырьләре, хикәяләре, җырлары район газетасында дөнья күрә. Иҗат эше җайга салына, әзме-күпме тәҗрибә туплана. Җанлылык сизелә, ышаныч арта. Аларга монда әдәбияткә, шигърияткә булган сөю иҗат белән яшәү теләге алып килә.

1980 елда Яңавыл шәһәрендә Башкортстан Язучылар союзы һәм Башкортстанның Комсомол өлкә Комитеты тарафыннан «Замандаш» әдәби берләшмәсе оештырыла. Бу әдәби берләшмә эшенә күрше районнардан Борай, Балтач, Тәтешле, Калтасы, Краснокама, Агыйдел, Нефтекама шәһәрендә иҗат иткән яшь каләм тибрәтүчеләр катнаша.

1992 елның ноябрь аенда безнең төньяк-көнбатыш регионында яшәүче һәм иҗат итүчеләр өчен зур вакыйга булды: Яңавыл шәһәрендә язучылар оешмасы төзелде. Бу исә яшь иҗат көчләренә ярдәм күрсәтү нияте белән эшләнде. Бу очракта, нинди генә кыенлыклар булса да, кулга алган иҗат эшебезне җанландырырга, төрләндерергә тиеш булабыз. Әдәбият шәхескә дә, заманга да йогынты ясый. Мең яшә — мең өйрән, дигән безнең бабайлар. Безгә күп нәрсәгә өйрәнергә, тир түгеп иҗат итәргә кала.

Оешманың төп максаты — башлап язучыларны берләштерү, аларның иҗатына юнәлеш бирү, вакытында ярдәм күрсәтү, талантлы яшьләрне тәрбияләп, әдәбият мәйданына чыгару.

Күренекле язучылар, шагыйрьләр белән очрашу-күрешү, аларның әдәби эшчәнлеге белән танышу башлап язучыларга иҗат осталыгына өйрәнергә мөмкинлек бирә.

Үз вакытында Башкортстанның халык шагыйрьләре Мостай Кәрим, Равил Бикбаев, Марат Кәримов, Тимер Йосыпов, шулай ук Сафуан Әлибаев, Рәдиф Тимершин, Рәшит Низамов, Мансаф Гыйләҗев, Риф Тойгынов, Дилә Булгакова белән очрашулар халык күңелендә онтылмас хатирәләр калдыра.

Башкортстан Язучылар берлеге белән Балтач, Краснокама, Тәтешле, Караидел, Борай, Яңавыл районнарында күчмә семинарлар үткәрелде. Аларда урындагы башлап язучыларның кульъязмаларын тикшереп, иҗатына бәя биреп, әдәбият мәйданына юл ачабыз. Болай эшләү яшь каләм тибрәтүчеләр күңелендә үз көченә ышаныч тудыра.

Язучылар оешмасында музыкаль-әдәби, юбилей, хәтер кичәләре, күренекле язучылар белән очрашулар еш үткәрелә. Төрле районнарда иҗат итүчеләрнең кульъязмаларын тикшереп, проза, поэзия секцияләренә тәкъдим итәбез. Барлыгы йөздән артык башлап

язучының кулъязмалары тикшерелде. Күбесе китап нәшриятына тапшырылды. Башланган иҗат эше нәтиҗәле булды, шушы вакыт эчендә күп кенә китаплар дөнья күрде.

Һәр районда иҗат белән кызыксынучы яшьләр бар. Нефтекамадагы «Инеш», Борайдагы «Яшь бөреләр», Тәтешледәге «Ак чишмә», Яңавылдагы «Замандаш», Балтачтагы «Танып дулкыннары» әдәби түгәрәкләренең роле зур.

Яңавыл язучылар оешмасы мәктәпләр белән тыгыз бәйләнештә тора. Укучылар иҗатына зур игътибар бирә, алар өчен күренекле язучылар белән очрашулар оештырабыз.

Иҗат оешмасының эше көннән-көн төрләнә, иҗат офыкларыбыз киңәя бара. Урындагы язучылар, шагыйрьләр әдәбият сөючеләр белән әледән-әле очрашып, иҗат җимешләре белән уртаклашалар, даими рәвештә урындагы, республикадагы гәзит-журнал битләрендә, радио, телевидение аша чыгышлар ясыйбыз.

Яңавыл язучылар оешмасы төзелүенә 20 ел булды. Иҗат дәрте сүнмәсен, яңа әдәби әсәрләр иҗат

итеп, әдәбият сөючеләрне тагын да куандырып яшәргә дигән уй-теләк белән җанып яшибез. «Замандаш» әдәби берләшмәсендә йөргән, үз каләмен шомарткан иптәшләрнең 10сы Башкортстан язучылар Союзының әгъзасы булып исәпләнә. Алар төрле яшьтә, төрле жанрда язалар. Үз әсәрләрендә бүгенге көннең проблемаларын ничек хәл итү, киләчәк турында уйланалар, җирнең сакчыл хуҗалары булырга чакыралар. Бер-берең белән аралашып, дусларыңа җыр-моң өләшеп, уй-кичерешләреңне уртаклашып яшәү — бүгенге көн таләбе ул.

Яңавыл районы хакимияте яшь язучыларны иҗади эшкә кызыксындыру максатында 1997 елда Гали Чокрый исемендәге премия оештырды. Ул иң яхшы дип табылган әдәби әсәрләрнең авторына ел саен бирелә. Менә шулай иҗади эшчәнлегебезнең нәтиҗәсен күреп, җимешләрен татып яшибез.

**Фәрит Суфияров,**
**шагыйрь.**
**Яңавыл язучылар оешмасының**
**җаваплы секретаре.**



**ФӘРИТ СУФИЯРОВ**

Фәрит Суфияр улы Суфияров Яңавыл районының Исәнбай авылында туып үскән. Урта мәктәпне тәмамлагач, Уфа финанс техникумында белем ала. Төрле оешмаларда финансист-икътисадчы булып эшли.

Педагогия институтын тәмамлап, район гәзитендә әдәби хезмәткәр, мәктәптә директор вазыйфаларын башкара.

1970 елдан Башкортстанның төньяк-көнбатышындагы яшь һәм башлап язучыларны туплаган «Замандаш» әдәби берләшмәсен җитәкли. Хәзерге көндә — Яңавыл язучылар оешмасының җаваплы секретаре.

Шигырьләре вакытлы матбугатта, коллектив җыентыкларда дөнья күрә. Радио-телевидениедә аның сүзләренә язылган җырларны популяр җырчылар башкара. Уннан артык китабы дөнья күрде.

Авторның иҗаты хакында аның якташы, шагыйрь, Башкортстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Рәдиф Тимершин менә нәрсәләр яза: «...Фәрит Суфияровның шигъри әсәрләре табигатьнең үзе кебек кырыс та, мәрхәмәтле дә. Әйткәндәй, аның байтак

шигырьләренең җирлеге, үзәге — табигать күренешләре, табигать тудырган хикмәтләр. Әмма шагыйрьнең максаты — һәркемгә дә таныш күренешләрне шигъри юлга салып тасвирлау гына түгел: я бу күренешләр — аның тойгыларын, рухи халәтен, булмышын ачыклаучы чара, я әдип теге яки бу табигать күренешен тасвирлап, үзенчә, башкалар әйтмәгән фикер бәян итә.

Үзе дә олы тормыш мәктәбе үткән Фәрит Суфияровның лирик геройлары — җир эшен, игенче һөнәрен үз иткән табигать балалары, хезмәт, намус, гаделлек төшенчәләре, яшәү яме һәм күңел матурлыгына мәдхия — иҗатының асылын билгели». Республикабыз әдәбиятын һәм сәнгатен үстерүдә күрсәткән хезмәтләре өчен шагыйрь Фәрит Суфияров Башкортстан Республикасының Мактау грамотасына лаек булды, аңа «Башкортстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелде. Ул — Гали Чокрый, Әнгам Атнабаев, Фатыйх Кәрим исемендәге премияләр лауреаты.

## ИЛГӘ БУЛГАН СӨЮЕМ

Ил өстенә давыл үрләсә дә,
Яшен уйнап, болыт килсә дә
Шикләндерә, куркуга да сала,
Күңел түрләрендә үлчәнә.

Илгә булган кайнар сөюемне,
Горурлану хисен белдерәм.
Эчәр суым, ашар икмәк биргән,
Туып үскән җирем, бер генәм.

Бәрәкәтле туфрагында шытып,
Тамырланып үскән бер гөлең.
Илгә фаҗигаләр янап торса,
Аянычлы узар гомерем.

Уңышларың артса куанырмын,
Үр яуласаң, ныгыр канатым.
Кырга сыймас шатлыкларым ташып,
Мин дөньяга туам кабаттан.

Иҗат — хезмәт белән бизәләсең,
Тыныч атсын, илем, таңнарың.
Җир тетрәп, сулар болганмаса,
Яшәү яме синдә табармын.

## ҖЫРЛАР КАЛСЫН

Тауга менсәм, тау буласым килә,
Моңы булып ургыйм чишмәнең.
Тәрәзәмне ачып, күккә карыйм,
Йолдыз сыман балкыйм кичләрен.

Зәңгәр күлнең мин камышы булам,
Дулкыннарын ярда кочармын.
Күксел кыяларның шоңкары мин,
Офыклардан биек очармын.

Яз чәчәге умырзая булам,
Җиргә якты бизәк өстәрмен.
Кышы, язы, җәе, көзе булам,
Күз камышкай төрле төстәмен.

Кешеләргә шатлыгымны бирәм,
Мирас итеп барын өләшәм.
Кардәшләрем кебек якын күреп,
Сәлам юллап, сезгә эндәшәм.

Юлаучыга юлдаш булып барам,
Маяк тезеп чыгам юлларга.
Бар көчемне җыеп, оран салам,
Җырлар калсын ерак елларга.

# ӨЛГЕРЕРГӘ КИРӘК

Мин кунакка килдем, дөнья, сиңа,
Мәңгелеккә түгел, бик азга.
Көнем якты, шуңа рәхмәтлемен,
Күкрәсен җан сусаган назга.

Хыялларым чынга ашса икән,
Өметләрем бары аклансын.
Кара болыт булып кайгы-хәсрәт,
Күңел күкләремне япмасын.

Игелеген күрим җир-суымның,
Өстәлемдә торсын икмәгем.
Үкендермәс, уфтандырмас бер дә,
Киләчәгем, минем үткәнем.

Еллар имин генә булсын димен,
Илһам бирсен иҗат җимешем.
Бәхет-шатлыгымны юллап алам,
Югалтмадым тияр өлешен.

Мин тормышны матурларга тудым,
Җавап тотам барсы өчен дә.
Вакыт чикле, өлгерергә кирәк,
Кыска гына гомер эчендә.

## ЗАМАН ШАУКЫМЫ

Заман шау-шуында читләп үтми,
Җаннарыма килеп кагыла.
Сары ялкын алды йөрәгемне,
Сүнмәс утлар булып кабына.

Бүген чик буенда җир тетрәде,
Дәрья чыккан ташып ярыннан.
Аянычлы хәбәр ишетелә,
Илем, синең төрле ягыңнан.

Кузбасс шахтерлары дәгъвалаша,
Митингка чыккан җыелып.
Литва халкы забастовка эшли,
Хәтеремнән китми җуелып.

Рейстан самолетлар кайтмый,
Диңгезләрдә кораб югала.
Гаепсезләр акланмыйча кала,
Гамьсезләр гел алга юл ала.

Нинди хәл бу, кая түбән төштек,
Без Ватанның данын сатмаек.
Милләтчеләр җирне бүлгән чакта,
Бердәмлекне илдә саклаек.

Еракларда калган шат көннәрнең,
Кайтавазы әллә чакыра.
Матур киләчәккә без ышанып,
Юлдан язып чыктык чатына.
Сабыр була белсәк чак кына.

## ШӨКЕР ИТӘМ

Якты көнгә иртән күзне ачсам,
Куанычлы хәбәр көтәмен.
Күкләр аяз, илем имин булса,
Сагышланмыйм, шөкер итәмен.

Кешеләрнең шат йөзләрен күрсәм,
Сәлам биреп, дәшеп үтәмен.
Яшәвемә бик канәгать булып,
Якты хисләр саклап йөртәмен.

Хезмәт вахтасына бастым исә,
Җиңү байрагымны эләмен.
Максатыма димәк ирешәмен,
Ышанычны аклый беләмен.

Кыйбылам бар, күз уңымда тотам,
Уй-теләгем бергә юнәлде.
Тормыш кануныма төшенәмен,
Ычкынмады кулда йөгәне.

Игелекле эшләр кылырга дим,
Гомер юлын бизәп үтәмен.
Йөгереп узган вакыт агышында,
Үкенмәмен, шөкер итәмен.

## БАРЫСЫ ДА КИРӘК КЕШЕГӘ

Табигатьтә адәм балалары...
Иркәләнә анда, назлана.
Җирдән башка һич тә яши алмам,
Бер мизгелгә, хәтта азга да.
Йөрим, дисәм, борма юллары бар,
Менәм, дисәм, биек таулары.
Хуш ис бөрки яшел тугайлары,
Сандугачлар кунган таллары.
Тормыш кебек үзе шаулы бит ул,
Ургып ага зәңгәр дәрьясы.
Һәркемгә дә җир мирасын саклый,
Куанычлы якты дөньясы.
Кыр өстендә арыш серкә очыра.
Агачларда яфрак алкышы.
Яңа көннәр туа шатлык белән,
Офыкларда таңнар балкышы.
Кояш көлеп караса да рәхәт,
Йөрәк тоя, барын төшенә.
Яуган яңгыр, шыткан үләне дә,
Барысы да кирәк кешегә.

# МОҢ ЧИШМӘСЕ ТЫНМАС

*Мөслим Могамаев истәлегенә*

Бу дөньяга син тугансың көлеп кенә,
Язмышыңның ни кыласын белеп
кенә.

Табигать бетмәс хәзинә бүләк иткән,
Моң чишмәсе синең, Мөслим,
чыңлый күптән.

Кеше күңелен җыр-моң белән
сугарасың,
Боз булып каткан зарларны
чыгарасың.

Куанычлар, сөенечләр өләшәсең,
Пәйгәмбәр затына син
тиңләшәсең.

Халык алкышына күмде сине
күреп,
Асыл гөлләр, такыялар бирде үреп.

Җыр-моң белән килер язларны
тизләтәсең,
Һәркемнең йөрәк яраларын
төзәтәсең.

Синең моң-авазың сихри көчкә ия,
Олы хөрмәт яулап алдың, халык сөя.

Халыкка игелек күрсәтеп яшисең,
Дөнья аренасына чыктың
яшьли син.

Аяныч еллар, айлар сизелми үтә,
Һәркем иҗат җимешләрен
авыз итә.

Бу заманга син тугансың ич
данларга,
Үзеңә һәйкәл куярлык көч табарга.

## МӨМКИН БУЛСА

Узган юллар артта калган инде,
Йөргән сукмак безнең суынган.
Аянычлы булса аерылулар,
Үкендерә икән соңыннан.
Безнең арабызда ята еллар,
Бер-беребездән хәзер ераклар.
Тик күңелләр барбер тынычланмый,
Очрашырга дигән теләк бар.
Очрашсак та, нигә сер бирмибез?
Таш бәгырьле әллә кешебез?
Керфекләрне яшькә манчыйбыз,
Кайвакытта сабый төслебез.
Нигә кирәк шулай газапларга?
Күңел сынык, йөрәк яралы.
Еллар үткән саен һаман ныграк
Ерагайта безнең араны.
Үткәннәрне башка кабатламыйк,
Мөмкин булса, әгәр аңлашу.
Гомер узган саен уйландыра,
Булмас иде болай ямансу...

## ДАЛА МОҢЫ

Күккә ашкан таулар да юк,
Урман да юк, шаулаган.
Җилләр уйнап йөргән чакта,
Чал кылганнар чыңлаган.
Офыклар ерак күренә,
Күз карашларын йота.
Зәңгәр күк астында тынып,
Дала җәерәп ята.
Сулышларым иркенәйде,
Тоям дала һавасын.
Иркенлектә, чиксезлектә,
Килә минем каласым.
Дала моңын тыңлый сыман,
Бормалы озын юллар.
Кай якларга илтә икән
Җырларын аккан сулар?

## ЕЛМАЮЫҢ КАЛСЫН

Матур яшьлегемне җырга кушып,
Колак салсаң әйткән сүземә.
Син көлгәндә дөнья балкып китсен,
Якты нурлар чыксын йөзеңә.
Елмаюың күз алдымда кала,
Шат булуың сиңа килешә.
Иңнәреңә төшсен кара чәчең,
Бер мизгелгә калсын минемчә.
Җирнең яме арта гөлләр шытса,
Яшь бөреләр күкрәп тишелсә.
Кыңгыраулар сыман чыңлап кала,
Көлгән тавышларың ишетелсә.
Уйларыма якты нур бөркисең,
Томан пәрдәләрен тараттың.
Карашымны минем үзеңә алдың,
Назлы кошым, сине яраттым.
Моңсуланма, елмаеп тор һәрчак,
Мин бит мохтаҗ синең назыңа.
Ир-егетнең канатлары талмас,
Шөһрәт кирәк аңа аз гына.

## ВАКЫТ САГЫНДА ТОРА

Күктә йолдызлар атыла,
Аккан чишмәләр кибә.
Гел үзгәреп тора дөнья,
Нишләсен, йөрәк күнә.

Кеше гомерендә яшьнәп,
Шәфәкъттай балкып сүнә.
Җирнең назлы чәчәкләре
Вакытсыз кайчак шиңә.

Таш ватыла, таулар чүгә —
Аянычлы бу дөнья.
Юксындыра, шомландыра,
Күңелемә шик куя.

Мәңгелек булып калырга
И кемнәр дәгъва кыла?
Кичен шаулаган ташулар
Иртәсен тынып кала.

Юллар кайтмый үткәннәргә,
Узылган ерак ара.
Елларны, чорларны санап,
Вакыт сагында тора.

## ДУСЛАРЫМ ТАБЫН КОРА

Дуслар җыелышкан мәлне,
Хисләр таша күңелдә.
Гармун чыңлый, моң агыла,
Табын җырга күмелә.

Дуслар кайткан — очраштык без,
Ерак юлларны үтеп.
Сагынып, зарыгып, күптән
Күрешү көнен көттек.

Табын яме, күрке аның
Йөзебездә чагыла.
Бергә булган вакытларны
Күңел һаман сагына.

Төчеләнмим, буш сүз түгел,
Сез мактаулы, хөрмәтле.
Олы җанлы, игелекле,
Зурладыгыз хезмәтне.

Тормыш йөге иңебездә,
Ил хәстәре җитәрлек.
Сезнең хакка мин тост әйтәм,
Дуслар, ягез, күтәрик!

## ДӨНЬЯ ЧИКЛӘРЕ

Күп илләрдә, күп җирләрдә булдым,
Аяк бастым диңгез читенә.
Бәхәсләшмим, дөнья чиксез диеп,
Телдә генә болай әйтелә.
Дәрья сулары да чиксез түгел,
Дулкыннарын ярга кагасың.
Космик кораблар да очып үтә
Йолдыз белән йолдыз арасын.
Күккә ашып торган биек таулар,
Диңгез тирәнлеге үлчәнә.
Билгеләнә җиһан киңлекләре —
Кеше кулы белән эшләнә.
Элек кенә олы сер ителгән,
Вакыт җиткәч, ача бикләрен.
Бөтен дөнья үлчәүләргә сыя,
Хыял гына белми чикләрен.



2 17

## БЕР СИН ГЕНӘ ТҮГЕЛ

Бу дөньяда бер син генә түгел,
Бер син генә күктән төшмәгән.
Син түгелсең ташка җан өрүче,
Күк йөзеннән йолдыз чүпләгән.

Кыланышың, ашкынуың хәтәр,
Ничек чыгалырсың чигенә.
Өч йөз алтмыш градуска борган,
Җир кендегеме соң син генә.

Яшен суккан имән агачы күк,
Урын тапмый кинәт чатныйсың.
Тау кадәрле ихтирамын күргән,
Дусларыңны читләп атлыйсың.

Иптәшләрең сиңа зур аяныч,
Артык шашма, артык кабынма.
Кеше кызык, сизмичә дә кала,
Атлап барган юлда абына.

Йөргән юлларыбыз уртак булды,
Чишмә безгә суын эчерде.
Дуслык хисе берүк сүрелмәсен,
Күңел йөгерек авыр кичерде.

## СОҢГЫ ЮЛГА ОЗАТА

Соңгы юлга китәр вакыт җитсә,
Исәп-хисап тота һәр кеше.
Гомерендә ниләр башкарды соң,
Уңышлымы булган бар эше.

Хезмәт юлы аның кайда үткән,
Җимешләрен җыйган мулданмы.
Кайгы-хәсрәт күреп яшәгәнме,
Шатлык-куанычы булганмы.

Аянычлы хәлгә юлыкканмы,
Игелекле эшләр кылганмы.
Бу чак җиткәч бәһалана кеше,
Булдыксызмы әллә уңганмы.

Тормышка ямь өстәп яшәгәнме,
Мохтаҗлыкта гомер кичкәнме.
Язмыш каһәренә юлыкканмы,
Утка кергән, суга төшкәнме.

Кырын эшләр кылган кеше булса,
Бәгырьләргә тиеп сызлата.
Кайгысы да, шатлыгы да бергә,
Соңгы юлга бар да озата.

# ХӘЕРНИСА ӘБИ КЫЗЫ

Юкә балын мактап чәй эчәләр,
Хәерниса әби табында.
Ахирәтләр бергә җыйнаулашкач,
Бәхәс кузгаттылар тагын да.

Ирдән кайткан быел күпме хатын,
Ничәмә кыз иргә чыкмады.
Ак каеннар шаулап яфрак коя,
Көз аеның ямьле чаклары.

Хәерниса әби кызын мактый,
Хаты килгән икән Бакудан.
Бу кияве бәхет китермәгән,
Зәгыйферәк булган акылдан.

Күрше авылдан ирен ташлап кайткач,
Күпләр имеш аны сораган.
Бер ул гына түгел, диде карчык,
Бәхетләрен шулай сынаган.

Нинди җилләр аны ташлаган соң,
Иргә чыккан тагын Кизелдә.
Бу кияве эчеп артык ваксый,
Мәрхәмәт юк икән күзендә.

Стәрледән килде соңгы хаты,
Әни сине һичбер йөдәтмим.
Бу кияվең белән матур яшим,
Акылга мин үзем өйрәтәм.

Хәерниса әби кыстый-кыстый,
Майлап, баллап чәен эчерә.
Яшь чагымда чыктым өч иргә ди,
Хәтмулласын искә төшерә.



# ГӨЛ МИРҺАДИ

Мин, Гөл Мирһади (Гөлнара Шәймөхәммәтова), Балтач районы Түбән Карыш авылында туып үстем. 2001 елдан район һәм республика матбугатында шигырьләрем һәм проза әсәрләрем басыла. 2006 елда «Китап» нәшриятында «Алмалы үләннәрем» исемле шигырьләр һәм җырлар җыентыгым дөнья күрде. 2011 елдан БР Язучылар берлеге әгъзасымын. Әлеге вакытта Иске Балтач авылында яшим, «Балтач таңнары» гәзите редакциясендә эшлим.

## БЕЛСӘҢ ИКӘН

*«Ындыр артыннан җыйган җиләк вареньесы белән чәй эчерәм әле мин сине, кызым»*

*Әлфия апаның сүзләре.*

Заман алга атлый, дибез.
Атламый! Чабып бара!
Азга гына арбасыннан
Син төшеп калып кара!
Артта калырга ярамый,
Оныталар, таптыйлар.
Заманча кыланып кына
«Отстой» диеп атыйлар...
Компьютерлар, машиналар,
Телефон һәм Интернет...
Яңалыклар башка сыймый,
Уйлап акыл китерлек.
Басмакларга басып кына
Майтарабыз зур эшләр,
Виртуаль дөньядан гына
Табабыз ярлар, ишләр...
Шул кадәр алга киткәнбез:
Айда яшәргә исәп,
Тагын алга омтылабыз,
Тизлекнең зурын өстәп...
...Авылыма кайттым бүген.
Көзгә аяк басканнар.
Ашыгып уңыш җыелган,
Тынып калган бакчалар.
Ындыр табагында тынлык.
Ашлык та юк, кеше дә.
Кайда соң «исергән» чаклар
Курган бодай исенә?

Ындыр табагы гөрләми.
Туктаган тегермән дә.
Карт-коры риза икмәкне
Кибеткә китергәнгә.
Ындыр артында да тынлык.
Мал ашатмый балалар.
Таллар гына талгын җилгә
Шыбырдашып алалар.
Шыбырдашып алалар да
Тыналар мине көтеп.
Ә мин заман белән бергә
Моннан барам тик үтеп...
Без алга барган кебекбез,
Авыл тәгәри артка.
Мин дә газиз авылыма
Әйләнеп барам ятка...
Сыер саклап, качыш уйнап,
Такырлаткан урыннар
Печәнлек ителгән хәзер,
Охшап калган болынга.
«Ындыр артта үскән җиләк.
Авыз ит, кызым», — диден.
Бу төбәкнең газизлеген
Син аны белә идең.
Маллар да аз. Балалар да
Хәзер уйнамый качыш.
Дөнья көтәрлек яшьләр дә
Калага бетте качып.
Кыргый урман-болынлыкка
Авыл әйләнгән чакта,
Белсәң икән: замананың
«Алга»сы кайсы якта?

* * *

Үткәннәр — бөгәрләп бәргән
Кәгазь хәлендә әле.
Тимә! Яндырма аларны!
Калсыннар шулай. Яме?!

Буш өмет — синең бүләгең,
Матур төш, матур хыял.
Төштә булса да бәхетле
Булудан кемнәр тыяр?

Берни дә булмады кебек
Икебезнең арада.
Юк телгә алыр истәлек,
Юк киләчәк — карарга.

Юк сагынырлык хисләр дә,
— Берни булмаган кебек.
Тик шул минутны тагын бер
Яшисе килә үлеп!

Аерым бер юл — йөрәктә
«Ярамый» дип язылган.
Ә күпме дәрт алам синең
Кыска гына назыңнан...

## БӘЛКИ...

Бүген бар без, иртәгә — юк.
Гомер бер мизгел генә.
Нигә гаепләргә сине?
Ник мина үзелергә?
Белмибез күкләр астында
Ничә сәгать яшисен.
Килми кыска гомеркәйдә
Ялгызлыктан өшисем.
Килми сарыф итәсем дә
Нәфрәткә минутларны,
Алып ташлыйм йөрәгемнән
Бер кыйммәтсез утларны.
Онытабыз фанилыгын,
Бу дөньяда без — кунак,
Буш уйлар белән янабыз,
Бетерми төптән уйлап.
Әй юкларга әрнибез дә
Йөрәк көчен түгәбез,
Кадерле гомер узганын
Соңлап кына күрәбез.
Бер көнлек бу дөньяларның
Белмибез шул кадерен,
Аңныйбыз бик азга гына
Күреп дус, сөйгән, туганның,
Якыннарның каберен...
Аңныйбыз бик азга гына!
Дөнья баса үкчәгә,
Безнең тормыш корылган бит
Мәңге җитмәс акчага...
Тукта, җаным! Шул мизгелне
Тойсын йөрәкләр бергә!

Кеше сөелеп яшәргә
Килгән бу матур җиргә!
Кичер, булса гөнаһларым,
Гаепләмә, үртәмә.
Туктат дөнья мәшәкатен,
Шул минутта иркәлә!
Соңгы тапкыр кочагыңа
Алган кебек иркәлә...
Бүген яшим. Бәлки, иркәм,
Мин булмамын иртәгә.

## ОЗЫН

Төннәр озын. Качкан йокыларны
Булмаганда кире кайтарып.
Үрсәләнәм, йолкам мендәремне,
Булмый йоклап, булмый җай табып.

Чакырусыз уйлар өермәсе
Башны тубал итә. Куамын.
Бөтен җиһан мине ташлап йоклый,
Ә мин көтәм таңның туганын.

Көннәр озын. Ике кулың эшсез,
Үзең өйдә ялгыз калганда.
Килер кешең көткән сукмакларга
Һәр көн сылап карлар салганда.

Юллар озын. Җәяү атлаганда
Машиналар үтсә туктамый.
Арысаң да, рәнҗеп еласаң да,
Юк бер чараң алга атламый...

Зая үткән ялгыз юлларыңнан,
Көннәр-төннәреңнән бизгәндә,
Сәгатьләрнең йөрмәс укларына
Нәфрәт белән багып түзгәндә, –

Гомер озын. Туйсаң яшәп җирдә,
Һәм канатсыз калса хыялың.
Яздым, сыздым. Тагын язып сыздым:
Төнне кыскартырга уйладым...

## ГОМЕР ҮТӘ ИКЕ АРАДА

Каерылып карыйм узган саен:
Туган йортым ындыр артында.
Мин чит кеше күптән, миңа анда
Юллар ябык инде кайтырга.

Каерылып карыйм яшел өйгә,
Кызыл түбәсенә калайдан.
Мең кадерле мунча-абзарларның
Такталары күптән карайган.

Картайганнар инде талларым да,
Кәүсәләрен булмый кочаклап.
Бөдрә таллар арасында гына
Адашып ла калды кыз чаклар.

Казлар саклап, маллар эзләп йөргән
Сукмакларны кемнәр сагынмас?!
Кемнәр кабатланмас балачакның
Тапсыз бәхетенә табынмас?!

Каерылып карап узар хәлдә
Күпләребез туган йортларга,
Елына бер өзлеп сагынып кайтыр
Хәлдә генә туган якларга.

Кычытканнар баскан тыкрыкларга,
Буш өйләргә карап әрнибез,
Тып-тын калган авыл урамыннан
Хатирәләр барлап йөрибез.

Йөрибез дә таралышабыз шул;
Туган җирдән яхшы торган җир.
Тагын бер ел кайтыр көнен көткән
Балаларга ходай түзем бир...

Кызларыңны гаеп итеп булмый:
Ир нигезен алар үз итә.
Бәхет эзләп асыл егетләрең
Чит җирләргә, авылым, ник китә?

Гаеп итеп булмый замананы,
Булган әлегедән авыры,
Күпме михнәт күтәрергә җиткән
Авылдашларымның сабыры.

Нигә әле бигрәк иркәләндек?
Ни булса да үрелеп хәмергә,
Өйрәндек бит эшләми яшәргә
Хәзер булып кына әзергә.

Ата-баба атлар җигеп сөргән
Күпме җирләр кысыр хәлендә,
Онытып барабыз түгелме соң
Мичтә пешкән икмәк тәмен дә?

Җир уллары, җир кызлары бит без,
Авыл балалары — онытмыйк,
Эзсез югалырбыз, туган җирдә
Калган тамырларны корытмыйк.

Күңел ачу өчен генә түгел,
Кайтыйк эшләр башлар өчен дә,
Авыл яшәр, күтәр әле безне
Авылдашлар булса көчендә.

Чит җирләрдә дан казанган ирләр
Ахырда бит кайта шул җиргә.
Бәхетлеләр генә тәүге кабат
Сулыш алган җирдә җан бирә.

Кайтып узган саен каерылып
Карап узамындыр артына,
Су коенып үскән Юкәлемә,
Һәм зиратка... уйлап анда яткан
Якын кешеләрем хакында.

Теләп узам шунда кайтып кына
Ятсам иде диеп азактан.
Туган авыл безне бер әйләнеп
Кайтыр өчен генә озаткан.

Туган җирләр якын торган җирдән,
Гомер үтә ике арада,
Әлдә барсың әле, туган йортым,
Каерылып кына карарга...

* * *

Сагындым, сагындым, сагындым!
Карашың китми күз алдымнан.
Җибәрмәс идем бит үзеңне
Бер генә минутка янымнан!

Сагындым, сагындым, сагындым!
Назыңны исемә төшерәм.
Шул чакның рәхәтен, ләззәтен
Кабаттан, кабаттан кичерәм...

Кабатлыйм эчемнән: сагындым!
Түзәмен күңелем тулса да.
Кил инде яныма бик кыска
Кадерле минутка булса да.

Сагындым, сагындым, сөйгәнем!
Күзләрең назына сусадым.
Сусыз гөл, кояшсыз иртәгә,
Йолдызсыз төннәргә ошадым.

... Кагылдым, сарылдым, кабындым...
Бәхеткә бер мизгел җитәдер.
Сагынып, сагынып, сагынып
Күңел шул ләззәтне көтәдер.



# НӘФИСӘ ХӘБИБДИЯРОВА

Мин, Нәфисә Мәүләви кызы Хәбибдиярова, яшьлек елларымнан башлап гомеремне иҗатка багышладым. Гомумән һәр каләм иясенең иҗаттан тыш төп эше була, ә мин — тегүче. Ә инде үземчә мин тегүче һөнәрен дә нәкъ шагыйрь, рәссам кебек үк матурлык тудыручы, дип аңлыйм. Шулай итеп гомеремнең бик күп, нәкъ өч дистәсен мин тегүче эшенә багышладым. Агачны яфрак, кешене чүпрәк матурлый, дигәндәй, мин дә нәкъ шул юнәлештә кешеләргә хезмәт иттем. Шул еллар эчендә кулым машинкада булса, күңелемнән шигъри юллар түгелә торды. Мин аларны бары ак кәгазьгә күчереп баручы гына.

Ә инде тумышым белән мин Бадрак авылына күрше генә яшеллек эченә чумып утырган кечкенә Тукай авылында туганмын.

Язмышым кечкенәдән Тукай язмышына да охшап куйган чаклары булды, чөнки мин күбрәк дәү әтием белән дәү әнием карамагында үстем. Олы кешеләр кул астында үскәнгәдер, күңелем балачактан ук бик нечкә булды, аз гына кагылсалар да түгелергә тора идем. Дәү әтиемнең алма бакчасында мин алмагач чәчәгенең исләрен,

кып-кызыл алмаларының тәмен татып үстем. Тәүге шигырьләрем дә шушы бакчада туды, дисәм хата булмас. Үсә-үсә шушы халәтем мине чын шигърият иленә алып килде. Күңелемә җыйган сагыш-моңнарымны, югалту-табышларымны шигырьләремә салдым.

Ә инде Бадрак авылында хезмәт түккән елларымда тәүге мәхәббәтемне, бәхетемне очратып, оя кордык. Тулы гаиләдә тормыш иптәшем Фирдәвес белән ике улымны, кызымны үстереп, олы тормыш юлына чыгардык. Бүген инде мин илле биш яшемдә күптән стажлы нәнәй.

Үткән 2011 ел минем өчен бик истәлекле ел булып күңелемдә калды, чөнки минем илле биш яшьлек юбилеем булып үтте. Шулай итеп, шушы бәйрәмдә мин дусларымны барладым, дип уйлыйм.

Ә инде иҗадыма килгәндә, мин хәтсез еллар язучылар союзында әгъза булып торам. Иҗат җимешләрем дә байтак җыелды инде. Баштагы елларда шигырьләрем «Тәлгәш», «Салават күпере» кебек җыентыкларда дөнья күрсә, тора-бара «Чәчәк бураны», «Янар гөлем», — дигән исемнәрдә

күләмле аерым шигырь китаплары булып дөнья күрде. Алай гына да түгел, китап нәшриятында тагын бер «Җиде тылсым» исемле шигырь китабым чират көтеп ята.

Инде бер аягым белән көзләремдә басып торсам да, йөрәк тулы хисләр йөртәм. Гомерем булса хыяллар зурдан, җырчы чишмә булып түгелергә дә түгелергә әле исәбем.

## БЫЛТЫРГЫ КАР

Ак урамнан ыжгыр җилләр
Йөгерә дә йөгерә.
Кичә яуган йомшак карга
Кызыл миләш сибелә.

Кичә яуган ап-ак карлар,
Инде былтыргы карлар.
Кичә генә без пар идек,
Бүген без ялгыз парлар.

Елгыр җилләргә ияреп,
Кайларга киттек инде.
Эзләреңдә — былтыргы кар,
Әйтер сүз бар — көт мине.

Яннарыңа барыр идем,
Рөхсәт итми горурлык.
Эзең миләш, миләштә кар,
Чара юк юл ярырлык.

«Кичер», диеп бер эндәшсәң,
Куркытмас бозлы буран.
Эзләреңә урамнарда
Былтыргы карлар тулган.

Син дә газапланыр булсаң —
Атла кичәге кардан.
«Сөю юк», — дию ялган ул,
Кил, әйтер сүзем калган.

## СӨЮ КАЛЫР

Йөрәгемдә учак кабызалмыйм,
Җитми җылың, назың, утларың.
Шәфәкъләрдән алсам сагыш сарыр,
Назы ялкын булмас ятларның.

Сүнә инде менә, сүнә инде,
Син кабызган сөю учагы.
Усал кыш та: «Ялгыз калдың», —
диеп,
Үчекләшеп җәя кочагын.

Нишләргә соң? Әллә ятлар сиңа,
Үз булдымы, әйтче, нишләдең?
Озын көзләр буе җаным ялгыз,
Көзләргә дә серем чишмәдем.

Килер кышның салкын капкасыннан,
Көтү дигән хәят хисендә.
Сине уйлап сынландырсам әгәр,
Сөю калыр бөек көчендә.

## ГАФУ ҮТЕНСӘҢ

Сау бул инде, җаным, хуш, үкенмә,
Хыялыма кайтам мин синнән.
Үзем белән алам сөюемне,
Иң беренче кавышкан төннән.

Бер сөюсез мин калдырам сине,
Ялгызлыкта җаның изалап.
Сөю кадеренә төшенерсең,
Соң булса да җаның язалап.

Үкенечтән яну ачыларын,
Яну газапларын кичерсәң.
Мин бит әле кабат хыялымнан,
Кайта алам, гафу үтенсәң.

## ТАНЫМАДЫҢ

Йөз ел инде сине күргәнем юк.
Беләсеңме сине сагындым.
Сине күрер өчен күктән,
Болыт булып агылдым.

Яңгыр булып түгелдем дә,
Тамдым керфекләреңә.
Күзләреңнән тамчы булып,
Үпмәдем тиккә генә.

Мин идем бит, мин идем бит,
Ә син берни сизмәдең.
Елап-җырлап яңгыр яуды,
Юеш иде күзләрең.

Йөз ел сине күргәнем юк,
Күрдең, тик танымадың.
Үксеп яңгырлар яуганда,
Тамчы булып сарылдым...

# АЛДАТМА, ЯЗ

Яз ялкыны бөтерелә җанда,
Гөрләвектә кояш коена.
Ә йөрәккә соңгы сөю хисе,
Язда түгел — көздә уелган.

Бу язым да көзге моңнарымны,
Тартып алмак булып кылана.
Миңа инде көзге ялкын сердәш
— Яз, алдатма мине, сынама.

Бүген шарлап аккан гөрләвекләр,
Тынып калыр килер таңнарда.
Җанны айкап аккан кар сулары,
Әллә кайда китәр салларда.

Соңгы сөю җанны кузландырган,
Инде язлар сезгә табынмам.
Сөюемнең хисе — көзге моңда,
Юк, язларда бүген кабынмам.



3 17

## ҖӘЙНЕҢ СОҢГЫ СУЛЫШЫ

Җәйләрнең соңгы сулышы,
Сизелә чәчкә-гөлләрдә.
Кура җиләк тәме килә,
Әкрен искән җилләрдә.

Көз белән җәй кавышамы,
Казлар моңсу тавышлы.
Саргайган бәбкә үләне,
Су буйлары сагышлы.

Алсу нурга җир коенган.
Казлар канат кагына.
Каз канатлары манчылды,
Шәфәкъ нең алларына.

Шәфәкъ алларында икән,
Җәйнең соңгы сулышы.
...Таң атканда сары көзләр,
Моңсулыктан тулышты.

# КӨЗ КОЧАГЫ

Ефәкләрдән тукылганмы
Каеннарның сары шәле.
Күкләр-җирләр моңда әле.
Табигатьнең моңсу чагы.

Дулкынланды ак каеннар,
Ефәкләрен җил очыргач.
Офыкларда тибрәлде моң,
Нурсыз калды  шәрә агач.

Офыкларда — сары шәфәкъ,
Ялкынлана көз учагы.
Яфрак яңгырларын коя,
Учагына көз кочагы.

Ефәкләрен сагыныр да,
Җилдә елар моңсу агач.
Их, ямансу шул чакларда —
Көзге шәфәкъ сүнеп калгач.



3 •

## БУРАН КӨТКӘНДӘ

Менә-менә уяныырлар кебек,
Йокымсырап калган бураннар.
Әле тынлык. Зыкы яктысында,
Ак нур сирпеп көлә урамнар.

Бу гүзәллек — кышның яктылыгы,
Ак нурлары җанга ятышлы.
Зыкы уйный. Сихри балкыш нуры —
Кышның җаны, кышның нәкышы.

Оныттырды инде көз сагышын,
Ак бәсенә төреп кыш төсе.
Ә күңелдә ак бураннар җыры —
Мәңге сүнмәс моңның бер хисе.

Уйный зыкы — якты нурларында,
Кышкы әкият сере саклана.
Бураннарга чишеләсе серне,
Табигатьтә күреп сокланам.

Ә бураннар килеп җитәр кебек,
Ерак калган яшьлек эзеннән.
Көртләр ярып, бер йөгерер идем,
Карлар булса булыр тиземнән.

## НАЗ БИТ ҮЗЕМДӘ

Пар мендәрдә ап-ак ромашкалар,
Нәкышларда бардыр бер сере.
Чәчкәйләрем тузып таҗларына,
Бер бәхеттән икәү исердек.

Сайрашмады кошлар: яуды яңгыр,
Безнең бәхет өчен сөенеп.
Җир кызының янып сөйгәненнән,
Көнләшмәгез берүк көенеп.

Чәчләремнән аңкыр гөлләр гаме,
Төшләремә кереп йөдәтер.
Гомерем буе ак ромашка сере,
Җанны назлар, җанны эретер.

Пар мендәрдә бизәк ап-ак таҗлар,
Чәчләремнән сыйпап йоклатты.
Ә таңнарда назлап-сөеп кенә,
Уятты да җанны юатты.

Шуңа, ахры, ап-ак ромашканы,
Җаным сөя җәй дә, көзен дә.
Таҗлар өзмәм «сөя — сөйми», — диеп,
Сөю тулы наз бит үземдә.



# КАҺИМ ӘҮХӘТОВ

Мин, Әүхәтов Каһим Әүхәт улы, Башкортстанның Тәтешле районы Иске Күрдем авылында 1932нче елның 2нче гыйнварында колхозчы гаиләсендә туганмын. Үземнең дә күпчелек елларым колхозда эшләп үтте. Шуларның 13 елын бригадир, 10 елын ферма мөдире булып эшләдем. Шул вакытларда әдәбият белән дә мавыктым һәм язмаларым гәзит-журналларда басыла торды. Бүген дөнья күргән алты шигырь җыентыгым бар. Яңавыл шәһәрендә «Замандаш»та даими катнашып киләм. 2001нче елда Тәтешле район үзәгендә оештырылган «Ак чишмә» язучылар оешмасының, туган авылым Күрдем авыл китапханәсендә оештырылган шигърият сөючеләрнең «Өметле каләм» клубының актив әгъзасымын.

## СЫНЫЙЛАР

Бу дөньяга килгән минуттан ук
Адәм затын сынау башлана.
Тикшерәләр йөреш-торышларны,
Күз сирпәләр төскә, башка да.

Сыный мәктәп, урам, юллар сыный,
Сыный мәҗлес, сабан туйлары.
Кызлы ана — егетләрне сыный,
Уллы ата — сыный кызларны.

Сыный хезмәт һәм табигать сыный,
Дым кирәктә утта яндырып.
Урак мәлләрендә үч иткәндәй
Төне-көне яңгыр яудырып.

Көтмәгәндә була ул тормышның
Сагышларга салган бер мәле.
Юктыр да ул адәм баласының
Сыналмыйча үткән көннәре.

Сыный хәвеф-хәтәр, бәла-каза,
Шатлык, кайгы сыный, яу кыры.
...Кылдан нечкә, кылычлардан үткер
Сират күперләре аркылы

Үтәбездер. Чөнки тереләрне
Кабергәчә кат-кат сыныйлар,
Булса булыр бала йодрыгыдай,
Ул йөрәкләр әл дә чыдыйлар.

## МИН СИННӘН КАНӘГАТЬ, ЯЗМЫШЫМ

Аяклар атлаган көнемнән
Юлда мин. Туктаусыз юлда мин,
Атамның яшәгән яшен дә
Узганмын. Бик күпкә узганмын.

Бүген дә хәтердә. Әнкәйнең
Гомере өзелде илледә.
Шул яшьтә кычкырдым мин юләр;
«Кулларда, — дип, — каеш дилбегә.»

Кычкырдым. Беразга тукталыш
Ясаган мәлемдә — алтмышта,
Кисәтте йөрәгем сак кына;
«Син, — диде, — артыгын тартышма!»

Гел уңай исмәгән икән җил,
Көтмәгән гел шома юлларда,
Ә еллар калдырган эзләрен,
Чәчләр — чал, маңгайда — буразна.

Өзеләм-өзеләм дип тора,
Дилбегә кыркылган — бик нечкә,
Ә бәлки барып та җитәлмәм
Төбәгән кыйблама — җитмешкә.

Шулай да һаман да юлда мин,
Мукәйләп булса да барышым.
Яндырдың, туңдырдың, яшәттең,
Мин синнән канәгать, язмышым.

## УЛЫМА

Китәсеңме? Риза-бәхиллекләр
Көтәсеңме? Бирәм. Кит әйдә.
Тик кайда да әзер маллар юк ул,
Тырышканнар эшләп бөтәя.

Кешеләргә ихтирамлы булсаң,
Тырыш-уңган булсаң эшеңдә,
Бөтәерсең, шуны син атаңның
Бәхиллеге, дип тот, исеңдә.

Йөргән юлларыңда абынмаска,
Адашмаска һичбер вакытта,
Нидер сораганчы анаңнан да
Сора башта хәер-фатиха.

## КӨТҮЧЕ

Космонавт булырга теләмәгән
Адәм заты юктыр ир-аттан,
Тик көтүче табу авыр бүген,
Көтү көтү бүген чираттан.

Таш явамы, боз явамы, ул көн
Юк чиратны читләп үтүче,
Өлешеңә төшкән көмеш икән
Директор да, министр да ул көн — көтүче.

...Бүген минем чират, иртә таңнан
Маллар белән кырга атладым.
Тик тапмадым маллар ашатырлык,
Яшел аклан гына тапмадым.

Йөргәнгәдер һәркөн берүк эздән
Чокыр-чакыр хәтта тап-такыр,
Бүген дә юк үлән, ә иртәгә
Чыккан кеше нәрсә ашатыр?

Кая барма ашлык, ә малларны
Үч төбедәй җирдә куасың.
Сөт-май хакын, көтүченең хәлен
Аңлап була инде шуннан соң.

Авылдан дүрт көтү чыга һәр көн
Шул бер юлдан кайта кичләтеп.
Бу — чират үткәрү, ә малларга
Кайту гына басу иснәтеп.

Йөреп кайттым мин дә, секунд санап,
Минут санап, гүя, ел тулды.
Ә шулай да бушка йөремәдем,
Моңлы-зарлы шушы җыр туды.

* * *

Гомерем буе мин кызыгып йөрдем
Рәхәтлекнең кадерен белгәннәргә,
Әмма үзем түзеп яталмадым.
Җылы, якты, тыныч бүлмәләрдә.
Аякларга мең-мең рәхмәт булсын,
Мин аларда таптым таянычны.
Аягөсте булды йокы, ялым,
Ашау-эчү булды аягөсте.

Аягөсте уйланылды уйлар,
Җырлар туды хәтта аягөсте.
Аяклардан калсам җырым тынар,
Шунсы гына булыр аянычлы.

## ИСКЕ ГАДӘТ

Бер танышым озак кына еллар
Түрә булып гомерен уздырды.
Бар белгәне — корсак үстерде дә,
Байтак креслолар туздырды.

Җае чыккан саен тиеш күреп,
Кысрыклады, какты «түбәнне»,
Иллә мәгәр кырыкка бөкләнеп
Каршылады олы түрәне.

Эшләми ул бүген. Очырдылар.
Каршы торалмады заманга.
Тик барыбер кешесенә карап,
Билен бөгә әле һаман да.

Пышылдаша күрше-күлән: аңа
Бил бөгүнең бармы хаҗәте?
Белми алар шуны, интегә ул
Ташлый алмый иске гадәтне.

...Гаҗәп кызык мәлдә яшибез без,
Сүзгә ирек, ирек — хокукка.
Ә шулай да канат җәялмибез,
Нидер тота, нидер куркыта.

Акланабыз, юанабыз һаман;
Без тумыштан, имеш, әдәпле.
Юк, әдәпле түгел, интегәбез
Ташлый алмый иске гадәтне.

* * *

И, гөлләрем, назлы гөлкәйләрем,
Тәрбияләсәм дә көне-төне.
Тернәкләнмәдегез, яшәтүдән
Өзгән идем инде өметемне.

Шулчак килеп җылы яңгыр яуды,
Күз алдымда калкып яшәрдегез.
Шул яңгырдан гына булган икән
Кыл өстендә торган яшәвегез.

Барыбыз да берүк чыбыклардан
Куылганбыз, дисәм, хата түгел.
Җылы карашлардан безнеке дә
Канатланып күккә аша күңел.

## ПЕНСИЯГӘ МӘДХИЯ

Алдан белеп торам, сизеп торам
Нәрсә әйтереңне, пенсия;
«—Балда-майда йөздерәлмәм, — дисең,
Җан асраткыч кына мин сиңа».

Шулай инде, без дә көчсез, дулап
Куптара алмыйбыз зур тавыш.
Азга риза булып үтте гомер,
Инде синдә соңгы тукталыш.

Алганнарга — аз шул, бик аз, җитми,
Биргәннәр — зур, ди, күпсенә.
Тауга карап, тау да булалмабыз,
Яшә генә инде, пенсия!

Кулга эләккәнче кырык җиргә
Бүленеп бетсә дә шул акчам,
Шырпы-тозын ничек алыр идем,
Әгәренки син дә булмасаң.

Син килгән бәйрәм, тик бер көнгә
Урын бетеп тора моң-зарга.
Җим көткән кош балалары кебек,
Авыз ачып көтәбез без сине,
Вакытында кил, берүк соңлама.

## ГАЛСТУК ТУРЫНДА

Уйламаган, һич тә көтмәгәндә
Сәер генә сорау килеп чыкты.
Очрашуга чакырганнар мине,
«— Тагаргамы, юкмы галстукны?»
...Югары сорт оннан пешкән икмәк
Булса да бик ак һәм бик туклыклы,
Тик бодаен чәчкән, урганда да
Тага алмадык без галстукны.
Игенчелек эшен белмәгәннәр
Йөриләрдер актан, пакътан санап,
Ә без кайта идек төнлә эштән,
Чүп-тузанга батып баштанаяк.
...Фермаларда булган вакытта да
Галстуксыз гына эшләп йөрдек.
Өстәлләргә менгән ап-ак сөтнең
Ничек килгәнлеген шунда белдек.
Шулай итеп гел карадан гына
Булдылар башкарган бар эшләрем.
Шуңа сезгә галстуксыз килдем
Кичерегез, дуслар, танышларым.
...Галстуксыз эшләп, җырлар яз! —
дип,
Яраткандыр инде Ходай безне.
Бүген генә килеп таксам аны
Булырмындыр кебек ике йөзле.

* * *

Шатлыкларым — мөлдерәмә,
Тик әрсездән түгел алар.
Бик сак кына кагылсаң да
Чайпала да түгеләләр.

* * *

Алтыннарга манып алган кебек,
Арыш камыллары сап-сары.
Ядрә бөртекләрен күтәрәлми
Түбән игән алар башларын.
...Кайчан гына яшел уҗым иде,
Үсте алар буын сикертеп.
Гамьсез сабый сыман чабыштылар
Бөтен басуларны бер итеп.
Кайчан гына әле шул арышлар
Шаулый-шаулый серкә очырды,
Шушы мәлдә, гүя, калдырдылар
Балачакны — гамьсез бер чорны.
Тыйнакланды алар, башкайларын
Дөнья моңы, хәстәр, уй басты.
Мин аларда һәрчак тоеп киләм
Кешеләргә охшаш сыйфатны.
...Бәвелә-бәвелә күксел рәшә уйный,
Кояш карый көлеп, кыздырып.
Арыш басулары күренә бүген
Туен көткән җиткән кыз кебек.



# ФӘНИЛ МИҢНЕГАЛИЕВ

# ҮЗЕМ ТУРЫНДА ИКЕ СҮЗ...

Тәтешле районының ямьле Гәрә елгасы буена урнашкан Кашкак авылында 1951нче елның карлы-буранлы февраль аенда дөньяга аваз салганмын. Әти-әнием гомерләре буе колхозда эшләп, җиде баланы аякка бастырдылар. Яшьли генә тормышның ачысын-төчесен татып, икмәкнең кадерен белергә өйрәндем. Берничә ел рәттән тамак ялына авыл көтүен дә көтәргә туры килде.

Башлангыч белемне туган авылымда, ә урта белемне Яңавыл районының Ямады мәктәбендә алдым. Уфа Юл-транспорт техникумын тәмамлап, туган ягым Тәтешлегә кайттым. Төзүче һөнәрен сайлап, бу һөнәргә гомерем буе тугры булып калдым. Буш вакытларымда күңелемдә туган уй-хисләремне ак кәгазьгә күчереп куярга яратам. Күңелемә хуш килгәннәрен райондашларыма район газетасы аша бүләк итеп киләм. Иҗат җимешләрем «Кызыл таң», «Атна», «Өмет» газетасы һәм дә Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәрендә нәшер ителүче «Мәйдан» журналы битләрендә әледән-әле дөнья күреп килә.

2009нчы елда исә Уфада Зәйнәп Биишева исемендәге «Китап» нәшриятында «Акчарлак» китап альманахында бер шәлкем шигырьләрем басылып чыкты.

Әйе, һәркемнең дә бит үз язмышы: бәхетен дә, шатлыгын да, кайгысын да, җыеп кына әйткәндә, агын да, карасын да бүләк итә һәм мине дә буш калдырмады.

Зарланмыйм, чөнки бүгенге көндә яраткан, кешелекле, түземле һәм дә мине аңлап кичерә белгән тормыш иптәшем, ике улым, яраткан киленнәрем, сөеп туймаслык оныкларым, иҗатымны үз иткән укучыларым булу үзе генә дә зур бәхет дип саныйм.

Шигъри күңелле районлашларым ярдәме белән «Язмышым бүләге», «Үз җиремдә» дип аталган ике китабым дөнья күрү бәхетенә иреште.

Данлыклы якташым, Русиянең атказанган, Татарстанның халык, Башкортстанның атказанган артисты, Габдулла Тукай, Муса Җәлил, Әнгам Атнабаев премияләре лауреаты, Казан дәүләт сәнгать һәм мәдәният академиясе профессоры Салават Зәки улы Фәтхетдиновның матди ярдәме белән «Гомерем агышлары» дип аталган өченче

китабымның дөнья күрүе минем өчен гомеремдә мәңге онытылмаслык иң-иң бәхетле мизгелләрнең берсе булып калды. Мең рәхмәт аңа. Күп кенә шигырьләремә Нефтекама шәһәрендә яшәп иҗат иткән яшь, талантлы композитор Илдар Мәгъдәнов көй язды. Габделфәт Сафин, Нәфкать Нигматуллиннар башкаруындагы җырларым халык күңеленә хуш килде һәм компакт дискаларга язылып дөнья күрде. «Хезмәтенә күрә хөрмәте» ди халык. Башкортстан Республикасының Почет грамотасы кечкенә төп хезмәтемнең олы җимеше булса, Гали Чокрый һәм дә Әнгам Атнабаев премияләрен иҗатымнан үзләренә ниндидер рухи азык тапкан, үз итеп яратып өлгергән укучыларымның һәм барлык якташларымның олы бүләге дип кабул иттем. «Хезмәт ветераны» исеменә лаек булып хаклы ялга чыктым.

Бүгенге көндә Тәтешледә уңышлы гына эшләп килгән «Акчишмә» әдәби түгәрәген җитәкләп киләм. Яңавылда яшь һәм башлап язучыларны берләштергән «Замандаш» әдәби берләшмәсендә әгъза булып торам.

# ӘЙ, МӨКАТДӘС ТУГАН ЯГЫМ

Әй, мөкатдәс туган ягым,
Кендек каным тамган җирем,
Бүләк булсын йөрәгемнән
Ташып чыккан шушы җырым.

Сиңа карап кем сокланмас;
Урманнарың, болын-кырлар
Сиңа тарта, алып кайта
Ераклардан урау юллар.

Азан моңлы һәр авылың,
Ямьле Танып, Әри буең,
Кайда барсам, кайда йөрсәм,
Бары синдә минем уем.

Канат биргән талантларың
Сине бетмәс данга күмә.
Гали Чокрый, Атнабаең,
Белми хәзер кемнәр генә.

Синдә моңлы сандугачлар,
Чишмәләрең җырлап ага.
Адашканнар, җиде ятлар
Үз бәхетен синдә таба.

Синең сулыш — минем язмыш,
Әнкәм назын синдә тоям.
Кочагыңа сыена-сыена
Чын күңлемнән сине сөям.

Кабатланмас бала чагым,
Синдә атты яшьлек таңым,
Рәхмәтемнең иң олысын
Җиткерәмен сиңа тагын.

Күзләремне сиңа багам,
Яшәргә көч, илһам алам.
Эш сөючән халкың белән
Атлыйсың син алга табан.

Газизләрдән-газиз җирем,
Сине күреп шатланамын,
Заманага сер бирмичә
Яшәвеңә таң каламын.

Әй, мөкатдәс туган ягым,
Синең белән горурланам.
Синдә яшәү — үзе бәхет,
Мәңгелеккә синдә калам.

*08.01.2006*

# КАЙТАМ ӘЛЕ

Кайтам әле авылыма,
Туып үскән ягыма.
Авылдашлар, кан кардәшләр,
Туганнарым янына.

Авылымның урамнарын
Бары бер үтәр өчен,
Күңелләрем бушаганчы
Елап бер китәр өчен.

Иман нурына күмелгән
Изге йортка барырга,
Хәер салып әткәм-әнкәм
Рухын искә алырга.

Яшьлегемнең ак каенлы
Сукмагыннан үтәргә,
Үткәннәрне исләремә
Төшерепләр китәргә.

Азан моңын, чишмә җырын
Бер туйганчы тыңларга,
Җиләк җыйган, көтү көткән
Болыннарны буйларга.

Тузанлы басу юлыннан
Җәяүләп бер үтәргә,
Сагнуларны, сагышларны
Таратыплар китәргә.

Ямьле сабантуйларында
Очрашып сөйләшергә,
Су буенда учак ягып,
Таңгача серләшергә.

Сокланып бер карар өчен
Иген үскән кырларга,
Үз моңнарыма кушылып
Рәхәтләнеп җырларга.

Тәмле чишмә сукайларын
Бер авыз итәр өчен,
Рәхмәтемнең иң олысын
Әйтепләр китәр өчен.

Кайтам әле авылыма
Карамый бернәрсәгә.
Туган җирдән кадерлерәк
Юк шул, юк, бернәрсә дә.

*25.05.2007*



4 17

# РӘХМӘТ, ӘНКӘЙ!

*Җиде бала анасы, әнкәем*
*Корбанбикәгә...*
*Автор*

Рәхмәт, әнкәй, озын төннәр буе
Күзләреңне безгә баккансың.
Тәүге тапкыр күзләремне ачкач,
Тел ачкычын үзең тапкансың.

Рәхмәт, әнкәй, ак биләүгә биләп,
Күкрәк сөтең безгә биргәнсең.
Балам минем, бавыр итем, диеп,
Йөрәк җылыңны син өргәнсең.

Рәхмәт, әнкәй, син бит безнең өчен
Бергә түгел, җидегә ярылдың.
Менә тагын сабый бала сыман,
Сагынып кайтып сиңа сарылдым.

Рәхмәт, әнкәй, изге догаларың
Бәла-казалардан сакласын.
Җир-йөзендә һәрбер бала-чага
Бала булып калсын, «чакмасын».

Рәхмәт, әнкәй, йомшак миңа һәрчак
Сөялләнеп каткан кулларың.
Риза булып бирче фатихаңны,
Алда көтә тормыш юлларым.

Рәхмәт, әнкәй, без бит синең алда
Бурычлыбыз гомер-гомергә.
Мәңге яшь бул, картаюны белмә,
Кайгы-хәсрәт күрмә һичбер дә.

Рәхмәт, әнкәй, мәхрүм итмәгәнсең
Үз телемнән, туган телемнән.
Үз язмышың, берүк, аермасын
Гомер иткән изге җиреңнән.

## ШАГЫЙРЬЛӘРНЕ КҮКТӘН ТӨШКӘН, ДИЛӘР

*Әнгам Атнабайга*

Күзләремне тутырып күккә карыйм,
Күзәтәмен чиксез галәмне.
Йөрәгемә тынгы табалмыйча,
Кулларыма алдым каләмне.

Шагыйрьләрне күктән төшкән,
диләр,
Күктән карлар гына ява ул.
Дөреслекнең күзләренә карап,
Шагыйрь булган кеше яза ул.

Шагыйрьләрне күктән төшкән,
диләр,
Күктән яңгыр гына ява ул.
Шагыйрь булган кеше халкы өчен
Йөрәк маен хәтта сава ул.

Шагыйрьләрне күктән төшкән,
диләр,
Күктә яна бары йолдызлар.
Җирдә дә бит үз йолдызын
кабызып,
Балкып янган уллар, кызлар бар.

Шагыйрьләрне күктән төшкән,
диләр,
Ышанасым килми төшкәнгә.
Халкың сине үз шагыйре итте
Халкың белән бергә үскәнгә.

Шагыйрьләрне күктән төшкән,
диләр,
Күктән төшми алар, менә ул.
Шагыйрь булган кеше халкы белән
Бергә яши, бергә үлә ул.

Шагыйрьләрне күктән төшкән,
диләр,
Күктә балкый бары Кояш, Ай...
Якты маяк булып күңелләрдә
Мең яшәрсең әле, Атнабай.

Күзләремне тутрып күккә карыйм,
Күпме йолдыз балкый күгемдә.
Мәңге үлмәс гади халык улы,
Яшисең син безнең күңелдә.

## БУЙЛАДЫМ ИГЕН КЫРЛАРЫН

Кайтып киләм туган якның
Киң кырларын иңләп-буйлап.
Кыр батырын, игенчене
Данга күмеп, җырлар җырлап.

Алларымда борма-борма
Басу юлы, иген кыры.
Ишетелә аяз күктән
Тургайларның дәртле җыры.

Тук башаклар тибрәләләр
Акрын гына искән җилгә.
Әйтерсең лә укый алар
Рәхмәтләрен газиз җиргә.

Үзем атлыйм, тәмләп куям
Пешеп килгән икмәк исен.
Тоям шулчак игенченең
Ачы тирен, хәләл көчен.

Шатлыгымның һич чиге юк,
Җәйрәп ята туган ягым.
Икмәктән зур, кадерлерәк
Нәрсә бар соң җирдә тагын.

Алларымда иген кыры,
Уңда арыш, сулда бодай.
Бар теләгем — тук башаклар
Тибрәлсеннәр мәңге шулай.

## ВАКЫТ ЧАБА, ГОМЕР АГА...

Теләсәң-теләмәсәң дә
Вакыт туктамый чаба,
Аккан сулардай ашкынып
Гомер көзенә таба.

Вакыт чаба, гомер ага
Мизгелләргә бәйләнеп,
Үткән гомер — атылган ук,
Кире кайтмый әйләнеп.

Узардай булып вакытны
Берәүләр дөнья куа,
Гомере күзләрен дә көтми
Якты дөньядан шуа.

Син ашыкма тормышыңда,
Яшә елмаеп, көлеп,
Тазалык сора Ходайдан
Шөкераналар кылып.

Вакыт чиксез, тик гомер бер
Күз ачып йомган ара,
Фанилыктан бакыйлыкка
Күчкәч бары да кала.

Бушка уздырма вакытны,
Болай да кыска гомер.
Теләсәң дә кабат янмас
Көлгә әйләнгән күмер.

Исең китмәсен вакытның
Туктамый чапканына,
Китсә китсен, тик уфтанма
Гомернең акканына.

*12.03.2008*

## БАЛАННАР

Язлар җиткәч, кар сулары кипкәч,
Яшеллеккә күмелә аланнар.
Һәр ел саен мине каршы ала
Аландагы үскән баланнар.

Җәйләремдә гүзәл табигатьне
Күрер өчен киләм аланга.
Күзем төшә һичбер бирешмичә
Бөгелеп-сыгылып үскән баланга.

Күңелем сагышларын таратырга
Киләм көзен таныш аланга.
Әллә тормыш заман җилләреннән
Елый төсле ачынып балан да.

Кар-буранда, кышкы салкыннарда
Эзләп табам таныш аланны.
Күңелем белән, гүя, кочып елыйм
Канлы яшен түккән баланны.

Язлар җиткәч, кар сулары кипкәч,
Яшеллеккә күмелә аланнар.
Зарланмыйча, һичбер уфтанмыйча
Чәчәк ата һәр яз баланнар.

*15.01.2005*



## АЛИЯ ХАЙРУЛЛИНА

**Алия Закиевна Хайруллина**

Туган, үскән, яшәгән, хезмәт иткән җирем Борай. Һөнәр буенча — педагог. Тел-әдәбият, мәдәният укытучысы. Хезмәтемнән тыш яраткан шөгелем дә әдәбият-сәнгать белән бәйле. Гомерем буе сәхнәдәмен. Борай мәдәният йорты кырындагы халык биюләре ансамбленең, халык театрының нигез ташларының берсемен.

Шигърият белән кызыксынуым кече яшьтән. Шигырьләрем минем — күңелем көзгесе, йөрәгем авазы. Лирик шигырьләр иҗатымның төп өлешен алып тора. Фәлсәфи, тормыш-яшәеш, замана-дәверләргә кагылышлары да бар. Тәрҗемә белән дә шөгелләнәм. Афанасий Фет, Сергей Есенин, Константин Симонов, Рәсүл Гамзатов, Михаил Исаковский, Алексей Сурков, Алексей Фатьянов кебек шагыйрьләрдән тәрҗемәләрем бар. Шигырьләрем район, республика газета-журналлары битләрендә күренә. Бәләбәйдә чыга торган «Йәйгор»(2000 ел), «Акчарлак» (2007 ел) җыентыкларында басылдылар. Минем шигырьләргә композиторлар Вәсил Хәбисламов, Марсель Иванов, Ильмир Зәлиев, Эндира Лалаева, Фәвил һәм

Мәүҗидә Гыйлфановлар язган җырлар Хәния Фәрхи, Айдар Галимов, Гөлназ Сираева, Мәгариф Әхмәдиев кебек профессиональ җырчылар, районның, республиканың үзешчәннәре башкаруында сәхнәләрдән, радиодан, телевизордан яңгырый.

Бәләбәйдә үтә торган «Илһам чишмәләре» (2000 ел) шигърият бәйрәмнәре лауреатымын.

Башкортстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, Русиянең мәгариф отличнигы.

Бүгенге көндә Борай тарихи-крайны өйрәну музее директоры.

## БОРАЕМА — ТУГАН ЯГЫМА

*Туфрагына алтын чәчсәләр дә,*
*Җитми икән туган җирләргә.*

Бораем дип җырлар язганым юк,
Көтәсеңдер, бәлки, көтәсең.
Багышларга сүзләр җитмәс кебек,
Туган җирем, гафу итәрсең.
Бу дөньяда бардыр хәйран яклар,
Иң гүзәл як — бары син, димим.
Минем өчен синнән күркәме юк,
Чөнки туган җирем син минем.
Туган җирне сайлап алмасам да,
Рәхмәт хисем ихлас күңелдән.
Бар гомерем сина багышланган,
Бар булмышым сиңа үрелгән.
Болыныңның кыяк-үләне мин,
Чишмә суларыңның тамчысы,
Тургай җырларыңның бер авазы,
Аҗаганның ялтыр камчысы.
Синнән китеп кайда бәхет табыйм —
Тамырларым монда, тирәндә.
Күңелләрнең әллә кайсы кылы
Тетрәп куя «Борай» дигәндә.
Тормыш бәйрәм түгел, ә шулай да
Синдә үткән гомер җырга тиң.
Уңыш үрләрендә — шатлык уртак,
Авыр көннәрендә — иңгә-иң.
Бардыр, бардыр синнән гүзәл җирләр,
Иң гүзәл җир бары син, димим.
Минем өчен синнән якыны юк,
Чөнки туган җирем син минем.

# ӘЛЛӘ КАРТАЯМЫ ЕЛЛАР ДА

Быел язлар әллә нинди сүлпән:
Кар сулары ярсып акмады,
Сыерчыклы таңда, хәбәр салып,
Тәрәзәне җилләр какмады.
Өлгермәдек никтер кошларны да
Бәйрәм ясап каршы алырга.
Гашыйклар да ашкынмады, ахры,
Пар сыерчык күреп калырга.
Бозлар китүе дә яр тутырып
Җыялмады быел халыкны.
Тау башларындагы үләннәр дә
Бездән башка шытып калыкты.
Сайрар кошлар кайту шатлыгыннан
Ярсый-ярсый канат какмады.
Яз хуҗасы — галиҗәнап кояш
Артык мәрхәмәтле бакмады...
Бар да боек кебек табигатьтә,
Чәчкә ата алмый гөлләр дә...
Аңламассың, әллә безгә карап,
Сүлпәнләнә инде көннәр дә.

# МОГҖИЗАЛАР БАРДЫР, ЫШАНСАҢ

Сәгать сукты... Яңа елның
Беренче адымнары.
Беренче кар, беренче җыр,
Беренче табыннары...
Теләк яңгырлары ява,
Ярышып карлар белән:
Тигезлектә үтсен еллар
Лаеклы ярлар белән.
Бәхетләрнең, шатлыкларның
Килсен өр-яңалары,
Кабул булсын тәкъваларның
Кылган бар догалары.
Мәрхәмәт-шәфкать күңелдә
Яңадан урын алсын,
Ызгыш-талаш, этеш-төртеш
Үткән елларда калсын...
Ышандыра кешеләрнең
Шау-гөр котлашуына,
Ел буе йөргән хыялның
Тормышка ашуына.
Юкса, күптән артта калган
Беркатлы сабый чаклар,
Яңа бәхет-шатлык теләп
Яккан өмет-учаклар.
Тик җибәрми әкият иле,
Күптән китсәк тә үсеп —
Күңелнең бер почмагында
Балачак тора посып.

# ӘЙЛӘНӘ ДӨНЬЯЛАР

Әйләнә дөнья, әйләнә,
Һәркем үз өлешен татый:
Берәүләрне күккә чөя,
Берәүләрне салып тапый.
Тагын бер әйләнеп куйса,
Урыннар алмашу китә.
Берәүләр тантана итә,
Берәү — әйләнгәнне көтә.
Берәү бөтен җил-давылда
Исән-имин кала бирә:
Йә куштаннар телен белә,
Йә түрәләр серен белә...
Әйләнә-тулгана дөнья.
Ә офыклар шул ук төстә.
Саллылар һаман түбәндә,
Җиңел-җилпе калка өскә.

# САГЫШЛАРДАН ЮК ШУЛ ЧАРАЛАР

*Әткәем гармунчы*
*Зәки истәлегенә*

*Мин әткәйнең гармун уйнаганын*
*Еш ишетәм соңгы араларда.*
*Аның моңы тула күптән инде*
*Төзәлгән дип йөргән яраларга.*
*Роберт Миңнуллин*

Шагыйрь бәхетлерәк — күреп калган
Әткәсенең гармун уйнаганын.
Аңлый алыр яшьтә булмаса да
Уйнаганданиләр уйлаганын.

Ишеткәндер әткәсенең моңы
Яңгыравын җәен сәхрәләрдә,
Кышкы моңсу кичтә, бәйрәмнәрдә,
Сабантуйда, бәлки, сәхнәләрдә.

Эштән арып кайткан әткәсенең
Утыргандыр кочагына сыенып,
Әле акыл белән аңламаган
Бәхетенә сабыйларча сөенеп.

Шагыйрь бәхетлерәк безнең кебек
Сыңар канат белән үскәннәрдән.
Бәллүләрдә тирбәләсе чакта
Сагыш күлләренә төшкәннәрдән.

Минем әткәемнең гармун моңы
Калган бары кеше телләрендә,
Сибелеп калган сәхрә-болыннарга,
Ул яраткан «Борай көйләрендә».

Тезелсә дә еллар араларга,
Сибелсә дә моңнар далаларга,
Юк чаралар җирдә, юк дәвалар
Үзем белән яшьтәш яраларга.

# КОЕЛА КЫЗЫЛ МИЛӘШЛӘР

Кыш уртасы — сукмакларга
Кызыл җиләк сибелгән!!!
Әйтерсең лә ак җирлеккә
Кызыл бизәк чигелгән.
Гүя ак калфак кашында
Энҗе-мәрҗән күзләре,
Гүя яралы яугирнең
Яу кырында эзләре.
Күптән үтеп киткән җәйнең
Соңгы сәламедер бу.
Бөек рәссам — табигатьнең
Шаян каләмедер бу...
Ничекләр бу күренешне
Түкми-чәчми сакларга!
Табигать рәнҗер шикелле —
Кыймый торам атларга.

## ЯЗНЫ КӨТКӘНДӘ

Яз хәбәре килеп җитәр-җитмәс,
Уянмаган әле каеннар.
Кыяр-кыймас керфекләрен сирпеп,
Яз киләсе юлга карыйлар.
Җирнең өсте ап-ак келәм әле,
Ак бүректән әле түбәләр.
Саклан, дигән төсле шул түбәдән
Тамчы-сөңге җиргә төбәлгән.
Кояшы да кырыс кына карый,
Бик елмаеп бармый Галәмгә —
Әллә җиргә бирәр дәгъвасы бар,
Әллә үпкәләгән адәмгә...
Тик күңелләр урынында түгел,
Көтү дулкынына корылган,
Табигатьнең шундый үзгә мәле —
Бар тереклек язга борылган.

# КАРТАЙМАСЫН БАРЫ КҮҢЕЛЛӘР

Дөрләп янган учаклардан
Калмый ул пыскып күмер...
Яшьнәтеп яшәгәнгәдер —
Сизелми үтте гомер.
Тик йөрәкләр мантыйк белән
Теләми килешергә,
Котылгысыз мизгелләргә
Карусыз бирешергә.
Үзебез дә адымнарның
Тизлеген сүндермибез,
Үкчәгә басып килгәнгә
Юл биреп, сер бирмибез.
Юатабыз күңелләрне,
Әле кич булмаган, дип.
Чәчләргә кунган кыраулар
Күңелгә кунмаган бит!



**ГӨЛСИМӘ ЗИННӘТУЛЛИНА**

Мин, Гөлсимә Әхәт кызы Зиннәтуллина, яшьлек елларымнан башлап Борайда яшим. Тумышым белән мәңге яшел карагайлары, ак зифа каеннары белән дан тоткан калын урманлы Аскын якларыннанмын. Күпсанлы елга-чишмәләре, сузылып яткан таулары белән үзенә чакырып торган гүзәлләрдән гүзәл Иске Казанчы авылы — ул минем туган бишегем! Әйе, мин урман кызы, гел урманда гына үстем дисәм дә хата булмас. Чөнки әткәем күп еллар урманчы булып эшләгән. Әмма 1955 елның кара көзендә минем туганымны көтеп йөргәндә безнең бәхетле гаиләбезнең ишеген кара кайгы шакыган. Әткәемне җирләгән көнне туганмын. Язмышлардыр, мин нәкъ әткәем кебек табигать баласы булып үстем. Аның эзләреннән китеп урманчылыкта эшли алмасам да, әтием кебек үк урманнарны өзелеп яратам. Шушы хисләр еллар белән күңелемдә үсте, ә инде туган якларымнан читтә яши башлагач, урманнарыма булган сагынуларым кайнар чишмә булып күңелемнән түгелә башлады. Тәүге шигырьләрем дә минем — туган якларым турында! Әйе, дуслар, җырчы кошка сагыну хисе хас шул. Әмма, кечкенә

чагымнан тальян, хромка гармуннарын оста гына сайратсам да, дөньяга ниндидер матур күзлек аша карасам да, шигъърият, җыр-моң күңелемә бик якын-үз булса да, язмышларым мине илһам илләренә урау юллар аша китерде. Әмма мин соңладым дип тормадым, гомер җәйләремә аяк баскач кына шигъриятькә сәфәр чыктым. Һәм менә бүген инде дистә елдан артык шигърият мәйданынында үзем кебек каләм ияләре белән бил алыша-алыша сары көзләремнең каршыма килеп басканын да сизмәгәнмен... Әйткәндәй, шушы еллар эчендә җиңүләрем дә юк түгел, дуслар. Үзем туып үскән Аскынымның «Ышаныч» гәзите тәүге шигырьләремне дөньяга күрсәтсә, тора-бара үзем гомер иткән Бораемның «Алга» гәзите шигъриятемә трамплин булды, дияр идем.

Аннары инде «Өмет» гәзите, «Тулпар» журналы редакцияләре миңа дуслык кулын сузды. Бәләбәйдәге эшләп килүче «Илһам чишмәләре» фестивалендә дә иҗатымны үз иттеләр, җылы сүзләр әйтеп, канат куйдылар. Әйтәсе килә, үзем әгъза булып торган Яңавыл «Замандаш» әдәби-иҗат берлегенең дә минем

кебек соңлап атын җиккәннәргә рухи яктан ярдәмнәре бик зур. Андагы иҗади очрашулардан илһам алып, үзебезне кечкенә каләм иясе санап, рухланып яшибез. Яңа каләм тибрәткәннәрнең бил алышыр мәйданы булган «Акчарлак»-2009 җыентыгында да бер шәлкем шигырьләрем дөнья күрде. Бу әле соңлап чыккан иҗат юлымда тәүге биеклекләрем генә булса да, соңгысы булмаса иде!

Ә инде иҗат җимешләрем бар да үземнең тормыш бакчамнан өзеп алынган. Җимешләремнән авыз итегез, бәя бирегез, дуслар!

## ШАЛАШТА ДА ЯШӘҮ ОҖМАХ, ДИЛӘР

Шалашта да яшәү оҗмах, диләр,
Сөйгән кешең булса янында.
Парлы гомердән дә кадерлерәк,
Бу дөньяда ни бар тагын да?

Ялкыннарын кем соң өстәп торыр,
Әгәр ялгыз учак кабызсаң?
Көтмәгәндә язлар ташкан чакта,
Хыялыңны салып агызсаң?

Яз җылысы сиңа кагылмаса,
Шытмасалар сөю гөлләрең.
Парлыларга карап, ямансулап,
Гел уфтанып үтәр көннәрең...

Син бәхетле — яшьлек язларында
Сөю утларында яналсаң!
Кавышу сәгатьләре насыйп булып,
Яратканың белән калалсаң!

Парлыларның дәвамнары кала,
Нәсел чылбырдарын сузарга.
Һәммәбезгә язсын, парлы булып,
Гомер юлларыннан узарга!

Шалашта да яшәү оҗмах, диләр,
Сөйгән кешең булса янында.
Парлы гомердән дә кадерлерәк,
Бу дөньяда ни бар тагын да?

## ГАИЛӘҢ БАР,
## ДИМӘК СИН БӘХЕТЛЕ

Гаилә ул — кешеләрнең тылы,
Ә тормыш ул — көрәш мәйданы.
Гаиләң, эшең, тазалыгың булса,
Үзе табыла ул калганы.

Гаиләң бар, димәк син бәхетле,
Эштән кайтып керер йортың бар.
Өшегән җаныңны җылытырга,
Учагыңда янган утың бар.

Гаиләң бар, димәк син бәхетле,
Өзелеп торган якын кешең бар.
Шәҗәрәңне дәвам итәр өчен,
Синең кызың яки улың бар.

Гаиләң бар, димәк син бәхетле,
Тәрәзәңдә утың сүнмәгән.
Киләчәккә сине алып барыр,
Өмет-ышанычың үлмәгән!

Гаилә ул — кешеләрнең тылы,
Ә тормыш ул — көрәш мәйданы.
Гаиләң, эшең, тазалыгың булса,
Үзе табыла ул калганы!



5 17

## ТОРМЫШ АРБАСЫНДА

Тормыш арбасында дүрт тәгәрмәч —
Гомер атларына җигелгән.
Үз кыйбласыңны табып,
югалтмыйча бару,
Бу дөньяда түгел җиңелдән.

Ал тәгәрмәч келтер-келтер бара,
Хатын-кыздай назлы, иркәрәк.
Арт тәгәрмәч ир-ат затыннандыр,
Этеп кенә бара иркәләп.

Мин көчлемен,
мин баш булам, диеп,
Ал тәгәрмәч белән ярышмый.
Бар көченә этеп бара бирә,
Язмыш белән килешә, карышмый.

Гомер буе тормыш арбасының,
Авыр йөген бергә сөйриләр.
Шатлыгы да, кайгысы да уртак,
Бер үк җырны алар көйлиләр.

Тормыш арбасында дүрт тәгәрмәч —
Гомер атларына җигелгән.
Үз кыйбласыңны табып,
югалтмыйча бару,
Бу дөньяда түгел җиңелдән!

# АЕРЫЛУ САГЫШЫ

Поезд китте. Мин перронда
Сөйгәнемне калдым озатып.
Боекмачы, дустым, диеп
җилләр генә,
Иңнәремә кагыла юатып.

Исәннәр бит, бер кайта ул, диеп,
Җилләр шыбырдыйлар колакка.
Көтәр кешең булу зур бәхет ул,
Китсә дә ул бик-бик озакка.

Ялгызлыктан җаным өзгәләнеп.
Кайтып барам җәяү башым иеп.
Юл буенда парлы кошлар сайрый,
Син бит ялгыз түгел, түгел, диеп.

Менә йортым мине көтеп тора,
Моңсу гына ачам капканы.
Ялгызлык шәүләсе сагыш булып,
Миннән калмый өйгә атлады.

Стенада сәгать туктап калган,
Әллә ялгыш, әллә язмышмы.
Көйгә салсаң, сәгать йөреп китәр,
Ничек җиңим ачы сагышны?

Күп тә тормас, тагын мин поезддан,
Каршылармын сөйгән ярымны.
Исән булсак, очрашырбыз, диеп,
Җилгә чишәм сагыш-зарымны...

# ЙӨРӘК БӘЙГЕ АТЫ

Их, димен дә, йөрәк кысып куя,
Күз яшьләрем чыга атылып.
Җаем үтте, күзләремә багам,
Гомер атым чаба ашыгып.

Йөрәкне бит ярсыма син, диеп,
Йөгәнләпләр куеп булмый бит.
Әйдә, ярсып чапсын вакытында,
Ташкыннарсыз йөрәк тынмый бит!

Сәгать тә бит, килеп бер ватыла,
Ә йөрәк соң ничек чыдасын?
Язмыш ачысына түзәлмичә,
Яндыра ул соңгы чырасын...

Менә шулай, бәйге аты кебек,
Гомер юлларыннан узасың.
Өстән салмый кигән кием кебек,
Йөрәккәем, син дә тузасың.

Их, димен дә, артка борылып
карыйм,
Күз яшьләрем чыга атылып.
Җайләр үтте, күзләремә багам,
Гомер атым чаба ашыгып...

## ЯЗМЫШЛАРНЫҢ КУЛЫ КАТЫ

Кайчак тормыш гел кирегә китә,
Каккалый да сине суккалый.
Язмышларың куйган сынаулардан,
Беркем сине килеп якламый.

Бу дөньяда терәгең булмаса,
Яшәүләре ай-һай читен лә.
Әйтерсең лә шулчак син үзеңне,
Тоясың күк упкын читендә...

Тик бер адым, бары тик бер адым,
Җаннарыңны сала упкынга.
Гомер буе аннан яна кеше,
Әрнү-үкенечләр утында.

Шундый чакта якын дуслар кирәк,
Серләреңне чишеп салырга.
Салкын акылыңны эшкә җигеп,
Упкынга сикерми калырга.

Бер алдын, бер артын күрсәтә шул,
Тормышыбыз бик нык катмарлы.
Әмма, дуслар, шуны онытмыйкчы,
Кеше гомеренә хак бармы?

## ДУСЛАР КУЛЫ КИРӘК

Җанда кара таплар калдырырлык,
Сәбәпләре чыгып кына тора.
Көтмәгәндә барыр юлларыңа,
Язмыш сынаулары киртә кора.

Киртәләрне атлап чыгу авыр,
Җаның бәлаләргә тарыса.
Көчен, дәртен җуйган ялгыз җаның,
Язмыш белән көрәшеп арыса...

Упкын читләренә килеп басып,
Кемнәрдәндер ярдәм көткәндә.
Кемдер килеп кулын бирер, диеп,
Язмышыңнан өмет иткәндә.

Шул чакларда дуслар кулы кирәк,
Упкыннардан тартып алырлык.
Баш очыңда яшен яшьнәгәндә,
Синең белән бергә калырлык!

Шунда гына тормыш күкләреңнең,
Кара болытлары таралыр.
Күңелеңдә язлар чәчәк атар,
Йөрәгеңдә сөю яралыр!

# СЕЗ КАЙДАСЫЗ, ЯШЬЛЕК ДУСЛАРЫМ

Сер сыярдай дуслар, сез кайдасыз,
Аваз салам, тавыш бирегез?
Йөрәккәем үрсәләнгән чакта,
Яннарымда юксыз берегез!

Кер бавына элеп киптергәндәй,
Җаным кибәр инде җилләрдә.
Күңелкәем яңгыр көтә, диеп,
Эндәшим соң бүген кемнәргә?

Җылы яңгыр булып түгелегез,
Язлар баш калкытсын бакчамда.
Күңел ишегегез минем өчен
Ачык булсын, кайчан барсам да!

Үзегез дә минем тарафларга,
Тузан төшермәгез, — килегез.
Сез кайдасыз, яшьлек дусларым, дип,
Сезне көтәм, дуслар, белегез!

Сер сыярдай дуслар, сез кайдасыз,
Аваз салам, тавыш бирегез?
Йөрәккәем үрсәләнгән чакта,
Яннарымда юксыз берегез...

*2012 ел*



**РӘФИС МӨХӘММӘТДИНОВ**

Мин, Мөхәммәтдинов Рәфис Нәҗип улы, үзебезнең гүзәллеккә бай Башкортстанның Яңавыл районы Яңа-Уртавыл авылында, 1960 елның 28 февралендә дөньяга килгәнмен. Бала чагымнан ук аякларыма басып йөри алмыйм, минем аякларым — инвалидлар коляскасы. Мәктәптә укып белем ала алмадым, укытучылар өйгә килеп укырга, язарга өйрәттеләр. 1990 елда кулыма каләм алып шигырьләр яза башладым, әсәрләрем Башкортстан, Татарстан гәзит-журналларында басылып тора, китапларым да бар. Киләчәктә дә авыр язмышыма баш имичә, шатланып иҗат итеп яшисем килү теләге зур!

## КОЯШ НУРЫМ СИН

Син бит минем яшәү чыганагым,
Дөньялыкта яшәү терәгем.
Мәхәббәтем бары сиңа гына,
Син генә дип тибә йөрәгем.

Син елмаеп күзләремә баксаң,
Канатланып яшәр көч алам.
Авыртынган чакларыңны күрсәм,
Тирән уйлар белән борчылам.

Синең кайгыларың — минем кайгы,
Шатлыкларың була шатлыгым.
Күзләремә карап аңлыйсың күк,
Минем сүзләремнең хаклыгын.

Син булганда минем яннарымда,
Күңел күгем балкып нур чәчә.
Кояш нурым булып, һәрчак балкып,
Яшә әле, иркәм, син яшә!

*декабрь 2009*

# КАЙТАМ

Мөмкинчелек булган саен,
Кайтып урыйм туган якка.
Берәү әйтә: «Анда сине
Әткәң-әнкәң көтми хәзер,
Ник кайтырга инде юкка!»

Кайтмый булмый, туган нигез,
Болай да бит еш кайталмыйм.
Газиз авылдашларымны,
Туганнарны, дус-ишләрне
Һич кенә дә оныталмыйм.

Авылым урамнарын үтеп,
Җанга бер рәхәтлек алам.
Зиаратта әткәм-әнкәм,
Рухларына дога кылып,
Каберләргә чәчәк салам.

Менә шуның өчен кайтам...

*26.01.2010*

## КӨЗГЕ ҖИЛЛӘРГӘ

Җилләр, җилләр, көзге җилләр,
Бигрәк салкын исәсез.
Түтәл-түтәл чәчәкләрнең
Гомерләрен кисәсез.

Җилләр, җилләр, яфракларны
Өзеп харап итәсез.
Кояшлы җылы җәйләрне,
Тагын алып китәсез.

Җилләр, җилләр, сез гөлләрне
Туңдырмагыз, көтегез.
Кулларыма чәчәк тотып,
Сөйгәнем белән очрашыйм,
Бераз сабыр итегез.

*22.10.2012*

# АКЛЫК КОЧАГЫНДА

И сокланып карап йөрим
Агачлардагы бәскә.
Күз нурларын камаштырган
Кышкы сихри ак төскә.

Һәр агачта бер матурлык,
Үзенә күрә бөтән.
Табигатьне бу халәттә
Күрмәгән идем күптән.

Җаныма моң булып инә
Яшь карның шыгырдавы.
Әйтерсең лә, тауга менәм,
Алдымда — шатлык тавы?

*19.01.2012*

# САГЫНДЫРА

Мин ашкынып авылыма кайтам,
Бүә аръягына, кунакка.
Сагындырды инде, бик күптәннән
Юл төшмәде озак ул якка.

Юл буенда каршы ала мине
Ап-ак каеннарым тезелеп.
Гомер күзләремә якынлашкач,
Нигеземнән киттем өзелеп.

Үзгәрмәгән авыл, элеккечә,
Әллә кайдан балкый, нур чәчә.
Шау-шу килеп бала-чага уйный,
Кыз, малайлар анда берничә.

Көтү каршыларга чыгып басты
Авылдашлар капка төпләргә.
Бу күренеш миңа шундый якын,
Сөердер бу сүзем күпләргә.

Сагындыра, капка төбебездә,
Көтү кайтуларын көткән чак.
Әткәй, әнкәй барда бергәләшеп
Рәхәтлектә гомер иткән чак.

*21.10.2012*

## КҮҢЕЛ КҮЗЕМ

Чыктым әле урамнарны
Бер әйләнеп керергә.
Алтын көзнең матурлыгын
Янә дә бер күрергә.

Баланнарның, миләшләрнең
Кызарып пешкән чагы.
Көннәр ямьле, җитте ахры
Әбекәйләр чуагы.

И матур чак, тик аз гына
Гөлләр саргая төшкән.
Алмагачларда алмалар
Ничек балланып пешкән.

Көзге шәһәр урамына
Сокланып барам үзем.
Ах, минем бит авылымның
Алтын басу-кырларына
Төбәлгән күңел күзем.

*09.09.2011*

## ЯМЬЛЕ АЙ

Табигатьнең йокысыннан
Уянган чагы.
Яшәүгә көч-кодрәт өстәп,
Яз җитте тагы.

Бар тирә-юнь яшеллеккә
Төренгән көннәр.
Кояшлы, ямьле май аен
Үз итмәс кемнәр.

Талдагы сайрар кошларның
Агыла моңы.
Тау буеннан ишетелә
Чишмәләр чыңы.

Кырда мотор тавышлары
Тәүлек буена.
Килер уңыш орлыклары
Җиргә сыена.

«Икмәк булса, бар да булыр!»
Бу әйтем, беләм.
Игенчеләр кырга чыккан
Зур өмет белән.

Ап-ак чәчәктә шомыртлар,
Алмагач, чия.
Күр, май ае нинди сихри
Ямьнәргә ия!

*06.05.2012*

# КӨРӘШӘМ

Авыру мин, аякларга
Басып та тора алмыйм.
Илле бер ел язмыш белән
Көрәшәм, туктап калмыйм.

Хәлем авырлаша бара,
Еллап түгел, ай саен.
Гомеремне озайтырга,
Төрлечә эзлим җаен.

Якты дөньяны калдырып,
Килми әле китәсем.
Авырлыкны җиңә-җиңә,
Килә минем бу тормышны
Гүзәлрәк итәсем.

*17.12.2011*

## МОҢСУЛАНМЫЙК

Тәрәзәдә карашларым,
Янә көзләргә җиттек.
Ашлыклар инде келәттә,
Быел мул иген иктек.

Вак яңгыр сибәләп тора,
Китте очар кошлар да.
Инде җилләр салкын исә,
Килеп җитәр кышлар да.

Өй каршындагы каеннар
Коя әнә яфрагын.
Озакламый ак кар каплар
Туган җирнең туфрагын.

Җир-анама да ял кирәк,
Язга кадәр ял итәр.
Моңсуланмыйк, исән булсак,
Салкын кышлар үтеп китеп,
Чәчәкле язлар җитәр.

*22.10.2012*

## АВЫЛДА ТУЙ

Авыл буйлап җилә туй атлары,
Борынгыдан калган тамаша.
Дугаларда чиккән сөлгеләрне
Күреп  хәтта күзләр камаша.

Кыңгыраулар чыңы әллә каян
Яңгырап тора бөтен урамга.
Туй атлары чаба авылымда,
Карап тормый карлы буранга.

Килен төшә кыңгыраулы атта,
Иске йолаларны яңартып.
Яшәсеннәр алар бер-берсенә
Тугры булып, сөеп, яратып.

*08.01.2011*



# ИНСИЯ МУХАНОВА

Мин, Муханова Инсия Әльмухамет кызы, 1940 елның 28 ноябрендә матур табигатьле Салих авылында дөньяга килгәнмен.

Авыл мәктәбендә башлангыч белем (4 класс) алгач, Ямады мәктәбендә укып, 10 сыйныфны яхшы билдәләргә тәмамладым.

1958 елда сатучылар курсын тәмамлагач, авыл кибетенә сатучы булып эшкә башладым. 17 ел Ямады сәүдә берләшмәсендә профсоюз эшен алып бардым. Өч чакырылышта авыл Советы депутаты итеп сайладылар.

Мәктәп елларыннан башлап үзем өчен генә шигырьләр, көлкеле хикәяләр, тәрбия һәм әхлак темасына мәкаләләр язу белән шөгылләнеп, мактау һәм рәхмәт хатлары еш алам.

## ГОМЕРЛӘРНЕҢ ҮТҮЕ...

Табигатьнең һәр мизгеле матур,
Көзе матур, матур кышы да.
Чәчкәле җәй, моңсу көзендә дә
Җирдә яшәү бәхет кешегә.

Гомернең дә була төрле чагы,
Кайчак була аның бураны.
Язы, көзе, чәчкәле җәйләре,
Мәңге истә кала торганы.

Җир ачылган түтәл эшкәртергә,
Түтәлләргә орлык төртергә.
Тизрәк үссен, диеп, су сибәргә,
Чәчкә атуларын көтәргә.

Мал карагач, аңа печәнен дә
Хәзерлисе җиңнәр сызганып.
Кыш ягарга утын әзерлисе,
Үзеңне тормыйча кызганып.

Кара миләш, кызыл миләш пешкән,
Шомырт пешкән диләр аланда.
Үз бакчамда үсмәгәннәренә —
Китәм чикләвеккә, баланга.

Җыйган җимешләрне эшкәртәсе,
Ашатасы күркә-кошларны.
Көнне төнгә ялгап, ял итмибез,
Шулай каршылыйбыз кышларны.

Җәй буена кышка әзерләнеп,
Мал асырап, кош-корт караулар.
Кичкә аякларың хәлдән тайгач,
Басалмаслык булып арулар...

...Әзерләнгән, бар да эшкәртелгән,
Хәтта күтәрелгән күңелләр.
Дүрт мизгел дә искән җилләр кебек,
Шулай үтә икән гомерләр.

*2005 ел*

## ТӨРЛӘНДЕРДЕМ

Дүрт балам да бер атадан —
Тик минем балаларым.
Бер үк казанда пешкән аш
Шул килеш ярамады.

Шуңа күрә казанымны
Тутырып аш саламын.
Ашны биш төрле итәлсәм,
Бик канәгать каламын.

Бүген җитештергән ашым
Барына да ошады.
Берсенә токмачын бирдем,
Берсенә шулпа-бәрәңге,
Берсенә ботка ясадым,
Берсе итен ашады.

Бишенчесе ирем белән
Безгә калган өлеш ул.
Анда: суган, сөякләре,
Туралмаган бәрәңгеләр,
Эрерәк токмачлары да
Безгә ризык тиеш ул.

Менә шулай биш порция
Аш пешә бер казанда.
Кемгә кайсын ашатыйм дип,
Төрләндереп бетердем дә...
Ни булса, шуңа канәгать,
Аптырарсың заманга.

## ОНЫКЛАРЫМ — МИНЕМ ШАТЛЫГЫМ

Биш оныка, бер оныгым —
Алар — минем шатлыгым.
Укып кеше булулары
Гомер үткәнгә ишәра,
Монсы — минем картлыгым.

Алтысы да зурәнкәй дип,
Зурәткәй дип торалар.
Озаграк очрашмасак,
Хәл белергә киләләр.

Айгөле беренче оныкк,
Гөл кебек көләч йөзле.
Улымның тәүге кызы ул,
Үзе бик туры сүзле.

Әнфисәсе дә бик матур,
Бик тырыш, җитез бала.
Читтән торып укый да ул,
Эштә дә алда бара.

Җитезлеге, тырышлыгы
Охшаган әнкәсенә.
Көләчлеге, шаянлыгы
Охшаган әткәсенә.

Ничек булса да килешә,
Сау-сәламәт булсыннар.
Уку һәм эшләре белән
Әткәй-әнкәйләренә гел
Шатлыклар китерсеннәр.



6 17

## СОЛДАТ ЕГЕТКӘ (Финатка)

Кемнәргә хатлар язасың,
Кем белән серләшәсең?
Күзләреңә генә карап,
Килә бер сөйләшәсем.

Туган йортың хәтердәме,
Нинди төшләр күрәсең?
Бик сагынган чакларым бар,
Килә сине күрәсем.

Күңелсез төш күрсәң, һич тә
Начарлыкка аны юрама.
Күкләр һәрчак аяз булсын,
Яман уйлар берүк уйлама.

Күз алдымнан һич тә китми
Елмаеп көлүләрең.
Кунакларны сокландырып,
Өздереп биюләрең.

Синең шулай биюеңә
Идәннәр селкенгәндер.
Шатлыктан да, сәләттән дә
Йөрәгең җилкенгәндер.

Ихлас елмаеп көлүең
Күңелләрне яшәртә.
Гаиләң бәхетле булып,
Һәрвакыт та уйнап-көлеп
Язсын бергә яшәргә.

## СУГЫШ ЯРАЛАРЫ КҮҢЕЛДӘ

Ой ул еллар бигерәк авыр булды,
Ашарга юк хәтта җитәрлек.
Кайнар суга он сибеп эчәбез,
Исәпләсәң исең китәрлек.

Мал карасаң тамак туяр иде,
Сыер карарга да көч кирәк.
Хәзергечә печән, салам юк шул,
Мал асыраучылар бик сирәк.

Тик бер йортта икмәк пешәр иде,
Бар авылга хуш ис таратып.
Шуны иснәп туйгандай булабыз,
Һәм иснибез шуны яратып.

Карлар эреп, балчык чыгу белән,
Черегән бәрәңгеләр җыябыз.
Шуннан пешкән күмәч, колачаны
Әле дә тәмледер дип тоябыз.

Кычытканы, балтырганы чыга,
Кузгалак һәм җиләк җыябыз.
Һәммәсен дә авыз иткәләгәч,
Бүген туйдык! — диеп куябыз.

Хәзер һич мохтаҗлык кичермибез,
Затлы киемнәр дә киябез.
Ни теләсәң шуны ашарга бар,
Аллаһка шөкер дип куябыз.

## УЛЫБЫЗ ХЕЗМӘТКӘ БАРА

Улым Армияга китә,
Ни генә уйламыйбыз.
Акыл-тәүфыйгын җуймасын,
Исән йөреп, сау кайтырмы?
Шулай дип уйланабыз.
Вакытлыча аерылсак та,
Тотлыга телләребез,
Уйлашабыз, борчылабыз,
Сагышлы күзләребез.
Кай арада үсеп җиткән,
Вакытның үтүләре.
Өзә инде үзәкләрне,
Аерылып китүләре.
Сагышлы да, ямансу да
Минутлар кичерәбез.
Әткәем, Әнкәем, диеп,
Өзгәләнеп торуларын
Тик искә төшерәбез.
Исән хезмәт итер диеп,
Үзебезне юатабыз.
Язмышларга риза булып,
Ил саклау изге бурыч дип,
Улыбызны озатабыз.
Гаделлекне якласын ул,
Туган илен сакласын.
Солдат намусын сатмасын,
Һәм үз йөзен акласын.

## РӘНҖЕТМӘГЕЗ АНАЛАРНЫ

Ана кеше һәрчак баласына
Тели бары изге теләген.
Йөрәк пәрдәләре ертылганчы,
Телгәләмәгез ана йөрәген.

Рәнҗетмәгез бер дә Аналарны,
Уйламыйча әйткән сүз белән.
Ана рәнҗемәс тә, каргамас та,
Тик яшь кенә чыгар күзеннән.

Түгелмәсә кайнар күз яшьләре,
Ул бит эчкә генә йотыла.
Җылы караш белән баш иелсә,
Барлык әрнүләр дә онытыла.

Әнкәйләрдән фатиха алмыйча,
Рәхәт күрермен, дип уйлаmaң.
Күңел төеннәрен чишәлерлек,
Йөрәкләрнең бозын эретерлек,
Әткәң-әнкәң исән вакытында,
Җылы сүз тап, улым, кыз балам.



## ДАМИР ХӘЙРТДИНОВ

Балтач районының Көнтүгеш авылында туган. Белгечлеге буенча агроном. Иҗат белән шөгыльләнү балачагыннан ук килә.

1978 елда яз көннәренең берсендә авыл мәдәният йортында язучы Руслан Мәксүтов, Агиш Гыйрфанов, Тимер Арыслан катнашлыгында үткән кичә күңелендә онытылмаслык тәэссоратлар калдыра. Өлкәнрәк классларда укыган чагында Көнтүгеш сигезьеллык мәктәбенең татар теле укытучысы Венария Шәвәлиева җитәкләгән «Яшь каләмнәр» түгәрәгендә шөгыльләнә. Язмаларын «Пионер», «Ялкын», «Башкортостан пионеры» кебек басмаларга җибәрә. Басмаларның әдәби хезмәткәрләреннән киңәшләр җиткерелгән җавап хатлары ала.

Һөнәри иҗат юлының башы 1992 елга туры килә. Шул елда «Азатлык» Балтач район гәзите редакциясенә хәбәрче сыйфатында эшкә алына. Иҗат җимешләре район, республика гәзитләре битләрендә басыла. Юмористик хикәяләре «Һәнәк» журналы битләрендә дөнья күрә.

2005 елда шигырьләре Бәләбәй шәһәрендә һәр ел саен үткәрелгән «Илһам чишмәләре» фестивале

нәтиҗәләре буенча «Йәйгор» җыентыгына кертелә. Район сәнгатькәрләре авторлыгындагы «Туган җирдә туган хисләр» китабында да аның шигырьләре бар.

Өйләнгән. Тормыш иптәше Алсу белән ике бала тәрбиялиләр. Кызы — Гүзәл, улы — Рузил «Баскычлар» төбәкара иҗатчылар конкурсында бер-бер артлы призлы урыннарга чыктылар.

## РЕКЛАМА

Рекламада күп төр азык
Этләргә-песиләргә.
Их, булсачы сыерга да,
Печән бетте. Нишләргә?

Берәү мактый күккә чөеп,
Шәп машина «Индезит»!
Керне ул да үзе генә
Юмыйдыр ла инде, кит!

«Чудо-йогурт»ны мактыйлар,
Элеп алып кашыкка.
Тәме белән тиңме соң ул
Без яраткан катыкка?

Парфюмерия дигәнең,
Рекламада төп тема.
Әйтерсең, аны алырга
Акча гел ага, тама.

Сыерыма азык бетте.
Сүз башында әйттем бит!
Реклама гәзите аша
Тәки печән таптым бит...

Рекламалы гәзитеңне
Берүк читкә ташлама!
Ялкытса да, биздерсә дә,
Кайчак кирәк реклама!

## БЕНЗИН

Тормыш кайчан җиңеләя?
Күрәзәчедән сора!
Монполистлардан халык
«Игелек» күреп тора.

Әнә килә автомобиль,
Төягәннәр ди алма.
Бензин хакы артыр әле,
Берүк запассыз калма!

Әнә килә автомобиль,
Төягәннәр ди чебеш.
Бездә дә бензинның литры
Доллар торачак имеш.

Әнә килә автомобиль,
Әрҗәсендә биш ир-ат.
Азсларда бензинга
Бөтенләй бетте чират.

Әнә тора автомобиль,
Әллә ватылды микән?
Багында булган бензинын
Урлап киткәннәр икән.

## МАЙМЫЛ ӘЙТТЕ КЕШЕГӘ

Әйттем, дөньяга килгәндә,
Булма! — дидем син, кеше.
Рәхәт җирдә җәнвар булсаң.
Маймылның юк бер эше.

Беләм, йонсыз маймылсың син,
Тәнең кычый, кашыйсың.
Көнләшкәндә миңа карап,
Түләп банан ашыйсың.

Мин салымнар да түләмим,
Менә, ичмасам, бәхет.
Кеше булып йөрисең дә,
Яшәр рәтең бармы хет?

## ИХ, БӨЛГЕНЛЕК, БӨЛГЕНЛЕК...

Кулымдагы балдагымның
Исемнәре Зәбирә.
Безнең колхоз сыерлары
Сөтне бигрәк аз бирә.

Безнең колхоз басуында
Эшләр бигрәк тә харап.
Агроном тора шаккатып,
Билчәннәренә карап.

Фермадагы унбиш үгез
Нигә мөгерди микән?
Мясокомбинат юлында
Аяк сузмаслар микән?

Кәнсәләрдә өч бухгалтер,
Бригадныйда учетчик.
Фураж бетсә нишләрбез, дип
Башын вата кладовщик.

Әнә килә автомобиль,
Төягәннәр буш капчык.
Орлыкка салган ашлыкны
Чүпләп беткән ди чыпчык.

Дуңгыз фермалары бетте,
Сарык та асрамыйлар.
Безгә эш хакын бирергә
Уйлап та карамыйлар.

Трактор, комбайннар иске,
Төзәтергә запчасть юк.
Чәчми, урмый яшәп булмый
Шунсыз авылга каюк.

## ЖУРНАЛИСТ ХАТАСЫ

Язарыма азык тапмый,
Аптырап бер калганда,
Телефоннан шылтыраттым
«Урал» атлы колхозга.

Бордым: ике, алты, өч
Һәм тагын тугыз, сигез.
Яңалыклар бармы сездә?
Зинһар, сөйләп бирегез!

Уңганнар бездә күп диләр,
Языйк шулар хакында.
Ашлык тазарталар икән
Ындыр табакларында.

Телефон аша ишеттем
Бер бухгалтер тавышын.
Бу сүзләрдән ныклап торып
Тойдым колхоз сулышын.

Мәгълүматлар туплангачтын
Мәкалә тиз язылды.
Бер колхозның уңганнары
Районга ук танылды.

Әйткәннәрен яздым бугай,
Булмады кебек хата.
Их, башыма тай типкере,
Язылмаган бер апа.

Мәкалә гәзиттә чыккач,
Менә купты соң давыл.
Кимсеткәннәр Хәмдияне,
Эшкә чыкмады авыл.

Соңрак Хәмдия турында
Яздым парча аерып.
Дәртләнде шуннан колхозчы,
Эшли хәзер каерып.



ӘДИС ЗИННӘТУЛЛИН

**Әдис Зиннәтуллин**

Чәчләрен артка тарап йөрткән, һәр хәрәкәте, сүзеннән әдәплелек, пөхтәлек бөркелеп торган бу кеше белән танышуыма 11-12 ел тирәсе бардыр. Ул «Кама таңнары» редакциясенә кунак кебек шигырьләрен алып килгән иде.

Әдис Зиннәтуллин редакция белән күптәннән бәйле, ул — район гәзитенең элеккеге хезмәткәре, әдәби сотрудникгы.

Ходай Тәгалә язу сәләтен биргән кешеләр бу «чирдән» барыбер котыла алмый, шулай ук Әдис агай да гомер буе эчтән генә уйлана, яза.

— Мине һәрчак кешенең тәгаенләнеше, бу дөньяда яшәвенең мәгънәсе, асылы уйландыра торган иде. Менә шул уйланулар шигырь юллары булып туды да инде, — ди Әдис Зиннәтуллин. Әдис Миңнегали улы дәһшәтле 1942 елның 30 апрелендә Илеш районының Буләк авылында дөньяга килә. Әтисе бу вакытта фронтта булганлыктан, Әдискә аны беркайчан да күрергә насыйп булмый — озакламый аның хәбәрсез югалуы турында язу килә.

Күп тә үтми Зиннәтуллиннар Краснокама районы Яңа Каенлык авылына күченеп килә. Әдис

агайның арытабангы бөтен язмышы шушы җир белән бәйле.

Урта мәктәпне тәмамлагач, ул Уфа статистика техникумында белем ала. Яшь белгечне Белорет районына җибәрәләр. Әммә ялгызы гына көн күргән әнисен кайгыртып, Әдис туган районына кайтырга карар итә. Ул вакытта Краснокама районы белән Калтасы районы кушылган чагы булганлыктан, кайтып Калтасыда статистика бүлегендә эшли башлый.

— Эш буенча редакциягә кереп йөри идем, ул чактагы мөхәррир Вагыйзь Хуҗин күтмәгәндә мине эшкә чакырды. Әдәби хезмәткәр булып, авыл хуҗалыгы бүлегендә алты елга якын эшләдем, — дип, ул елларны искә ала Әдис агай.

Ләкин язмыш дигәнең Әдис Зиннәтуллинны Нефтекама шәһәренә алып килә. Башта торак-коммуналь хуҗалыгы системасында, сөт заводында һәм аннары, лаеклы ялга чыкканчы, автозаводта эшли.

Лаеклы ялга чыккач, иҗат үзен ныграк сиздерә башлый да инде. Шулай итеп бер-бер артлы шигырьләр туа.

Әдис Зиннәтуллин 70 яшен билгеләде. Егетләр кебек җитез адымнар белән йөргәнгәме, аңа бу тиклемне бирәсе дә килми. Ничә еллар белсәм дә, Әдис агайның тормышка зарланганын ишетергә туры килмәде. Ә бит ул әтисез үскән, балачагы ачлык-ялангачлыкка туры килгән. Шушы зарлана, кешегә ачу тота белмәве, сабырлыгы, һәрчак яхшыга гына ышанып яшәве аны яшь итеп күрсәтә торгандыр да инде.

**Гөлнара Гыйлемханова, РФ, БР журналистлар союзы әгъзасы.**

## АВЫЛЫМА

Зәңгәр күкләр дә яктырак,
Син сайлаган урында.
Җырлар чыгарып яшәек,
Туган авыл турында.

Таңнар да сызылып ата,
Нурга балкый өйләр дә,
Сагыну хисләре иркә,
Без җырлаган көйләрдә.

Урамнар да ямь-яшелдән,
Хисләр җыела, арта.
Бер сөйләшеп утырулар,
Туган авылга тарта.

Гармун телләре дә көмеш,
Нурда күзләр чагыла.
Авылымны күреп туймыйм,
Йөрәктән җыр агыла.

## ӘТИЕМНЕ ИСКӘ АЛАМ

Өч яшемне тутырганмын,
Сугыш беткән көннәрдә.
Әти кайтуын көткәнбез
Бик сагаеп төннәрдә.

Күз яшьләре түгелүдән,
Җылы хәбәр килмәгән.
Әтинең ничек булуын
Беркем сорап йөрмәгән.

Әти күрмәгән буынга
Сугыш безне күчергән.
Авыр сынаулар килсә дә,
Халык батыр кичергән.

Җиңү өчен көрәшкәндә,
Әтиләр үлеп калган.
Әниләр яшьлеген биргән,
Безне ятимлек алган.

Һәйкәлләр биек булса да,
Бетерми сүзне сөйләп.
Әтиемне искә алам,
Герман җырына көйләп.

## ЕГЕТЛЕК БИТ ЯШЬТӘ ТҮГЕЛ

*Укытучым Рамазан Саматовка*

Сугыш ветераны инде,
Сиксән тулган, сафта әле.
Түр башында утыралмый —
Эшләрнең кызган мәле.

Ил турында кайгыртадыр,
Тынгы белми һич йөрәге.
Киңәшләре — алтынга тиң,
Тормышныңдыр ул терәге.

Үткәннәрне барлап яши,
Һәрберсенә юл күрсәтә.
Җиңеллекне сайламый ул,
Авырлыклар күп күрсә дә.

Үзе өчен бернәрсә дә,
Түрәләрдән сорап бармый.
Башкаларга ярдәм итеп
Йөресә дә әле армый.

Егетлек бит яшьтә түгел,
Күренә ул кылган эштә.
Рамазандай аксакаллар
Картаймый ул әле һич тә.

## НЕФТЕКАМАМ

Нефтекамам, язмышымның
Кылын тартып уйнадың.
Гел елмаеп кына карап,
Юатырга уйладың.

Яшәгән саен яшәрдең,
Дан артыннан кусаң да.
Матурлыгың илгә таныш,
Нефтьләрдән тусаң да.

Иркенлектә иркәләнә,
Киң Каманның агышы.
Тирә-яктан дуслар җыйган
Сандугачлар ярышы.

Киләчәгең чагылышын
Тирән уйлар киңәйтә.
Иҗатка кулыңны бирдең,
Рәхмәтен йөрәк әйтә.

## КЫЗГАНУ

Калыная кар катламы,
Кышның эшләре каты.
Хәтеремә килеп төшә
Колхозның мескен аты.

Корсагы карда йөзсә дә,
Калмый артыннан чана.
Эшли җан көчләрен биреп,
Күрмәгәч башка чара.

Соңгы сулышына кадәр,
Туктамас юлда кисәк.
Хуҗа тоткан дилбегәне,
Сыртында уйный күсәк.

Атка кызганып карадым,
Дәшми ул, әйтми сүзен.
Сабырлыгын җыеп алып,
Яшь атты ике күзе.

Йөкне күпме салсалар да,
Тибә белми тәртәгә.
Буйсынып башларын игән,
Түбән генә кәртәгә.

## ТЕЛӘГЕМ

Аякларым юк атларга,
Чыгалмадым мин ауга.
Күңел карый югарыга,
Менәргә тели тауга.

Язмыш колы түгелмен мин
Өзәм чылбырын тартып.
Ирешермен максатыма,
Таш кыяларны ватып.

Кояш яктырта йөземне,
Жәлләми сибә нурын.
Бу тормышта җиңү өчен
Миңа да бардыр урын.

Яулыйм иң зур биеклекне,
Утырмыйм ярдәм көтеп.
Йөрәгем типсә ашкынып,
Булыр киртәләр үтеп.

## САНДУГАЧЫМ

Сандугачым, көй тартасың,
Күңел кылын өзәсең.
Тавышың — диңгез киңлеге,
Үзең монда йөзәсең.

Сандугачым, очма ерак,
Кунчы безнең тирәккә.
Өзелеп сине тыңлармын,
Җанга дәва кирәккә.

Сандугачым, тынмый сайра,
Яшем акса да күздән.
Моңнарыңнан эри күңел —
Бозланган кырыс сүздән.

Сандугачым, яшә җирдә,
Матурлык күреп сөен.
Киләчәкне моңга бизәп,
Чыгарчы аның көен.

## КҮҢЕЛЕМ

Күңелем моңнар илендә,
Сайлый заман җырларын.
Вакыт белән дә сөйләшми,
Күрми маңгай сырларын.

Яшьлек белән бер өстәлдә
Ашый тәмле ашларын.
Бер карасаң, мактый башлый
Тауның кыя ташларын.

Сер бирмәгән мәңгелек тә,
Эзләп тапмаган көен.
Кире якка бер дә китми,
Чишелми калса төен.

Тукталып бер матур җырда,
Аны бик озак көйли.
Яшәү дәртенең янында,
Сүзне назланып сөйли.

Өзелердәй нечкә кылда
Калган кебек кайчакта.
Упкынга егылып төшми,
Җырлар кул биргән чакта.

## ЯШЬЛЕК НУРЫ

Чал чәчләрем, күренәсез,
Көзгеләргә карасам.
Яшьлек белән мин сөйләшәм,
Уйларымны барласам.

Сезне буяп яшеримме,
Кем соң каплаган көнне?
Яшьлек суза миңа кулын,
Ай да яктырта төнне.

Җилфердисез көзге җилдә,
Мин көтәм һаман язлар.
Яшьлек сибә миңа нурын,
Хәтердә калган назлар.

Серләрне сездә саклыйммы,
Гел аклыкка табынып.
Яшьлек килә ялкын булып,
Йөрәк яна кабынып.



НАЖИЯ БАСЫЙРОВА

Мин, Басыйрова Нажия Карам кызы, 1949 елның 2 февралендә (паспорт буенча) Краснокама районы Эритакталачык авылында туганмын. Чакмагыш сәүдә училищесын һәм Уфа сәүдә техникумын тәмамлап, 35 ел сәүдә өлкәсендә хезмәт итеп, хаклы ялга чыктым. Ә шигырьләр язу җене балачактан ук килсә дә, гел күңелемнән генә язып йөрдем. Иҗат өлкәсендәге казанышларым өчен «Замандаш» язучылар оешмасына һәм аның җитәкчесе Фәрит абый Суфияровка рәхмәтлемен.

## ТУГАН ЯК

Туган якка кайтам диеп,
Ашкынып тибә йөрәк.
Торган җирләрдән бигрәк
Туган җир кадерлерәк.

Кайтып җиттем туган якка,
Йөгердем болыннарга.
Яланаяк хатирәсен
Саклаган урыннарга.

Яшьли йөргән урманнардан
Җиләк җыеп кайтышым.
Битемне иркәли назлап,
Көнбагышым, арышым.

Тигәнәкләр берәм-берәм
Итәккә чигү чигә.
Бар да моңлы җыр икән бит
Туган як сөючегә.

## «ЗАМАНДАШ»КА

«Замандаш»ның мин бит әле
Бер кечкенә баласы.
Бар үсәсе, җилпенәсе,
Канатлар чыгарасы.

Канат чыгарып алгач та,
Килер күккә очасым.
Ай-кояшны, йолдызларны
Үбә-үбә кочасым.

Тик биектә озак тормам,
Җиргә килер кайтасым.
Яшел үлән өсләрендә
Мәтәлчекләр атасым.

Җир-ананың кодрәте зур,
Беләм тартып аласын,
Кара җирдә, кара икмәк
Ашап үскән баласын.

Ни дисәң дә, мин бит җирнең
Түгел үги баласы.
Изге җирдә туфрак булып,
Мәңгелеккә каласы.

Менә шундый уйлар белән
Хозурланып мин очам.
«Замандаш»ка гомер теләп,
Замандашларны кочам.



7 •

# МИЛӘШ

Бер төбәктә өч төп миләш,
Һәркайсының үз хәле.
Берсе кызыл, берсе сары,
Берсе ямь-яшел әле.

Кызыл миләш горур гына
Сарысына эндәшә:
«Кызарырга өлгерерсең,
Көнләшми генә яшә».

Сары миләш, кызарынып,
Яшеленә сүз дәшә:
«Яшел ул — яшьлек билгесе,
Кадерен белеп яшә».

Әнә шулай миләшләр дә
Киңәшләшеп кызара.
Ник соң җирдә адәми зат
Аңлашалмый үзара?

## ТАШЛАНДЫК ЙОРТ

Ташландык йорт кардан арчылган,
Күптән сүнгән утлар кабынган.
Тәрәз пәрдәләре ачылган,
Күрше-күлән белән йорт тулган.

Ник моңсу соң бүген өй эче?
Пышылдашып сөйли бар кеше.
Авыл очындагы бу йортка
Кайта, диләр, бүген бер кортка.

Бик озакка түгел — бер тынга.
Ярты гына көнгә, бер төнгә.
Йөгереп тә кайтмый, чабып та,
Кайтаралар аны табутта.

Туган туфрак, нигез кирәк шул,
Васыятьләрне үтәү — сирәк ул.
Соңгы васыять, дөрес, үтәлде.
Тик ташландык йорт гафу итәрме?

# МИН ТАШ ИНДЕ

В. Высоцкийга ияреп.

Мин таш инде хәзер, кеше түгел,
Таш язмышын үзең беләсең.
Бу юлларны укыганда, дускай,
Яшь аралаш миннән көләрсең.

Таш та түгел әле, таш кадерле,
Кешеләргә чыга кирәге.
Ташлар елый белә тетрәнгәндә,
Шартлап ярылганда йөрәге.

Таш түгел шул,
Әгәр вак таш булсам,
Ак юл булып тигезләнер идем.
Эрерәге булсам, йорт астына
Ныклы терәк булып нигезләнер идем.

Юк инде, юк, мин бер дүңгәк кенә,
Тота алмам кара давыл өермәсен.
Табынганга, абынганга мин түзәрмен,
Тик өстемә менеп кенә сикермәсен,
Һәм йөземә теш аралаш төкермәсен.

## ӨЙРӘТТЕҢ, ДИСЕҢ, БАЛАМ

«Шырпысыз ут тергезергә
Өйрәттең», — дисең, балам.
Сүнәр-сүнмәс утлар күрсәм,
Йөгереп шунда барам —
Сүндерә күрмә, балам.

«Сулардан коры чыгарга
Өйрәттең», — дисең, балам.
Су өстенә учак ягып,
Йөрәк җылымны салам —
Чылана күрмә, балам.

«Юлларыңда адашмаска
Өйрәттең», — дисең, балам.
Җиде юл чатына чыгып,
Яктыртып алдан барам —
Адаша күрмә, балам.

Бәхет гөлең түтәлеңдә
Чәчәк атса бер заман,
Ләйсән яңгырлары булып,
Керфек очыңа тамам.
Бәхетле булчы, балам!
Син бәхетле булсаң гына,
Мин бәхетле шул булам.

***

Минем өчен чыга торган кояш
Кайберәүләр өчен баеган.
Мин бервакыт аерылган идем
Көндез — кояш, төнлә — аеннан.

Үткәннәрем артта калды хәзер,
Киләчәкне инде сәламлим.
Ашыгыплар ала күрмә, Ходай,
Моң язарга биргән каләмең.

## ТУКАЙ – КОЯШ,
## ТУКАЙ – ҖИР ШАРЫ

Поэмадан өзек

Лә иләһи кәлимәсен әйтеп,
Малай чактан кигән түбәтәй.
Милләтемнең горурлыгы —Тукай,
Иҗат сөючегә — зурәтәй.
Ә мин аны бертугандай күреп,
Габдулла да димен, Тукай да.
Хискә тарып, күңел сынар чакта
Чыгып китәм зәңгәр тугайга.
Очратам да, әйтәм аңа болай:
— Син юл ярган илһам чишмәсенә
Табынганга шигырем языла.
И туган тел, и матур тел диеп,
Сабыем теле, күзе ачыла.
Шатлыклардан шашып яшәмәдең,
Бик газаплы үткән юлларың.
Шундый кыска гомер кичерсәң дә,
Күпме шигырь язган кулларың.
Шул кулларны кулларыма алып үбәм,
Алларыңа кырдан җыеп гөлләр өям.
Чаллар кергән башым түбән иеп,
Сау бул, Тукай, хыял тугаенда
Очрашырбыз әле, серләшербез, диям.
Аннан китәм Кырлай болынына,
Күбәләкләр белән серләшәм.
Урманында шүрәлене табам,
Су анасын күреп сөйләшәм.
Изге уйлар тагын алып китә
Печән базарына, Казанга.
Суктырам да атны, чаптырам да,

Соңламаска иде азанга.
Соңламаска иде... Сырхавыңнан
Ничекләр соң табыйм чарасын?
Сәгать суккан саен кыскарта бит
Яшәү белән үлем арасын.
Ах бу ютәл, кара елан булып,
Уралды шул аның муенына.
Җаны очты айга, ә гәүдәсен
Яңа бистә алды куенына.
Әмма җиргә Тукай җаны булып,
Һәр яз саен кайта бер тургай.
Барча коштан биегрәк менеп,
Сайрый кошкай, җырлап һич
туймый.
Сайра, кошкыч, сайра, йөз егерме
нәрсә,
Син бит кояш, син бит җир шары.
Кояш һәм җир арып туктаса да,
Тукай рухы мәңгелек югары.
Тукай — Кояш,Тукай — Җир шары.



МӘСҮФӘ ӘЮПОВА

Мәсүфә Әюпова Башкортстанның Борай районында Берләч авылында туган. 1979нчы елны Благовещен педагогия училищесына укырга керә. 1983нче елны туган авылында башлангыч классларукытучысы булып хезмәт юлын башлый. 1990—1995 елларда район мәгариф бүлегендә башлангыч сыйныф укытучыларының методисты булып эшли. 1991нче елны Бөре педагогия институтына читтән торып укырга керә. 1995нче елдан башлап бүгенге көнгә кадәр Борай өченче санлы мәктәбендә укыта.

Нечкә күңелле, шигъри җанлы. Ул үзенең эшен һәм туган телен, аның мәдәниятен, үткәнен ярата, дәресләрендә үзе иҗат иткән шигырьләрен балаларга сөйли. 8 яшеннән башлап шигырьләр, җырлар, бәетләр яза.

## КАРА МУНЧА

Исемең дә онытылып ята,
Тарих битләрендә күренми.
Кара мунча исләремә төшә,
Җылың җанда — һаман сүрелми.

Арып талганнар да сихәт алган,
Чирлеләре баскан аякка.
Кайберсенең беткән мохтаҗлыгы,
Мөгештәге тимер таякка.

Күпме бәбиләрне хәтерлидер,
Кара мунча — каен миллекле.
Бәхет теләп чапкангадыр инде,
Сабыйларың бар да игелекле.

Төтен тәме килеп бәрелгәндәй,
Булды әле менә тагын да.
Кара мунча беләнмиллектән соң,
Чәйләре дә тәмле табында.

Кара мунча синең каралыкка,
Тиң булырлык кара эзләдем.
Синнән алган аклык, пакьлыкларга,
Тиңләшерлек сафлык күрмәдем.

*2007 ел.*

# ЧҮП ШИГЫРЬ
# ҺӘМ ЧЫН ШИГЫРЬ

Китап кибетенә керсәм,
Сыгылган киштәләре.
Эй, эзләдем мин алардан
Фәһемле киңәшләрне.

Тукайны сорап карыймын,
Атнабай, Миңнуллинны.
Сатучы кызым күрсәтә
Китапханәгә юлны.

Кибет киштәсендә ятмый,
Алар тиңдер алтынга.
Еллар үтәр, һәрбер сүзе
Әйләнер тик ялкынга.

Борылдым да, киттем чыгып,
Юксынып сине, шагыйрь...
Су эчәсе килгән кебек,
Укыйсы килә шигырь.

Чын шагыйрьгә түгел сүзем,
Шигырьне «ясаучыга».
Шул юлларны укыганда
Ачу чыгаручыга.

Сыйфат дигәнне онытып,
Саны дигәнсең тулсын.
Мең шигырең чүп булганчы,
Бер шигырең чын булсын.

*Февраль, 2009 ел*

## ГОМЕР ЮЛЫМ

Ярты гомерем гамәл дәфтәремдә,
Яхшы-яман бар да җитәрлек.
Шундый дөрес итеп яшәсәм дә,
Хата анда исең китәрлек!..

Тумас борын карга сөйләгәннәр,
Шул каргадан бар да башланган.
Мин язмышка түгел, киресенчә,
Язмыш миңә үзе ташланган.

Ничек кенә тормыш сынамады,
Туры юлдан һаман барамын.
Карыным белән кардан шуышамын,
Борыным белән бозны ярамын.

Шул гадәтем өчен дошманнарым
Барыр юлга капкан куялар.
Мин елмаеп яшәгәндә — ачлар,
Мин еласам гына туялар.

Якыннарым минем киресенчә,
Мин елмайсам гына бәхетле.
Өреп кенә утыртырлар иде
Алтыннардан коеп тәхетне.

Калган юлым бәхетлерәк булыр,
Бар күңелдән шуңа инанам.
Дошманнарым калышмаслар миннән,
Якыннарым, берүк сез калмаң!

*2007 ел.*

## КЫЗЫЛ КҮЛМӘКЛЕ БАЛАЧАГЫМ...

Элеккечә инде дулкынланып,
Көтмимен мин сабантуйларын.
Ә шулай да шушы изге бәйрәм
Балачакка итә уйларым...

Сабантуйга диеп әнкәй миңә
Кызыл күлмәк текте бер чакны.
Көне генә туры килмәде шул,
Өскә яуды бозлар борчаклы.

Тешем тешкә тими өшесәм дә,
Күңелемдә бәйрәм шатлыгы.
Ә йөземдә минем, күзләремдә
Кызыл күлмәгемнен чаткысы.

Сабантуйда салкын тидереп мин,
Озак яттым урын өстендә.
Күлмәгемә яңгыр ява диеп,
Елап уянганмын төшемдә.

Мендәр сүрүеннән тегелсә дә,
Матур иде минем күлмәгем.
Шундыенча гүзәл киемне мин
Башка бер генә дә күрмәдем...

Хыялымда тугел, чынбарлыкта,
Эх, балачакта иде калырга...
Бозлы яңгырда да сабантуйга
Кызыл күлмәгемдә барырга!

*1979 ел*

## ӨЧ ТАГАН

Өч кыз туган — өч таган
Утырдык та бер заман.
Гәп сатабыз — фәлсәфәбез,
Бетәлми әле һаман.

Өч кыз туган — өч таган,
Безне хыял чорнаган.
Еллар үтәр, таган ныгыр —
Әңкәй шулай юраган.

Өч кыз туган — өч таган,
Йөрәкне тирән уйган.
Аерылгач та сагынам,
Сезне күреп кем туйган?!

Өч кыз туган — өч таган,
Бөтен кием тап-таман:
Берсе сары, берсе кара,
Берсе уртача булган.

Өч кыз туган — өч таган,
Күпме бәхет юралган!
Һәрберебезнен иңенә
Мәшәкатьләр уралган.

Өч кыз туган — өч таган,
Балачак яшьлек тәмам.
Әммә озак күрми торсам,
Тамактан үтми тәгам.

Өч кыз туган — өч таган,
Безнең дуслык сыналган.
Бер минутны әрәм итмик,
Сәгатьләр бит саналган.

Өч кыз туган — өч таган,
Олыгаябыз һаман.
Таганнар утырмасына
Ашыгам, сүзем тәмам.

*2004 ел*



# ТАҺИР МИНГАЛИН

Үзешчән композитор Таһир Вәсби улы Мингалин 1949 елның 28 февралендә Калтасы районының Яңа Актул авылында җыр-моң сөюче гаиләдә дөньяга килә. Әтисе гармунда уйный, әнисе Яңавыл районының танылган җырчысы була, аны хәтта Уфага, Башкорт дәүләт филармониясенә күчәргә дә димләп йөриләр.

Таһир да гармунда һәм баянда уйнарга бик иртә өйрәнә. Калтасы урта мәктәбен тәмамлагач, ул Түбән Тыхтем авылында сигезьеллык мәктәптә музыка укытучысы булып эшли башлый. Совет Армиясе сафларында хезмәт итеп кайткач, Бөре педагогия институтында укый. Институтта укыганда Таһир «Яшьлек» дип аталган ансамбль оештыра. Бу ансамбль республиканың бик күп районнарында чыгыш ясый.

Соңрак Таһир Вәсби улы Краснокама районында партия, профсоюз органнарында, мәгариф системасында эшли, үзешчән сәнгатьтә дә актив катнаша.Татар һәм башкорт җырларының халыкара «Дуслык җыры» фестивальләрендә катнашып, призлы урыннарны яулый.

1996 елда якташ шагыйрә Нәҗибә Сафина сүзләренә беренче җырын иҗат итә. Соңрак бу «Крас-

нокама җирендә» җыры районның гимны булып китә. Аннан соң Рафига Усманова сүзләренә «Күзләрең» җыры туа. Таһир Вәсби улы «Инеш» иҗат берләшмәсе шагыйрьләре белән хезмәттәшлек итә башлый. Нәфисә Нәбиева сүзләренә «Кодашым», «Яшик әле шатлык белән», Әдис Зиннәтуллин шигыренә «Җырлар язам» һәм башка әсәрләре дөнья күрә.

2006 елда Учалы шәһәрендә Марс Латыйпов истәлегенә багышлап оештырылган үзешчән композиторлар конкурсында «Милли рух өчен» махсус призына лаек була. 2006 ел йомгаклары буенча Краснокама районының «Ел кешесе» дип танылa.

Бүген Таһир Мингалин киләчәккә зур планнар, төрле конкурс-фестивальләрдә катнашу һәм җиңүгә ирешү ниятләре белән яши.


ӘЙ СА-ТЫН-ДЫМ А-ВЫ-ЛЫМ-НЫ, Я ШЕЛ БАБ-ЖА
ТУ-ГАН ЙОРТ-КА КӨН-ДӘ КАЙ-ТЫП КИ-ЛӘ-МЕН,
ГЕЛ-ZА-КЫ-РЫП ТО-РА-СЫН

# КОДАШЫМ
## Җыр

*Таһир Мингалин музыкасы*
*Нәфисә Нәбиева сүзләре*

Эй сагындым авылымның
Яшел бәбкә чирәмен.
Төшләремдә туган йортка
Көн дә кайтып киләмен.

*Кушымта:*
Эх, Кодашым-кояшым ла
Гел чакырып торасың.
Синнән киткәндә, сизмәдек,
Читтә гомер узасын.

Авылым яныннан гына
Ага җыр-моңлы Таныпп.
Сине сагынып яшибез,
Читләрдә ярлар табып.

*Кушымта:* шул ук.

Нигезләр арта авылда,
Яшьләр «оя» коралар.
Кайтып килик яшьлеккә, дип,
Еллар дәшеп торалар.

*Кушымта:* шул ук.


Мон-да Таң Җаралсу-ы-рәк Яр-су-ы-рак иөрәк-ләр
и-сә Җы-җы ши-фа-лы Җил тир-бә-ләләр ти-рәк-ләр.
КА-МА ТА-НЫП А-ГИ-ДЕЛ-КАЙ ЖЫР-ЛА-ПА-ТА БУ-ЯК-ТАН
МА-ТУР-Ы-РАК ЖИР КУР-МӘ-ДЕМ КРАС-НО-КА-НА ЖИ-РЕН-Н-ЭН.

## КҮЗЛӘРЕҢ
### Җыр

*Таһир Мингалин музыкасы*
*Рафига Усманова сүзләре*

Сизмәстән очрадың юлымда,
Чәчәкләр шәлкеме кулыңда,
Күземә тутырып карадың,
Нигәдер, күңелгә ярадың.

*Кушымта:*
Күзләрең-күзләрең серлеләр,
«Сөям», дип, шаяртып көлделәр.
Мәхәббәт утында янганын
Әллә соң күрделәр? Күрделәр!

Чәчәкләрең бүләк иттең дә,
Кулларыңны изәп киттең дә.
Газаплар утында яндырып,
Йөрәкне яралы иттең лә.

*Кушымта:* шул ук.

Чәчәкләр хуш исе бетмәсен,
Мәхәббәт гөлләрең кипмәсен,
Көт дигәч — көтәрмен,
Тик безнең йөрәкләр аерым
типмәсен.

*Кушымта:* шул ук.



8 17



## КРАСНОКАМА ҖИРЕНДӘ
### Җыр

*Таһир Мингалин музыкасы*
*Нәҗибә Сафина сүзләре*

Монда таңнар алсу(ы)рак,
Ярсу(ы)рак йөрәкләр,
Исә җылы, шифалы җил,
Тирбәләләр тирәкләр.

*Кушымта:*
Кама, Танып, Агиделкәй
Җырлап ага бу яктан.
Матур(ы)рак җир күрмәдем,
Краснокама җиреннән.

Монда җир дә юмарт(ы)рак,
Көләч(е)рәк кешеләр.
Җир астында — кара алтын,
Җир өстендә — башаклар.

*Кушымта:*
Дуслык җебе — нефть юлы
Шушы җирдән юл ала.
Татар, мари, урыс, башкорт —
Тату гаилә монда.



8 •



КАМИЛ ГӘРӘЕВ

Камил Гәрәев 1928 елның 17 ноябрендә Борай районының Картамак авылында туган. Урта мәктәпне тәмамлаганнан соң Тын океан флотында 4 ел хезмәт итә. Мәскәүдәге художество, Уфадагы режиссерлар мәктәбен тәмамлый. Җыр һәм музыка сәнгате буенча маһирлеге өчен Бөтенрусия дипломаты исеменә лаек була.

Язган әсәрләре Башкортстан, Татарстан республикалары вакытлы матбугатында басылып килә. Ул иҗат иткән драма әсәрләре буенча эшләнгән спектакльләр озын гомерле булдылар һәм төрле өлкәләрнең халык театрлары сәхнәләреннән төшми яшиләр.

## ӘБИНЕ ТАЛАГАННАР

Бәдриямал әбинең күзенә йокы кермәде. Булачак «бәхетле» минутларын күз алдыннан кичереп, төне буе уйланып чыкты. Үзе кебек озын гомерле сары самоварын берничә тапкыр җырлатып алды, ләкин ни чаклы гына ширбәтләмәсен тамагына үтмәс булды аның. Гадәте шул: шатлыктан да, кайгыдан да, берәр эш туса да йокысы кача. Төпчеге, Габделбәренең берничә тапкыр уянып:

— Әни, китәреңә бер атна бар бит әле, йокла инде, — диюенә дә кул селтәп кенә җавап бирде. — Рас кияү белән кызым чакырган икән, Сыбирлау тиклем Сыбирлауга да булгач, рәтлерәк күлмәк киеп барырга иде инде. Кешене хәзер бернәрсә белән дә шаккатыра алмассың. Шулай да киемең ялт итеп торсын. — Әби шул турыда уйлый башлады. — Ну Шәмсебәдәр күрше көнләшер инде. Минекеләр аныкы кебек түгел. Кияүкәем Иванны әйтәсе түгел. Зур бизнесмән диме, шунда... Кызым да шунда, акча тирәсендә бутала бугай.

Кодагый гына: — Кияү акча күп тапкач ни, әллә кем булып кылана.

Барбара кодагыйны әйтүем. Үткән ел баргач, кызыл постау күлмәге өстеннән зәңгәр камзул кигән булып, дәшмичә йөргән булды. Мин ничек кенә ярарга тырышсам да, - дирибинчә, дигән була.

Анның каравы балакайлары алмадай, мине өрмәгән җиргә дә утыртмыйлар. — Туктале, — диде әби нидер исенә төшеп, үзе артыннан килгән зур агач сандыгын актарырга тотынды. Ул аннан берсеннән-берсе асылырак берничә күлмәк тартып чыгарды. Бераз карап торгач, ул. — Бармый, модадан чыккан болар. Барбара кодагыйдан уздырырлык булмагач...

Кичә генә Шәмсебәдәр күршесе, яңа ачылган камерсия кибетеннән дүрт метр күлмәклек алдым, элекке коммунист, депутат — Саранов фирмир икән бит, шул ачкан, дип, кибетендәге байлык ушың китәрлек, дип мактап торды. Саранов әле Кәмирсиәнный тегү мәчтүрское да ачкан, имеш.

Әбиебезнең тагын бер төне йокысыз үтте. Тамагына аш үтмәс булды. Чыннан да, яңа кибеттә кеше әби уйлаганча гына түгел булып чыкты. Әби килеп керүгә кибет теге мең төрле азык-төлек, бизәнү,

ашамлыклары-ние бары бергә өелгән товарлар күреп, озак кына басып торды. Кеше күплегенең серен ул әле бераз гына арткан пенсия акчасына кайтарып калдырды. Алай дисәң, товарларга бәя бермәбер арткан да түгелме соң? Кыскасы, әбинең бу турында уйларга да вакыты калмады, чираты җитте. Шушы тиклем дә сылу кызны бу Сарановы каян тапкан икән. Кашы, күзе уйнап тора. Мондый олы күзле, нәфис гәүдәле кызлар Кавказ ягында гына була бит, ходаем! Бармаклары саен алтын. — Сезгә кайсын үлчәргә? — дип, ягымлы елмайды чибәр. Товарларга карап уйлануыннан сизеп, ике башына да тимер кагылган метр таягы белән бер өем товарга күрсәтеп. — Әнә, теге эрерәк чәчкәлесен, дүрт метр ярым, — диде әби. — Күлмәккә иде, чибәрем, — диде. Күршесеннән төгәл ярты метрга уздырып.

Әби әйтеп бетерүгә сатучы кыз товарның соңгы метрын тарта иде инде. — Бәрәмәч, нинди көчле икән, үлчәүләр бөгелә, сынмагае әле. Ярый, товары нык тагын, дип уйлап бетүгә, кәгазьгә төрелгән товар кисәге әбинең алдына шап итте.

Яңа ачылган капирация мастерскоена житкәнче гел уйланып барды әби. Анда да моңарчы күрмәгән чибәр кызлар җыелган, гел елмаеп кына торалар. Товарны да бик мактадылар. — Бик тә сәбримүн, — диләр ич. Тик үлчи башлагач кына, бердәнбер таныш, түбән өч карак Хәбир кызы Гөлгайшә әллә нишләтеп, җыерып-куерып үлчи башлады. — Бәй, бәй, әбекәй! Алъяпкычка да җитми ич бу, — дигән була, авызын турсайтып. Әби телсез калды. — Калдырсам я үз өстендәге кебек итеп тегәр, тәнемнең иң җаваплы җирләрен дә капламаса, Барбара кодагый алдында да хур булуың бар дип уйлады һәм ярый, яулыкка булса да ярар, — дип товарын кире алды.

— Таладылар, көпә-көндез, чырылдатып, тукмап та түгел, көлдереп тә, сөеп кенә таладылар, — дип әрнеде ул. Бүген дә тыныч кына йоклый алмады. Күзен йомуга әлеге олы күзле кибетче белән очраша. Анысы ялгаулы керфекләрен уйнатып, әбинең каршысына ук килеп баса. Озын тырнаклы бармаклары белән әбинең кесәсен актара башлый. Әби йөгерә, ә кул һаман да сузыла, имеш. Котылдым гына дисә, тегүче Гөлгайшә тешен ыржайтып каршыга килеп баса.

Таң атуга башы чатнап ярылыр хәлдә булса да, әлеге бәхетсез төенчекне кыстырып, түбән очта ялгыз яшәүче ахирәте Фатыйма карчыкка барырга чыкты. Хәеречире шуның белән бетә генә күрсен, ул андый догаларның рәтен белә ичмасам. Фатыймаларга җиткәндә әлеге капкадан чыгып килүче Шәмсибәдәр күршесен очратты һәм сүзсез генә карашып торганнан соң, талanучылар бер ул гына түгеллеген белгәч, шатланып китте әби.

Бу вакытта кибеттә чибәр кибетче, күңелле елмаеп, бу көннәрдә сул як кесәгә җыелган табышын саный иде.

## КЕМ УЛ?

...Кемнәрнеңдер җәберсенеп, кимсенеп яшәвен күреп шул кимсетелгәннәрнең тормышта әрнеп яшәвеннән ләззәт таба. Ул элек һичшиксез коммунист булган. Ул чакларда үз гөнаһларын партия итәге астына оста яшерә белгән. Партия билеты әле дә еракта түгел, алай-болай була калса атылып чыгарга уңай төштә генә саклана.

Ул иртә белән тышка чыккач, үзенең шул каһәрләнүчеләр

исәбеннән салынган ике катлы вилласының иң биек ноктасына карап соклана, клуб кадәр гаражына кереп, чит илдән кайтартылган берничә җиңел машинасының ялтыр капотыннан сыйпый да, чыгып күршесенең ярым җимерек көнкүрешенә карап елмая, тәне буйлап рәхәтлек каны тәгәри. Чөнки ул булдыра, ул «белдеклерәк», беркемнең дә киңәшенә мохтаҗ түгел, ярамыйга карамый. Күпме кирәк — үзенеке итә ала, аңа дөньяның мең төрле юлы таныш. Ул элеккеге коммунист, бүгенге «ирекле» таякка таянган тәҗрибәле демократ. Ә инде әҗәлең кытыкласа, син инде ул таякны аударырга тырышып кара!..

Ул сиңа кушылып хәзерге тормыштан «зарлана», хәтта президентны сүгә, думадагыларны эт итә, син күрмәгәндә читкә борылып, «пырх» итеп көлеп куя. Ул синең кешечә нечкә күңелле, ярдәмчел, бар булганына риза булып яшәвеңнән дә көлә, заманча яши белми, ди, тормышка карашы үзенчә: мәңге рәхәтлектә генә, кимендә ике гасыр даешь!

Ул синең атаңнан калган дүрт тәрәзәле иске өеңә тераn, кызыл кирпечтән ике катлы йорт

салып куеп, чиксез ләззәтләнү кичерә. Синең өеңдә ашарга сорап елаган сабый тавышы аңа симфоник оркестр музыкасы булып яңгырый, аңа рәхәт. Хәзер салмак атлап, күптән инде үзенеке иткән хөкүмәт «Волга»сына юнәлә, зур канәгатьләнү белән чираттагы «ауга» юллана. Бу вакыт гараждагы өр-яңа машиналар хуҗа кайтканны көтеп ял итә.

Син пенсия акчаңа тәгам эзләп йөреп, арып кайтып киләсең. Әле кайтып җитәреңә 3-4 чакрым бар, «Волга» чыжлап үтеп китә, кычкыртып куя. «Күрсен», — дидер. Сине утыртып вакланмас инде. Ул бит «эшем иясе». Башыңа мең төрле уйларыңны төяп тыркылдый бирәсең. Уйлар аңлаешсыз. Гел генә изгелекләр, юнәюләр генә көтә идек бит. Әллә нишләп дөньябызның арбасы тәгәрмәче кирегә әйләнә башлады. Патша заманасы кире кайтып, изүчеләр, изелүчеләр, байлар, ярлылар чоры кабатлана түгелме? Көннән-көн ишәя барган мәгънәсез күренешләр дә шул борчулы уйларның дәлиле булыр сымак тоела бара. Тормышыбыз болай бәхәсле барса, әлләни күрербез кебек. Борчылдыра...

# ШӘФКАТЬЛЕ ЖУЛИК

Сугыш туктауга икенче ел киткән иде. Әмма ачлык дигәннәре һаман да әле безнең йорт-җирдән аягын алырга ашыкмый. Бу чакта миңа ундүрт тулган иде. Күптән инде колхозда ат җигеп, үзем дә аттай җигелеп эшләп йөрим.

1947 елның марты миңа көтелмәгән бәхет китерде дисәм, ялгыш булмастыр. Ул шатлык Жулик белән бәйле. Ачлыктан алып калучы да шушы этем булды. Бик тә акыллы, булдыклы иде ул. Чын спортчы да иде өстәвенә.

Исеме Жулик булса да, беркемнең дә әйберсен урлаганы булмады аның.

Күңелләре, уй-хисләре изге кешеләргә өреп тә карамас иде. Өрү дигәннән, куян куганда өреп куар иде мәхлугың. Анысы инде кылыйкайны чаба алмас хәлгә җиткерү өчен генә. Бик тә акыллы иде шул. Аның белән ауга йөргәндә өчәр куян алып кайта идек. Ул еллардагы өч куян ите кеше тормышында нинди роль уйнаганын күз алдына китерү авыр булмастыр.

Әтисез һәм икмәксез, онсыз да ярлы тормышыбыз чорының бер көнендә, безне, ике авыл егетен, авылдан утыз чакрым ераклыктагы Агый-

дел буендагы Казанцево пристанена катнашазык алырга җибәрделәр. Арыш, бодай һәм башка төр ашлык катнашмаларыннан торган әлеге онны безгә һәр олау исәбенә ике центнер алырга кушылган иде. Атларыбыз шуннан артыгын тарталмас хәлдә булгандыр инде. Бик арыклар иде шул. Шушы хәлсез атлар белән алып кайткан фураж онын җан башына сирәк-мирәк 200 граммнан тараттылар.

Без Казанцево пристаненда. Документлар өчен конторага китеп барабыз.

Мартның соңгы карлары чана табаны астында ямьсез шыгырдый. Кинәт каяндыр килеп чыккан берәдәк этләр белән бәйләнәсе килмәгән Жулигым чанага ук менеп утырды. Ул җиңелчә ырылдаудан башканы белми иде әле. Без өстенә сарыга буялган тун кигән берәүне куып җиттек. Ул кеше башын горур тотып, утырган этемне күреп:

— Һи-и, шушы буламы эт. Йолкыш мәче баласы да аңардан аруырак ич, — дип Жуликны хурлап ташлады.

— Якын килә күрмә, ашар үзеңне, — дигән булам. Янәсе, усал ул минем Жулигым.

— Энекәш, — ди бу, — син бу этеңне миңа бир, ә мин сиңа күп

итеп тоз бирермен, — димәсенме. — Мин тоз складында мөдирмен.

Йөрәк җылынып китте «тоз» сүзен ишеткәч. Һе, ике ел тозсыз ашап яшәүне хәзерге чор кешесе аңына да китерәлми торгандыр. Без складтан икешәр центнер «отход» салып чыгуга әлеге сары тун безне көтеп тора иде. Аның тоз складына киттем. Складын ташка үлчим: түбәсе ябылмаган, тирә-ягы тизәк белән тулы. Склад кайчандыр коймалы булган, анда-санда яткан такта кисәкләре шул хакта сөйли. Мин бу күңелсез күренешне күзәткән арада сары тунлы хуҗа берничә хатынга юкәдән үрелгән кап тоттырып, тоз чабарга кушты, тегеләре тырышып-тырышып тоз вакларга кереште.

Мөдир миңа яртысы чылбыр, яртысы сүс баудан үрелгән бау сузып, этемне бәйләргә кушты. Минем Жулигым үз гомерендә бәйләү дигәнне күргәне булмагач, миңа сораулы күзләре белән карап шыңшыды да чәбәләнергә тотынды. Ә инде без кап тулы тозны чанага салып, кузгалып китә башлагач, Жулик үрсәләнеп еларга кереште. Йөрәгем бавыры өзелеп төшкәндәй тоелды. Чөнки этем елый-елый мине хаинлыкта гаепли кебек иде.



# АИДА ХӘЙРТДИНОВА

Аида Радиф кызы Хәйртдинова Балтач районының Көнтүгеш авылында туган. «Балтач таңнары» гәзите редакциясендә редактор урынбасары булып эшли. Күп еллар республикада нәшер ителгән басмалар белән хезмәттәшлек итә. Хикәя, нәсер, новеллалары «Тулпар», «Ағиҙел» журналларында, «Өмет», «Йәшлек» һәм башка гәзитләрдә әледән-әле дөнья күреп килә.

2009 елда Зәйнәп Биишева исемендәге Башкортстан «Китап» нәшрияты «Яшьләр тавышы» сериясендә Аида Хәйртдинованың «Яшьлек җырым» дигән тәүге хикәяләр җыентыгын чыгарды.

2012 елда республика яшьләренең «Йәшлек» гәзите редакциясе Башкортстан Республикасының Язучылар Союзы һәм Әбҗәлил районы башкортлары Корылтаеның башкарма комитеты белән берлектә үткәргән Рәмил Кол Дәүләт исемендәге әдәби премия лауреаты булды.

## СУГЫШНЫ ҮТКӘН...
### Новелла

Нуртдин, егерме бер яшенә холкы бозылган, юк-барга тиз кызып китүчән, юлында кем туры килсә, шуның белән эләгешергә әзер авыр кешегә әйләнде. Боларның барысына да ике ел да өч айга сузылган хәрби хезмәт гаепле. Сугыш шулай үзгәртте аны. Кыз бала кебек йомшак күңелле, кеше җанлы егет иде. Бер имгәк җанга әйләндерде язмыш... Сорап тормады... үткәннәре белән уртаклыгы юк хәзер. Шундый кеше идеме соң ул? Их, син, Чечня җире... Кемнәрнең чәчәк кебек гомерләрен өзмәдең дә, язмышларын җимермәдең, җаннарын, тәннәрен гарипләмәдең син?..

... Хезмәткә чакырылган яшь солдатларны дүрт айга хәрби күнегүләр курсы үтәргә җибәрделәр. Казармаларга урнашкач, һәркайсына мамык кебек йомшак, яңа гына күзләре ачылган мәче балалары таратып бирделәр. Нуртдинга үзләренең Акмуенына охшаган мәче баласы эләкте. Чем-кара мәченең муены ап-ак! Бәләкәеннән тереклекне яраткан авыл малаеның якын дусты өен, авылын сагынуларын да оныттырды. Көндезге күнегүләрдән

кайтуын күтәп ала, чыгып киткәндә аякларына иркәләнеп озатып кала Акмуен. «Үзегез белән йоклатыгыз, ашатыгыз, тәрбияләгез», — диделәр. Ай буе үзләре белән сыенып йоклаган мәче балалары солдатларга туганнары кебек якынайдылар. Ә бер көнне... җыеп тезеп бастырдылар да... мәче балаларының муенын борып үтерергә боердылар!... Риза булмады солдатлар. Нишләп тере җан ияләренең тотып тиктомалга гомерләрен өзсен алар?! Хәрби приказ хәрби приказ инде. Офицерлар көйләп тормадылар. Әнә, Нуртдин белән янәшәдәге кроватьта йоклаган урыс егете Евгенийны мәчесен ирекккә җибәрергә теләп казармадан чыгып йөгергәч, артыннан куып тоттылар да, өчәүләп асфальт өстендә аунатып типкәләделәр. Баш мие селкенеп, кабыргалары сынып, госпитальдә ятып та юнәлмәгәч, хезмәткә яраксыз дип табып, әнисе белән туганын чакыртып алдылар да, кайтарып җибәрделәр... Барсы да шуннан башланды...

...Кайткач, Нуртдинны айларга сузылган реабилитация курслары үтәргә чакырдылар. Әллә нинди курслар үткәрсәләр дә, күңел яралары уңалмый икән. Йоклаган җиреннән кычкырып сикереп торып,

өйдәгеләрнең котын алып, биздереп бетте. Яшәвенең мәгънәсен югалтты егет. Әйтерсең, күңеленә бер шайтани зат оялады. Адым саен йөрәгенә төрле коткы оялавын сизсә дә, берни кыла алмый. Армия хезмәтеннән читләшкән егетләр Нуртдинның кан дошманнарына әйләнде. Реабилитация курсын тәмамлап, кайтыр юлында автобуска керергә торганда очрашты ул Айнур белән. Нуртдинның әтисе ягыннан зур әнисе яшәгән авылдан ул. Малай чакларыннан җәйге каникул көннәрендә авылда бергә уйнап үстеләр. Елга буйларында су коендылар, балык кармакладылар, мал көтүләделәр, кич чыктылар...

Бер-берсен танып белгән җиткән егетләр кул биреп күрештеләр. Айнур югары уку йортын тәмамларга өлгергән. Хәрби комиссариат юлламасы белән кала дәваханәсенә медицина тикшеренүе үтәргә килгән икән.

— Да-а-а, күрәселәрең алда әле, брат! Син дә безнең кебек изелеп кайт әле, аннан сөйләшербез! — Күзенә кан сауган Нуртдин, Айнурга сынаулы карап, лач иттереп җиргә төкерде.

— Яраксызсың, дип таптылар... өч айдан билет бирәчәкләр...

— Сатып алдың, димәк! Сволочьлар сез! Күралмыйм синең кебекләрне! Югал күз алдымнан!

Йодрыкларын төйнәп танышы өстенә килгән Нуртдинны автобус ишеге ачылуын көткән пассажирлар арасындагы ир-егетләр тынычландырды... Инде басылды, дигәч тә Нуртдинның: «Чиртсәң, каны чәчрәп чыгарга тора, яраксыз дип таптылар, имеш, табалар инде, эзләсәң. Сволочьлар!» — дип ярсуы алгы урыннарның берсендә утырган егетнең йөрәген пычак белән телгәләгәндәй итте.

Ярый, операциягә кадәр кулланыр өчен табиб билгеләгән даруы янында. Тиз генә пакетыннан алып, үзе белән йөрткән шешәдәге суы белән йотып куйды Айнур. «Түз, йөрәк, түз!... Нуртдинны да аңларга була, ул бит сугыш тикле сугышның эчендә булган кеше...»

Автобуска кереп урнашкан пассажирлар арасында әлеге күңелсез вакыйгага карата фикерләр ишетелде. Кемдер оятсыз дип Нуртдинны әрләде, икенчесе, киресенчә, аның гаебе юк, дип мәгънәсез сугышка ләгънәтен белдерде... Айнурга карата сүз әйтүче булмады.

...Ел ярымнан балачак дуслары кабат очраштылар. Үзәк район дәваханәсендә. ВТЭК көнендә. Коридор тулы халык. Шәфкать туташы чыгып документларны җыеп алды, авыруларны чират буенча кабинетка чакырып алачакларын әйтте. Иркен коридорның көньякка караган тәрәзәсе каршында уйланып басып торган Айнурны таныды Нуртдин. Карашлары очрашкач, Айнур килеп күрешергә кулын сузды. Нуртдин... сул кулын бирде. Уң кулының терсәктән түбән өлешен берничә ай элек, егет үзе дә операция үткәргән көннәрдә циркуль пычкысына эләгеп өздерүен ишеткән иде Айнур...

Шул вакыт кабинеттан шәфкать туташы чыгып Айнурны чакырды.
— Бу егеткә нәрсә булган? — Нуртдин янәшәсендә утырган Айнурның авылдашы Сәлим карттан сорамый булдыра алмады.

— Дүрт ай элек йөрәгенә авыр операция үткәрде бит, үлемнән калды... Армиягә дә шул чире аркасында алмадылар. Тазалык юк хәзер яшьләрдә, ю-у-ук...

... Ишек ачылды. Аннан башын иеп Айнур чыкты.

— Нәрсә диделәр? Бирделәрме?

— Чират көтүчеләр сорауларын яудырдылар.

— Бирделәр... — Егет баскычка юнәлде.

Баскыч тәңгәленә җиткәндә, үзен Нуртдин туктатты:

— Ни, туган, теге вакыттагы сүзләр өчен кичер мине, зинһар... Белмәдем бит...

Менә миндә...

Айнур яшьлек дустының иңбашына кулын салып, учы белән кысты да: — Бирешмик, Нуртдин! Нык бул! Син бит сугышны үткән кеше! — диде дә баскыч буйлап алга атлады...



**РИМА КАЋАРМАН**

Рима Каһарман (Рима Вәлиева Каһарманова) Ырынбур өлкәсе Октябрь районында дөньяга килә. Балачагы Стәрлебаш районының Бакча авылында үтә. Карагош урта мәктәбен тәмамлый. БДУның филология факультетында белем алып, һөнәре буенча журналист сыйфатында хезмәт юлын башлый. «Балтач таңнары» редакциясендә җаваплы секретарь булып эшли.

2006нчы елдан иҗат итә. Хикәяләре «Тулпар» журналында, «Өмет», «Атна» һәм Татарстанның «Дулкын» гәзитләрендә дөнья күрде. «Юлдаш» радиосында хикәяләре эфирга чыкты. 2007нче елда «Өмет» гәзите үткәргән әдәби конкурста җиңү яулый. 2009нчы елда «Акчарлаклар» әдәби әсәрләр җыентыгында аның хикәяләре дөнья күрә.

Вәлиевлар гаиләсендә уллары Руслан һәм Илнур әдәбиятка мөкиббән. Илнур үзе дә каләм тибрәтә. Хикәяләре югары бәһаланды. Регионара «Баскычлар» әдәби иҗатчылар конкурсында — беренче, бөтенрусия конкурсында өч ел тоташ җиңүче исеменә лаек дип табылды.



9 17

# ЕРАК СӘФӘР МАҖАРАЛАРЫ
## Хикәя

Аккош авылы егете Фидратның һәр вакыйга үзәгендә кайнавы һәркемгә дә мәгълүм. Моңа авылдашлары күнегеп беткән.

— А как же без бит җитмешенче елларның асыл егетләре, — дип үзен прогрессның этәргеч көче итеп санады егет. Тик әйдәүчеләр дә төрлечә әһәмияткә ия. Нинди бәрелеш, тавыш, гауга булса да иң элек бу йомгакның очын Фидратның тырышлыгында күрделәр. Янә шундый гадәттәге авыл киче дә Фидратның актив катнашлыгыннан башка үтмәде.

— Гарьләнәм, Гатифәкәем, ишеттеңме, кичә клубта ике авыл яшьләре пыран-заран килеп сугышып киртәләрне сындырып беткән ди, — дип ишек төбендә үк «свежый» хәбәрен чәчте Мәрфуга. — Без яшь чакта мондый тәртипсезлек юк иде. Әй тәртипле идек, ата-ана тәрбиясеннән булгандыр инде, —дип тәтелди бирде. Эшнең нидә икәненә төшенеп тә өлгермәгән Гатифә исә күршесенең сүзен хуплагандай баш кагып: «Сөйлисе дә юк, әйкәем. Баланы нинди итеп үстерү

үзеңнән тора шул. Аңламыйлар бит, нишләтәсең инде. Исләренә төшәр, тик соң булыр, — дип иртән савып кергән сөтен сөзә башлады.

— Көндез йокласыннар, төнлә клуб җимерсеннәр... — дип сүзен төгәлрәк юнәлешкә җибәрергә исәпләде Мәрфуга.

— Эшләп үсмәгәч, дөньяның кадерен аңламыйлар, — дип әңгәмәне өзмәскә тырышып эшен дәвам итте Гатифә. Бу сүз боткасының игечиге булмасына ишарәләп Мәрфуга исә турырак яра салды: «Олы улың өйдәме? Әтисенә ярдәмләшәсе урынына йоклап ятамы, мин әйтәм?»

— Таң атәче белән тормас инде. Кичә печәнне китереп бетердек. Тәмам арытты. Җитмәсә танцысына да барды, — дип газизен аклагандай әйтә салды да, башына уй килеп, — Ник уратасың әле, аңлатып сөйлә, — дип куркулы катыш карашын күршесенә төбәде.

— Әй, таң атәче белән тормас инде улың үзе төн атәче булгач,— дип ул-бу булмагае дип хафага калган ананың күңелендәге учакка ялкын өстәп җибәрде.

— Кояшның беренче нурлары белән үк кеше тикшереп йөргән була. Апаңның улын Әдисне бел.



9 •

Авылның заслуженный сугыш чукмары, —дип Мәрфуганы сүзсез калдырырга теләде күршесе. Тегесе исә үпкәләгәндәй: «Кешегә яхшылык эшлим имеш. Уллары теләсә нинди юлга басмасын дисәң. Көт тә тор. Туры сүзле туганына ярамаган дигәннәре шул инде. Эчсен, чыдамаса кеше алдында йомышын йомышласын — бер кешегә ләм-мим әйтмәм моннан соң!— дип антына тугры булырына ышаныч белән чыгу ягына юл алды Мәрфуга. Бигрәк шәп иткән Әдис: Фидратларын укыткан әле. Барыбер акыл кермәс инде үзенә, дип үзалдына уйлады. Төнге мажараларның нечкәлекләрен сөйләп бетә алмавына гына бераз эче пошты пошуын. Тик ишекне шапылдатып япкач янә кереп сүзне дәвам итәргә тартынды. Фидратның ни сөйләгәнен дә ишетергә исәбе бар иде — барып чыкмады. Теге тавыкбаш бичә эшне бозды, дип каз куар өчен очына чүпрәк бәйләгән чыбыгын селтиселти Зинира апасы яшәгән авыл очына атлады. Каз бәпкәләре үлән ашасын, аларга ни булсын шул арада дип үзен тынычландырды.

Малик, Фидрат йорттагы куышында микән? Теге бичә әллә

ни сөйләнде. Кара әле, чык инде сараеңнан, — дип ирен ашыктырып кычкырды Гатифә. Икәүләшеп кушны ачулары булды, ни күзләре белән күрсеннәр: уллары ертык, пычрак киемдә аунап йоклап ята. Күз төпләре күгәргән, кыяфәт качкан, әйтерсең лә кемдер аягын аңа сөрткән диярсең.

— Ни булды?— дигән сорауга ул:

— Берни дә юк ла. Йокларга бирмисез, — дип мыгырданып, ертык чалбарын капларга тырышып борылып ятты.

— Ике авыл яшьләре сугышкан диләр. Нәрсә бүлештегез? — дип сүз кушты әни кеше.

— Әә, штакетник сугышы соңыннан гына булды. Анысы пуштяк. Теге мушкетерлар кебек кенә селтәнделәр, күңелсезлектән. Ә баштарак теге оч егетләре..., әй белмим лә. Әдис белән сөйләштек икәүдән-икәү, — дип юрганын башыннан ук ябып куйды. Әңгәмә дәвамы хәзергә юклыгын аңлап, ата-ана йортка чыкты. Тик кулга нинди эш барсын инде? Кирәк-ярак алыр исәптән түгел, улы әйткәнчә, төнге «мушлитерлар»ы кем икәненә төшенер өчен Гатифә кибеткә барырга булды: анда бар хәбәрне

беренчеләрдән ишетәләр бит, ачыклык кертерләр.

Монда хатын-кыз җыелышып гәпләшеп торган мәлендә бар нечкәлекләрен дә ишетеп булыр дигән уй белән килеп керде, әмма үзе хәбәрнең соңгы өлешенә генә өлгерде. Ни сәбәпле бу «бәрелеш» башланганын тикшерә иде халык. Шул чакны Әдис тәмәке алыр исәптән кибетнең ишеген ачты. Сүз ни хакта барганын аңлап ник килгәненә дә үкенде булса кирәк. Хатыннар исә аны сырып алып сораулар яудыра башлады. Әдиснең йөз-килбәт бары да урында, тик кәефе генә бераз кырылган иде. Нидән ихтирам итү, итмәү соравы кузгатылганын, ничек башланганын хәтеренә төшерүе читен булды баһадирга.

— Әллә, без бильярд уйнаганда теге «кыстыбый сыныгының» күз карашы ошамадымы. Юк, атлавы бугай, — диде Әдис, җилкәсен кашып.

— Бәй, Фидрат чатан булгач аның атлавы, билдәле, бер төсле инде,— дип көлеп җибәрде берикесе. Гатифәне төркемдә кинәт күреп алгач кына алар җитди кыяфәт белән хәтерләренә нидер төшкәндәй кибеттән чыгарга ашык-

тылар. Әдис: «Бераз төшергән идек. Нидән башланганын хәтерләмим. Кулда бильярд таягы иде. Кемдер штакетник алып керде. Соңыннан башкалар кушылды. Әй, хәтердә юк, мин егылгач кемдер колакка басты, әле һаман авырта. Ә кем икәне искә төшми...», — дип бар сорауларга җаваплагандай тәмәке тартасы килүе дә басылган килеш кибеттән югалу юлын карады. Мәрфуга исә каз куа торган чыбыгын кулында боргалап ата-ана тәрбиясенең мөһимлеге хакында сүз кузгатуы белән Гатифә дә кайтырга ашыкты. Мәрфуганың каз бәпкәләрен карга да алмый ичмасам, таягын тәрбия үрнәгедәй бар җирдә селкемәс иде дигән шомлы уйлар аңа тынгы бирмәде.

— Малик, дим, икәүдән-икәү сөйләшүләре хәтәр булгандыр боларның. Фидратыбызның өсбашын күрдең, ә Әдиснең бите дә чыелмаган ичмасакаем. Башка авыл яшьләре ни эзләп килгәндер — анысында эшем юк. «Мушлитерларын» да аңламадым. Тик моны болай калдырырга ярамый, — дип улын дәвалар өчен кирәк-ярагын әзерләп, уфтанып сүзен башлады Гатифә.

Ә Фидратның исә бер дә исе китмәде: «Печән өсте тәмам,

бәйрәм иттек шатлыктан. Җитми калгач бер яртыга тагын барып килдем. Нурмасы артып киткәндер, чамасызга әйләнгән. Юк белән башыгызны катырмагыз әле, зинһар өчен».

Җитми имеш, ник Әдис алдында парадтагы кебек тилтак-милтак таптандың. Аңа йөрешең ошамаган да. Ә киемнәреңә иптәшләрең бергәләшеп аякларын сөрткәннәр диярсең — карарлык түгел, — дип сыкранды ана.

Йөрешем ошамаса арты белән утырсын иде. Минем кием генә, ә җае чыккан арада үзем Әдиснең башына да бастым, урынын белсен хәчтерүш, дип.

Кара аны, монысын беркемгә дә ләм-мим. Аның колагында ботинка эзең калмагандыр, иллә-мәгәр зарланды, ә кем басканын хәтерләми. Телең тик торса, башың исән булыр, — дип Гатифә улына кат-кат кабатлады.

— Ярый, әнисе, улың дөрес әйтә. Бәйрәме дә, бер-берсенең тузанын кагу да үткән эш. Юкка тавыш куптармыйк. Калганы пуштяк, баш исән булсын, — дип Малик улының һәр сүзен хуплады. Бар хәлнең җавабы билгеле иде — салып алгач инде ул кем белән ни булмас...

Авылның тормышы үз дулкыны белән салмак кына үтә торды: хуҗалык эшләре, бәйрәмнәре, мәзәкләре. Төрле вакыйгалар кемгәдер кызыклы кушаматны мәңгелек юлдаш итте. Фидратның һәркайда кысылышы, нинди дә булса мөнәсәбәте булуына авылдашлары күптән күнекте. «Исемен Хикмәт дип кенә кушасы калган», — дип көлешүләренә бер дә хәтере калмады. Сөйли бирсеннәр, әгәр мин булмасам, авылның күңелле җырга тиң мәзәкләре бетәр иде, дип горур булды. Һәркем аның белән кызыксынуы үзен авылның асыл егете итеп тоярга этәргеч бирде...

Кысылмаган эше, тукмакланмаган җире калмады. Тик берничә дә исе китмәде, ачу сакламады. Теләккә ирешү өчен йөз кызару, күз күгәрү гадәти хәл кебек тоелды аңа: күңел төшенкелегенә урын юк — һәрчак вакыйга үзәгендә булды.

Автомобиль водительләре әзерләүче мәктәп, ягъни курсларда белем алганнарны берничә айга төрле төбәкләрдәге заводларга җибәреп практика үткәрү гадәти хәл кебек иде. «Бердәмлек» колхозыннан егермеләп ир-ат бу һөнәрнең асылын теориядә өйрәнгәннән соң,

Мәскәү шәһәрендәге заводка практика үтәргә юнәлтелде. Юллама буенча өч айлап башкалада эшләп кайтырга тиеш иделәр алар. Ике дистә ир-ат өчен гаиләләреннән аерылып читтә яшәү үзе бер сынаудай тоелды. Әйтүе генә ансат: туган авылларыннан бер адым да чыгып йөрмәгән кеше өчен бу сәфәр имтиханга тиң эш. Әмма Фидрат моны мавыктыргыч сәяхәттәй кабул итте. Ул-бу булмас — якташлар янәшәдә генә, ә нинди мөмкинлекләр ачыла дигәндәй күңеле аны Советлар Союзының башкаласына әйдәде... Ул елны көз башы белән суыклар башланды.

Юлга чыгасы көнгә барысы да җитди әзерләнгән. Поезд белән барганга күрә сумкаларына күпләп ризык тутырганнар. Өр-яңадан киенгәннәренә генә Фидратның эче пошты. Кәләш сайларга баралармыни, диярсең. Төрле төсле курткалар кигәннәр. Балонь дип аталган тукымадан тегелгән, имеш — әтәч тиресе җылысы да юк, күрмәгәннәрен күреп, туңып кайтачакларын көт тә тор. Фидрат шул уйларына бирелеп үзенең яңадан килешле, ачык зәңгәр төстәге сырган фуфайкасының сәдәфләрен җайлап сыпырып куйды.

«Без авыл малайлары. Ялтыр-йолтырга кызышырга саескан түгелбез ласә, Әдис әйдә тыштан ялтырасын, кайтканда суыктан калтырамагае» — дип уйларына үзе көлемсерәп куйды. Ә юлдашлары исә Фидратның кыяфәтеннән төртмәле сүзләр белән көлделәр. «Хыяллар тормышка ашмас инде, Мәскәү кызлары синең арканда безгә «маһ» бирмәсләр. Фуфайкаң белән арттарак йөре инде. Әйберләребезне күтәрүче грузчик диярбез», — дип бер-берсенә күз кысышып хихылдадылар.

Томана, син үзең грузчик, швейцар дип әйт, — дип күп белгәненә басым ясап, теш арасыннан фырт итеп төкерде Фидрат, аларга юлда күп яңалыклар сөйлиячәген күзаллап. Гәзит тә укымыйлар бит ичмасам, аның кебек күп белерләр иде...

Ә син Швейцариядән түгел дә, ул исем белән сиңа дәшәргә, — дип Вәрис акыл сатмакчы иде, шул мизгелдә автобус килеп туктады. Якыннары белән хушлашып авылдашлар юлга чыкты. Вакыт поездда озак үтә диюләре буш сүз булып чыкты. Кәрт сугып, авыл хәбәрләрен сөйләп бара торгач, Мәскәүгә дә тиз килеп җиттеләр.

Гомум торакта урын бирделәр. Тик практика үтәсе заводка гына троллейбуста барырга туры килүе кәефләрен бераз кырды.

Хәтәбе җәяү йөрерлек ара булса иде, —дип көрсенде Вәрис.

Авылдан район үзәгенә кадәр җәяү барган кебек була бит. Бу араны җәяү йөреп, юлга тиешле акчаңны аерым салып бар да, берәр «акбаш» алырбыз, — дип үзенчә бик шәп фикере белән уртаклашырга ашыкты Фидрат.

Юк инде, бергәләшеп җәяү йөресәк кенә, — дип кырт кисте Вәрис. — Мин җәяү йөрим. Ә син акчасына эч имеш. Башың түгәрәк икән.

Экономиянең бер акыллы максаты булсын дип әйтүем генә. Җәяү йөресәң сәламәтлегеңә дә файда, безгә дә. Үзеңнең башың да шакмаклы түгел дә рахитлы баланыкы сыман. Баш турында ачыш ясыйсың...

Егетләр, читтә барысы да чутлы. Сүз көрәштермәгез. Җәяү булмас, бергәләп укырга йөрербез. Монда кесәләрне кисүләре бар. Бердәмлеккә ни җитә, — дип карашы белән очкын чәчеп торган Вәриснең фикерләрен чуалтты Зөфәр...

Икенче көнне таң атканчы тукталышка тезелде егетләр. Бергәләп йөрергә теләп, адашып торып калудан шөрләделәр. Унберенче троллейбус ерактан күренүе белән дулкынланды алар. Ишекләр ачылу белән чыгасы пассажирларга юл бирмичә, Берлинны алучылардай, бер тында троллейбуска кереп тезелде егерме ир-егет. Каушап калган чыгасы пассажирлар тавыш-гауга куптарып, тиргәшә-этешә, көч-хәлгә биредә төшә алды. Арада бер хатын-кыз юлына аркылы төшкән Фидратка: «Неотесанный деревенщина», — дип ачулы мөнәсәбәтен күрсәтеп әйтә салды. Үзе киләсе тукталышка кадәр барырга ниятләде булса кирәк, элекке урынына фырт кыяфәттә барып утырды.

— Күрдегезме, әпәт миңа күзе төште инде, — дип Фидрат әйтүе булды, авылдашлары бертавыштан кычкырып көлеп җибәрде. Аңламаган телдә сөйләшкәннәргә ханым сер бирмәскә теләп борынын чөеп бара бирде. Салондагы кәефне җайлау исәбе белән троллейбус водителе магнитофонны кабызып җибәрүне хуп күрде. Ят көй агыла. Ә Фидратның кәефе күбәләктәй очарга әзер. Мәскәүдә беренче көн

бит. Көйнең һәр дулкынына кушылгандай ул дирижерлар ясаган хәрәкәтләрен хәтерләткәндәй итеп бармагын селтәп барды. Бу исә аңа кычкырган ханымга үтә ошамады булса кирәк. Ачы алма капкандай кыяфәттә бара бирде ул. Фидратның болай кул болгавыннан башка пассажирлар исә ихлас көлделәр. Эшләренә барып җиткәнче йокылары да тәмам ачылды...

Уку, эш баштарак бар вакытларын алса да кайтырга чамалы вакыт калгач кемдер беренче булып башкала кинотеатрлары, музейлары, һәйкәлләрен күрү теләген белдерде. Мәскәүгә килеп магазиннарда йөреп, ГУМдагы фонтанны гына күрүләре хакында әйтсәләр авылдашлары гына түгел, сарайдагы әтәч көләр дип фикерләштеләр. Күпләре өчен музейга караганда сыра эчә торган барга бару мавыктыргычрак тоелды, әмма бу вакыт эчендә элекке гадәтне куганнар водитель таныклыгы алмаячагын кисәтүләре тылсымлы камчыга тиңләште. Тәмам «үзәкләре көйгәннәр» кайтасы көннәрен бармакларын бөкләп саный-саный көттеләр. Фидрат идеяны күтәреп алып барысын да музейга әйдәде. Кемдер «Ватык чүлмәкләр» күрәсем килеп тормый

дип, тәгәрмәчкә таяк тыгарга тырышты, әмма зур эрудициясен ассызыкларга җай тапкан Фидрат өзмәде дә куймады, ай-вайларны калдырып, бергәләшеп мәдәни походка чыктылар. Метрода барганда Фидрат көз суыгына бирешкән якташларына төртмәле сүзләре белән чагышты. «Озакламый кышка аяк басабыз. Матур килеш туңасыларыгыз алда әле», — дип элекке төртмәле сүзнең «сдача»сын кайтарырга тырышты. Бер шәһәр эче булса да тәмам ерак араны үтеп музейга килеп җиткәндә өшегән авылдашларның кәефе кырылып өлгерде. Фидрат кына сөйләнүен, көлүен, биргән сорауларына үзе җавап кайтаруын дәвам итте. Арыган якташларының аңа исләре китми иде инде, вулкан, цунами, җир тетрәүдән качып котылып булмагандай, страус кебек башны комга тыгып качып булмый.

Фидрат белән көрәшү тәмам мәгънәсез эш, сөйләсен, хәле беткәч тынар әле дип сабыр итеп көттеләр.

Музей бинасына керү белән күңелләре дәва тапты, тәннәренә җылы йөгерде. Гид ханым һәр экспонат хакында озаклап сөйләп барды. Аны бүлдерә-бүлдерә Фидрат сораулар бирде, кызыксынуын

күрсәтте. Кайчан бу «мәдәни агарту эше» ахырына җитә инде. Тәмам арыган Зөфәр: «Җитәр инде, тавык кырындагы әтәч кебек канатыңны җәймә. Артык кызыксынасың имеш, ул барыбер синең белән авылга кайтмас. Туктат допросыңны, — дип сораулар әзерләгән Фидратның кабыргасына төртте. — Мамонт сөяге белән тамак туймый, ачыктырды».

Үзенең кызыксынуы белән ханымның ихлас әңгәмәдәше булып өлгерсә дә, булачак водительләрнең кәефләрен кырудан тартынды авыл эрудиты. «Сезнең өчен тырышкан баш. Үзем ул сөйләгәннәрнең барысын да беләм. Хәтерегездә калсын дип сораулар бирүем инде»,—дип өстен чирттерде үзе музейдан чыккач.

Мәскәүдә булып әйдәгез әле монау заманча ашханәгә керәбез,— дип Вәрис игътибарны үзенә җәлеп итте.

— Бу ресторан бит. Бер кереп ашасаң авылыңа поезд артыннан җәяү кайтуың бар, — дип Әдис ачыклык кертте.

— Нигә, без бит анда «Әпипә» көен заказ буенча уйнатмыйбыз, ашап кына чыгабыз, — дип үзенә ышанган кыяфәттә Фидрат ишекне

ачып кереп үк китте. Бергә булу нияте беләндерме, иллә-мәгәр бу юлы икеләнеп, кире үгетләүче табылмады, барысы да сүзсез аңа ияреп керделәр. Ишек төбендә сәлам биреп торган матур пиджак, фуражка кигән олы абзый үзенең урынын калдырып гардеробка атлады, кешесе сорап киткәндер, бәлки. Ул кулындагы «печатка» йөзеген ялт-йолт китереп егетләргә сан сугылган пластмасса шакмакларын суза торды, тегеләрнең киемнәрен җитез генә гардеробка урнаштырды. Ниһаять, Фидратның чираты да килеп җитте. Ул фуфайкасын салып аңа сузды, әмма ыспай киенгән абзый бу киемгә күз ташлап, «номерогын» Фидратка бирергә ашыкмады. Кәрәсе егетләр туктапып аны көтә бирде.

— Возьмите! — дигән сүзләренә дә колак салмыйча «җылы урындагы абзый» карашын читкә борып, фуфайканы этеп куйды.

— Не принимаем, — диде ул кырт кисеп авыл кешесенең мескенлеген ачкандай. — Это не одежда.

— А шту же тогда? — дип нәфрәттән яшьләнгән күзләрен Фидрат аңа төбәде.

Сүзсез генә тегесе мыскыллы көлеп куйды. Бу кыяфәте белән бер

дә гарьләнә белмәгән Фидратның күңеленә хәнҗәр кадавына төшенмәде фырт киенгән кеше. Авылдашлары да тынсыз калды. Фидрат шул мизгелдә фуфайкасын борып чүпчар өчен куелган урнага бәреп, чатанлаганын сиздермәскә тырышып, ресторанга таба атлады.

Чәчләренә чал кунган, ә акыл заты да юк. Кеше үзе түгел, аның өстендәге чүпрәк киеме моңа важныйрак имеш, — дип ярсуын баса алмый кабатлады ул. — Күркә кебек киенеп баскан да важный птица булган. Менә шул инде швейцар, күрдегезме кешене сортларга бүлүчене? — дип авылдашларына очкынлы карашын төбәде. Тәмам кәефе кырылган, мәңге күңелчән авылдашы өчен аларның да эче пошты. «Ярый, аңламаганы өчен әпи шүрлегенә менеп төшеп авылдагыча простуй гына аңлатып булмый инде — Мәскәүдәбез бит, җәмагать», — дип Әдис тә тынычландырырга тырышты авылдашын. Хәер, йодрык белән проблемаларын хәл итеп өйрәнгән адәмгә үтә тынычлану өчен бара торган сүзләр иде бу.

— Күңелемне челпәрәмә китерделәр, егетләр, ашагыз. Миңа карамагыз, — дип Фидрат бер почмакта урын алды. Көн дөрес түгел агыш

белән баргандай тоелды аларга. Бу юлы киресенчә, үзләре Фидратның күңелен күрергә тырышып, шаярып та карадылар, әмма фәтүә булмады. Тукланып чыкканда швейцар яңа кергәннәрне хезмәтләндерә бирде. Барысы да киемнәрен алганчы Фидрат урамда көзге салкын җилгә чыгып баскан иде. Чүп-чар савытыннан аның фуфайкасын Вәрис алып чыгып хуҗасына суздысы. «Юләрләнмә. Беткә үч итеп, тун якмыйлар. Барыбыз да кайткач фуфайка киеп кыш чыгабыз», — дип Фидратны җиргә төшерергә тырышты...

Санаулы вакыт үтеп тә китте. «Бердәмлек» колхозыннан килгән ирләр шофер таныклыгын кулга алып кайтырга чыкты. Мәскәүгә килеп, бераз яшәүне кемдер язмыш бүләгедәй кабул итте, ә Фидратның монда күңеле тирән җәрәхәт алды. Әмма бу хәл ирләр арасында бер сер булып калды. Һәркем авылдашлары белән сәяхәт тәэссоратларын урталашырга ашыкты. Кайда да булса, башкала хакында сүз чыкса, Фидрат: «Син миңа Мәскәүне сөйләмә инде»,— дип бу шәһәрне биш бармагы кебек белүенә басым ясарга яратты. Әйе, нәкъ бу шәһәр белән

бәйле күп хатирәләр аның йөрәгендә урын алды. Күңел — пыяла, дигән хакыйкатьне дә башкаланың контрастлы тормышы аңа ачып салды...



**ФИРҮЗӘ ИБАТУЛЛИНА**

Фирүзә Фәрхи кызы 1970 елда Игезәкләр йолдызлыгы астында Тәтешле районы Салаевка авылында туган.

Урта мәктәпне күрше Бәдрәш авылында тәмамлый. Казан дәүләт университетының филология факультетында укый.

Белгече: татар теле һәм әдәбияте укытучысы.

Хезмәт урыны: «Халыкны социаль хезмәтләндерү үзәге»нең хатын-кызларга ярдәм итү бүлеге мөдире, хатын-кызлар советы әгъзасы.

Җыр-моң әйләнәсендә үскән Фирүзә Фәрхлисман кызы туй һәм юбилей кичәләре дә алып бара.

Тормыш иптәше Ильшат белән ике ул, ике кыз тәрбиялиләр.

## КАЙТУ
### Хикәя

Шатлык һәм кайгы. Гади сүзләр. Ләкин шушы гади сүзләрдә никадәр төрле мәгънә.

Шатлык, оча-оча, канатларын җәеп зәңгәр күк йөзендә бөтерелде-бөтерелде дә, бик матур ихатага тукталды. Әйе, күптән, бик күптән бу йортның ишеген какканы юк иде. Шатлык пәйда булган йорт — Сәлимә әби өе. Гомере буе инсафлы, изге күңелле, сабыр, эш сөйгән кеше булса да, нигәдер гел кайгыдан гына торды бичара Сәлимә әбинең гомер юлы.

Бөек Ватан сугышында өч улын, сөйгәне Бикмулланы югалтты. Әй, ул замандагы әрнү, сагышлар, көнне төнгә ялгап эшләүләр. Юк, Сәлимә елап, кул кушырып утырмады. Йөрәге сыкраса да, илгә килгән афәт, миндә генә түгел, дип, гел үзен юата килде. Үлгән артыннан үлеп булмый, нишлисең, тәкъдирләре шулдыр күз нурларымның, дип, ялгыз ана, тол хатын язмышына буйсынып яши бирде. Язмышын сынап, икенчегә кияүгә чыкты. Бичара Хәлимҗан белән дә озак яши алмадылар. Сугыш яраларыннан ул да гүр иясе булды. Хәлимҗан төсе

булып аннан туган улы Галимҗан гына калды.

Шатлык булып шушы Галимҗан кайта бүген Сәлимә әбинең йортына. Күптән, бик күптән кайтканы юк иде Галимҗанның. Әллә юлы төшмәде, әллә килене башка милләтнеке булганга улына кайтырга юл бирмәде. Югыйсә бит, Сәлимә карчык бер кәлимә рус сүзе белмәсә дә, марҗа килененә, «кызым, кызым», дип өтәләнеп торды. Киленемә генә дип мамык шәлләр, ап-ак йон оекбашларын бәйләп бүләк итәр иде. Өстәленнән каймагы, катыгы, өчпочмак, бәлешләре беркайчан да төшмәде. Гомер буе авылда яшәгән карчык үз тормышыннан бик канәгать иде. Ә менә килен карчыкны өнәп бетмәде. Ул пешергән бәлеш, өчпочмакны, каймак, катыкны да яратмады. Бар белгәне тәмәке көйрәтү, чәченбашын рәтләү һәм Галимҗан белән гыйшык-мыйшык уйнау иде. Сәлимә, йөрәге сыкраса да, замана башка, яшьләр башка, дип үзен юатты. Тик еллар үтү белән улы анасы янына кайтуын сирәгәйткәннән-сирәгәйтте. Анасының хәтере калса да, һаман да изге күңелле карчык, Ходаем үзең сакла күз нурымны,

Алланың рәхмәте белән — бер кайтыр әле туган йортына, дип, һәр җомга саен догасында булды.

Дөрес анысы, анысына хат, котлау, акча җибәргәләде улы. Ләкин буш кәгазь генә ана йөрәген җылытамы соң?!

Бик урау-урау булды шул Галимҗанның тормыш юлы. Ничә кабатлар туган йорты — анасына омтылса да, ничә еллар туган нигезе төшләренә кереп татлы йокыларыннан бүлсә дә, бик озак, бик озак кайта алмады шул Галимҗан.

Галимҗан хәрби кеше. Бер шәһәрдән икенче шәһәргә күчеп йөрүләр белән гомеренең ничек узганын сизми дә калды. Тормышның бар ямен хезмәтендә генә күрде. Нигә дигәндә, хатыны Анастасия белән сабыйлары булмады. Әллә эшсезлектән, әллә затыннан килгәнгәме, Анастасия эчкечелеккә бирелде. Ничә кабатлар ант итеп, ничә кабатлар үлемнән чак калса да, эчүен ташламады. Изге күңелле ир Анастасияне ялгызын калдырырга кызганды. Шуңа күрә дә сөеп-сөелү назын, җылы пешкән ашлы өйнең ямен татып яшәргә насыйп булмады Сәлимә карчыкның улына. Яшел елан колы булган Анастасия фаҗигагә очрады. Чират-



10 17

тагы күңел ачулардан кайтып килгәндә машина астында калып, тапталып үлде.

Хатыныннан бер тәрбия күрмәсә дә, бик авыр кичерде Галимҗан аның үлемен. Хатынын җирләп кайткач, бик озак елады ир уртасы булган кеше.

Кайгысын уртаклашырга бик күп дуслары, хезмәттәшләре килгән иде. Алар кайтып китеп, бүлмә уртасында берүзе калгач, ялгызлыкның никадәр авыр, ачы икәнен аңлады. Менә шунда гына ул чит-ят җирдә үзен япа-ялгыз тойды.

50 яшькә җитеп бер кабат та илаһи көчкә ия булган Аллаһы Тәгаләне искә алмаган ир: «Ходаем, үзең ярлыка, үзең кичер анам янына кайтмаганымны, Аллаһ бирсә, кайтам, әнием янына кайтам», — дип, күп тапкырлар кабатлады. Күптән отставкага чыккан подполковник Галимҗан Хәлимҗан улын эштә тоткарлауны кирәк тапмадылар.

Ничә еллар буена җыелган сагыну, күрешү шатлыгыннан очып дигәндәй йөрде Галимҗан. Аны хәзер монда берни дә тотмый иде инде. Ничә еллары үткән хәрби хезмәте дә, дуслары да, фатиры да. Үзалдына елмая-елмая әни карчы-

гына алма, чуклы шәл, алтын хәрефләр белән йөгертелеп язылган изге «Коръән» китабы, йөзем-җимешләр алды. Әй, куанып, әй, шатланып инде анасы. Күрешү шатлыгын тойгандай, әллә нинди рәхәтлек кичерде Галимҗан. Чемоданнарын җыеп, фатирын тапшырып куйганнан соң, Анастасиясе белән соңгы кабат хушлашырга зиратка китте. Зират эче тып-тын. Шунда тәүге кабат игътибар итте: һәрбер кабер өстенә карчыга кебек кап-кара тәре куелган. Нигәдер үзләренең авыл зиратын күз алдына китерде. Анда исә ап-ак мәрмәрташлар яки матур чардуган өстенә ай сурәте куела иде. Мәрмәр ташка куелган фотосурәттән Анастасиянең моңсу йөзен, үткен карашын күреп, сискәнеп китте ир. Гүя, бу күзләр, син мине калдырып китәсең, дип үпкәлиләр кебек иде. Галимҗанның ике яңагы буйлап кайнар яшь акты, үкенү дә, югалту да һәм шул ук вакытта сөйгәнен мәңгегә калдырып китү хисе дә биләп алган иде аны. Бик гүзәл иде шул аның Анастасиясе, шул чибәрлеге әсир иткән иде мөселман егетенең йөрәген. Соңгы кабат кабер ташларын сыйпап, сөйгәне белән хушлашуы бик-бик авыр булды Галимҗанга.

Самолетта тиз кайтып җитәр иде дә кайтуын. Тик Галимҗан поездда кайтуны кулайрак күрде. Күңеле белән тизрәк кайтасы килсә дә, туган ягын поезд тәрәзәсеннән булса да карап кайтасы килде.

Поездга кереп утыру белән йөрәген ниндидер рәхәтлек биләп алды. Гүя ул шатлык диңгезендә йөзә. Туган нигез, туган авыл, газиз әнисенең никадәр кадерле икәнен әле генә төшенгән сабый баладай, йөрәге күкрәк читлегенә сыймый тибә. Вагонда кеше күп түгел иде. Галимҗан моңа да бик шатланды. Аның татлы уйларын шау-шу бүлә алмас. Ничә еллар иңендә йөрткән, хәрби киемен салгач, үзен яшь егетләрдәй җиңел хис итте юлчыбыз. Күпмедер татлы уйларга чумып баргач, кайнар чәй эчәсе килеп, вагонның икенче ягына юл тотты. Кружкасына кайнар су агызгач, кире үз урынына борылды. Инде өстәл янына килеп җитәм дигәндә генә, колагына ягымлы, саф татарча сүз ишетелеп, бер мизгелгә туктап калды. «Кызым, кызым, булмаса кайнар чәй эчеп җибәрик, күңелләр күтәрелеп, эчебезгә җылы йөгерер», — ди карчык. Кеше сүзен тыңлап тору килешмәсә дә, Галимҗан борылып карамыйча булдыра алма-

ды. Аннан ерак түгел генә ап-ак яулыгын таратып бәйләгән кечкенә буйлы карчык белән сөйкемле генә 35—40 яшьләрдәге ханым утыра иде. Галимҗанның чәй эчү кайгысы югалды. Шушы ап-ак яулык бәйләгән карчык анасы кебек тоелды. Аның бик тә, бик тә туган телендә сөйләшәсе һәм бу сөйкемле ике зат янына барып сүз кушасы килде. Үзе эченнән генә: «Юләрләнмә, Галимҗан, кешеләрнең тынычлыгын җуйма, хәзер кешедә кеше кайгысы түгел», — дип, үзен битәрләде. Тик алар белән танышу, тагын да бер генә татар сүзе ишетү дә аның өчен зур бәхет иде шул. Карчык белән кызның чәй эчеп бетүен тыныч кына көткәннән соң, Галимҗан кыюлыгын җыеп, алар янына килде. «Гафу итегез, мөмкин булса, сезнең белән танышып, сөйләшеп барырга рөхсәтме?». Әбекәй кечкенә гәүдәсе белән Галимҗанга борылды да: «Кызым, безнең янда, ахры, кеше бар, нигә сөйләшмисең, татарча сөйләшә түгелме соң?», — дип, кызына эндәште.

Галимҗан шунда гына бу мөселман карчыгының күзләре күрмәгәнлеген шәйләп алды.

— Әйе, әнкәем, безнең күрше урындагы абый безнең белән сөйләшергә, танышырга килгән.

Әбекәй, күрмәгән күзләрен челт-челт йомып, тавыш килгән якка башын борды.

— Әйдүк, улым, әйдүк, түрдән уз, үзебезнең мөселман кешесе икәнсең, инде икенче тәүлек кайтабыз, бер генә дә безнең мөселман кардәшләре утырмаган иде багунга. Үзең кайсы яктан соң, улым, кайтып барышыңмы, китеп барышыңмы?

— Кайтам мин, әбекәй, кайтам, туган якка кайтам, әнкәем янына кайтам.

— Бик шөкер, улым, бик шөкер, туган нигез белән газиз ананы онытырга берсенең дә хакы юк. Ата-ана догасы пәйгамбәр догасы ул, балам. Улым, менә бездә кайтабыз, туган якка кайтабыз, белмим, безнең карендәшләр исән-имин микән инде, бик озак кайталмадык. Безнең дә бик урау, урау булды юллар. Туган нигезебез, туган йортыбыз гына исән булсын, авылдашлар куып чыгармас әле, әйеме, кызым.

— Әйе, әнкәй, әйе, борчылма.

— Улым, туган якка кайтуның сәбәбе дә бик аянычлы шул, бик

аянычлы. Кызым Гөлнәзирәмнең тормыш иптәше вафат булып китте. Хәрби кеше иде, каһәр суккыры Чечен сугышы харап итте кияү балакаемны. Әй акыллы, әй изге күңелле бала иде. Мине «әби» дип тә әйтми, «әнкәй, әнкәй» дип өзелеп тора иде. Шуның кадәр миһербанлы баланы харап кына иттеләр, мәлгуньнәр, ерткычлар. Гөлнәзирәм белән киңәшләштек дә, җыен урыс арасында калмыйк, дип, туган якка кайтырга булдык. Илдә чыпчык үлми, диләр, балам, Аллаһыбыз кушса, җае табылыр әле.

Галимҗан бу кечкенә карчыкны берчә гаҗәпләнеп, берчә аптырап тыңлады. Бу өч юлчының тормыш юлы бер-берсенә охшаганын ни дип тә аңлатырга белмәде.

Үз чиратында Галимҗан да башыннан кичкәннәрен һәм сөйгәнен чит-ят илләрдә калдырып кайтып барганын сөйләде.

— Әй, бала, бала, син дә безнең кебек хәсрәт эчендә икән. Шулай инде, улым, бәла агач башыннан йөрми, кеше башыннан йөри шул. Әнкәең янына кайтырга бик дөрес уйлагансың. Аналар бит көтә, айлар, еллар, гомерләре буе көтә. Миңа, улым, хәзер бар җирдә дә бер кебек.

Якты кояш нурын күрмим, шулай да туган як үзенә тарта икән шул, аннары, Гөлнәзирәмне дә шул урыс якларында калдырасым килмәде. Улым, кеше кайда туа, шунда гына бәхетен таба ул. Сандугач та үз оясында гына матур сайрый.

Галимҗан, карчык сөйләгәннәрне тыңлый-тыңлый, Гөлнәзирәгә игътибар итте. Гөлнәзирә исә вагон тәрәзәсенә караган, ә уйлары белән әллә кайда. Галимҗанда шушы таныш булмаган хатынкызны кызгану хисе уянды. Бичарага ирен чит җирләрдә калдыру авыр булгандыр, дип, үз алдына кызганып куйды. Ни дисәңдә, бу юлчылар белән ничектер язмышлар охшаш иде шул.

— Ярар, әбекәй, Гөлнәзирә ханым, ял итегез инде, күп сөйләшеп, сезне борчысам, гафу итегез. Татарча сөйләшүләрне бик сагынган идем шул, рәхмәт сезгә, сезнең белән сөйләшү сагынуымны баскандай булды. Хәерле йокы сезгә, тәмле төшләр!

Шулай саубуллашып, Галимҗан урынына барып ятты. Ләкин, күпме генә йокларга тырышмасын, күзенә йокы кермәде. Карчык белән Гөлнәзирә турында бик озак уйлады.

Бер сәгать кенә таныш булсалар да, алар аңа бик якын кешеләре кебек тоелды. Ә эчтән генә шушы кечкенә карчыкка, аз сүзле Гөлнәзирәгә рәхмәтләр укыды.

Гөлнәзирәне дә йокы алмады. Ире Мараттан мәңгегә аерылу бик авыр иде шул.

Алдагы билгесезлек, анасының сукыр булуы, шушы юлчы белән тормышлары охшаш булуы да битараф калдырмады. Я, Ходаем, язмышмы бу, әллә бу кеше минем киләчәгемме, дип баш ватты. Гадәттә хатын-кызлар язмышларын ир-атка караганда алдарак күрәләр.

Вагон тәрәзәләренә төшкән кояш нурлары Галимҗанны татлы йокысыннан уятты. Гөлнәзирәләрнең кайсы станциядә төшүләрен сорамаганы келт итеп исенә төште. Нигәдер шушы ике изге җан аңа бик кадерле кешеләре кебек тоелды. Хәрбиләрчә җитез генә торып, киенеп, юынып килгәннән соң, беренче эше итеп юлдашларына хәерле иртә теләргә ашыкты. Бәхеткә, карчык та, Гөлнәзирә дә үз урынnarында иде. Аларны күреп, Галимҗан бермәлгә тукталып калды. Чөнки карчык ап-ак яулыкларын тартып бәйләгән дә, иртә таңнан тәсбих

тартып утыра. Галимҗан шушы кадәр изге карчыкның тәсбих тартуын тирән дулкынлану белән күзәтте. Хәтта вагонда да мөселман икәнен, изге ниятен онытмаган карчыкка күңеленнән рәхмәтләр укыды. Гөлнәзирә исә, куе кара толымнарын сүтеп, тәмле итеп йоклый иде. Бу ике изге җанны куркытмыйм, дип, кырын гына үтеп, кайнар чәй алып килде.

Поезд туган якларга якынлаша. Өч юлчы күптәнге танышлар сыман, күгәрчендәй гөр-гөр сөйләшеп, туган якларга кайтып җитү бәхетеннән иркен тын алалар. Язмышның Галимҗанга елмаюымы, әллә бәхете туган җирдә булугамы, Гөлнәзирәләр Галимҗанның күрше авылыннан булып чыктылар.

Галимҗан, бәхет кошы тоткандай, алардан ризалык та сорый.

— Әбекәй, Гөлнәзирә, юлларыбыз гына түгел, туган төбәгебез дә бер икән бит, мин сезне үзебезгә, әнкәемә алып кайтам, —диде.

Улым, алай ярамас, ни дисәң дә, безнең үзебезнең нигез, үз оябыз бар. Рәхмәт, улым, җылы сүзеңә рәхмәт.

Гөлнәзирә дә әйтеп калырга ашыкты.

— Юк, юк, Галимҗан абый, үзебезгә кайтабыз, әнкәй дөрес әйтә.

— Мин бит сезгә чын йөрәктән. Минем сездән аерылып китәсем килми. Бу тормышта бик күп югалттым инде. Әбекәй, күңелеңә авыр алма, мин сезне, әнкәем — минем әбием, ә Гөлнәзирәне — тормыш иптәшем, дип таныштырырмын.

— Галимҗан абый, ни сөйлисез сез, без бит бер көнлек танышлар, юлчылар гына.

— Юк, Гөлнәзирә, без бер һава сулап, бер су эчеп үскән җирдәшләр. Без ятлар түгел.

Автобус тукталышына чыкканда әбекәйне ике яклап култыклаган кешеләрнең берсе Галимҗан, берсе Гөлнәзирә иде.

Автобус көтүчеләр бу таныш булмаган өч кешене читтән генә күзәттеләр. Аларны беркем дә танымады.

Бу вакытта Сәлимә әби, каз бәбкәләрен күлдән куып кайтып, йокыга талган иде. Төшендә аккошлар күрде. Аккошлар Сәлимә әбинең өй түбәсеннән очтылар-очтылар да, ихатасына төштеләр. Төштеләр дә, кешегә әверелделәр. Шулар арасында Галимҗаны да бар иде шикелле.

«Улым, улгынам, йөрәк парәм, кайттыңмы?» — дип дәшә, имеш, Сәлимә әби. «Кайттым, әнкәй, кайттым, бөтенләйгә кайттым, фатиханңы бир, киленең белән кайттым», — ди, имеш, улы.

Сәлимә карчык, күзләрен ачса, үзе янында тезләнгән улын күреп, куркып китте. Әллә төшем, әллә өнем, дип, күзләрен бер ачты, бер йомды.

— Әнкәй, бәгърем, төшең түгел, өнең бу! — дип, Галимҗан какча гәүдәле әнкәсен кочаклап алды.

Ни еларга, ни көлергә белмәгән ана һаман бер сүзне кабатлый. «Улым, улым, йөрәк парәм, кайттыңмы, кайттыңмы, улым?» — дип өзгәләнә.

Әйе, шатлык, шатлык бу. Шатлык, колачын киң җәеп, Сәлимә әбинең йортын, ихатасын үз кочагына алды...

## МЫШТЫМ СӘРБИ

Сәрбиҗамал карчык, бүген эшләгәннәреннән бик канәгать калып, үзе яраткан «Уракчы кыз» җырын җырлый-җырлый, күперә торган кара туфракка соңгы үсентеләрне утыртты. Әйе,

иренмәгән кешегә күзен дә бакчада эш җитәрлек. Язын ап-ак чәчәктә утырган, көзен ашап туймаслык татлы җимеш биргән алмагачлары төбен казып йомшартты, карлыган төпләренә тирес чыгарды, кура җиләге куакларын бәйләп җыйды. Мәрхүм әнисе әйткәндәй, яшелчә һәм җиләк-җимеш бакчасы җыештырып куелган йорт эчедәй күркәмләнеп китте. «Кара инде син аны, карт юләрне, яшь киленнәргә хас дәрт белән көнозыны бакчада казынды. Иртәгә кул-аякларымны да кыймылдата алмам инде», — дип үзен битәрләп алды Сәрбиҗамал. Уеннан аны сәгатьнең «келт-келт» йөрүе сискәндереп җибәрде. Баш та күтәрмичә эшли торгач авыз ачар вакыт җиткәнен дә сизми калган бит. Быел Рамазан ае көзгә, октябрь аена туры килде. Иншалла, сәламәтлеге булса, Аллаһы Тәгалә кушуы буенча бер көн уразасын калдырмаска исәбе. Ничек инде сау-сәламәт килеш ураза тотмаска? Иманыбызны ныгыткан, күңелебезне сафландырган ай бит бу. Рәхмәт ае, сабырлык ае, ризыкның кадерен белеп, изгелекләр эшли торган ай.

Авыз ачарга егерме минутлап вакыт калган иде. «Булмаса,

изге чишмә суына барып кайтыйм әле, чәе бигрәк тәмле була», дип сөйләнә-сөйләнә көянтә-чиләкләрен алып чишмәгә юлланды Сәрбиҗамал. Җил капканы ачып чыгуы булды, чәчәкле күлмәкләр киеп алып, ак яулыкларын озынга сузып бәйләгән Хәмдияттәй белән Гөлкәйне очратты ул.

— Нихәл, Сәрбиҗамал, исән-сау гынасыңмы? Уразалар тотарга көчең җитәме?

— Рәхмәт, Хәмдияттәй, әлегә исән-имин. Уразамны да тотам, Ходайга мең шөкер.

Авылда «гайбәтче» дигән исеме чыккан Гөлкәй карчык та сүзгә кушылды:

— Кара әле, Сәрбиҗамал, үзең авыз ачарга йөрмәгәч тә ни дип безнең каршыга буш чиләкләрең белән шалтырап чыгасың. Без турыңнан үткәнче сабыр итәр идең азрак.

— Әй, күршекәем, юлымда сез очрарын каян белим инде. Юкка борчылма, чакырылган кунакка буш чиләкләр генә комачауламас әле.

— Беләм мин сине, «мыштым Сәрбине». Тыштан ялтырыйсың да, эчтән калтырыйсың. Безнең көн саен авыз ачарга йөрүебезгә эчең пошадыр әле...

— Нишләвең бу, Гөлкәй, тоткан

уразаларыңны харәмгә чыгарасың бит, ни дип Сәрбиҗамалга кадалып тик торасың? — дип сүзен бүлде Хәмдияттәй.

— Куегыз әле, без бит Аллаһы Тәгалә бәндәләре. Ходайның күзе төз, аның каршында гөнаһларым булса да адәм алдында гөнаһларым юк. Барыгыз, бар, аш-суларыгыз тәмле булсын.

Карчыкларны озатуга атлар-атламас кына чишмәгә юлланды Сәрбиҗамал. Я, Хода, көнозыны бакчада эшләп арымаган карчык Гөлкәйнең сүзләреннән соң кечерәеп, бөкерәеп калды, иңнәре асылынып төшкәндәй тоелды. Ни өчен күрә алмый инде аны күршесе? Күпме изгелекләр китерә аңа Сәрби: ике икмәге булса, берсен аңа кертә, сырхаулап китсә, дару үләннәре белән дәвалый. Күрше хакы — тәңре хакы, дип яши бит ул. Бүген дә бер дә юктан җанына җәрәхәт салып китте Гөлкәй. «Мыштым Сәрби» кушаматы аңа бик яшьли ябышып калды. Авылдашлары, чордашлары күптән оныттылар инде аны. Ә менә Гөлкәй исеннән чыгармый. Бу сүзтезмәне ишетүгә Сәрбинең йөрәге куырылып китә, ерак еллар төпкелендә калган гөнаһсыз үсмер чагы күз алдына

килә. Авыл халкы Сәрбиҗамалны бик ихтирам итә. Елның-елында Рамазан айларында авыз ачарга да, гает, корбан бәйрәмнәренә дә чакыралар. Тик Сәрбиҗамал гына кеше күп җыелган җиргә йөрми. Әллә гадәте шундый, әллә элеккедән калган кеше арасындагы кимсенүе. Гөлкәйнең төртешүенә өйрәнергә кирәк тә бит, юк шул, булдыра алмый. Изге китапларда да язылган бит: күршесен тынычлыкта тотмаган кеше җәннәткә керми. Иманы булган кеше күршесен рәнҗетмәсен, Исламда рәнҗетү юк. Әгәр күршең кяфер булса, синең өстеңдә бер хак — күрше хакы, мөселман булса, ике хак — күрше һәм мөселман хакы, күршең туган-кардәш булса, өч хак — күршелек, мөселманлык, туганлык хакы бар диелгән.

Я, Раббым, бер синең ризалыгың өчен генә ураза тоттым, тоткан уразаларымны кабул ит. Гөнаһларым булса, гафу ит, дип укына-укына күпереп торган мендәренә баш төртте Сәрбиҗамал. Ләкин күпме генә йокларга тырышмасын, белгән догаларын кабат-кабат укымасын, күзенә йокы кермәде. Күзләрен йомса, бүгенге хәл исенә төште, Гөлкәй һаман аны үртәп

каршында басып тора төсле тоелды.

Җитмеш тугыз яше белән барган карчыкның җыерчыклар тулы бите буйлап кайнар яшьләр ага. Сабый баладай йодрыклары белән битен сөртә-сөртә: «Кеше каршында бер генә гөнаһым юк бит. Уналты яшьлек үсмер кызны зар елаткан, сафлыгын алып, чәчәктәй яшьлеген җиргә таптаган адәм актыгы Зәки генә гаепле», — дип акрын гына сыктады ул.

Сабыйлары Сәрбиҗамал тугач Шәрифулла белән Гөлбикәнең шатлыклары чиксез була. Кадер-хөрмәттә иркәләп кенә үстергән бердәнбер кызлары карап туймаслык гүзәл булып буй җиткерә. Андый гүзәлләр хакында халыкта «бал кашыкка сал да йот инде» диләр. Биленә җитеп торган куе кара чәч толымнары, карлыгач канатыдай кыйгач кашлар, зур кара сөрмәле күзләр, чия төсендәге кабарынкы иреннәр. Әнә шул хур кызларына тиң гүзәллеге хурлыкка калдырды да инде гөнаһсыз үсмер кызны.

Авылдагы егетләрне дә, типсә тимер өзәрдәй ир узаманнарын да каһәрле сугыш үзенә чакырды. Ә яше егермегә җиткән сау-сәламәт

Зәки төрле юллар белән сугышка бармый кала. Әле колакларым сызлый, әле күзләрем начар күрә, дип хәрби комиссариатны алдый килә ул. Чираттагы чакыру кәгазе килгәч, үзенең газиз тәнен дә кызганмыйча, уң кулының кул чугын чабып өзә. Янәсе дә корал тоту өчен бармаклары юк. И, шул вакытта анасы Мәрьямнең җир-күк елаулары. Утын алырга дип сарайга керүенә бу хәлгә үзе шаһит була ул. Зәкинең ул чактагы әрнүе, туктамыйча каны агуы, елавы анасы йөрәгендә тирән эз калдырды. Еллар белән бу әрнүләр азрак басылды. Тик Мәрьямнең һаман булса бу дөньяга тудырган газиз баласының шул кадәр мәрхәмәтсез, имансыз, куркак, сатлыкҗан булуына ышанасы килмәде.

— Әни, бәгърем, зинһар кешегә сөйли күрмә, ялгыш балтага егылды дип әйт. Мин куркам ул сугыштан, минем үләсем килми. Терәк булырмын сиңа, тик сугышка гына җибәрмә, — дип әнисенең аякларын кочаклап елаган иде ул. Күңеле белән улын бик кызганса да, җаны-тәне белән аннан чиркана иде Мәрьям. Бөтен ил явыз дошманга каршы күтәрелгәндә үз-үзен

гарипләгән улы анның өчен кешелек сыйфатын югалткан мәхлукка охшап калды.

Сугышка җибәрмәүләренә тәмам ышангач, Зәки үзен төрле яклап тәрбияли башлады. Уң кулы эшкә ярамаса да, сулы белән булса да колхозга ярдәмләшергә тырышты. Ә бер көнне районнан килгән вәкил авылда яшьрәк ир-атлардан үзе генә булган Зәкине бригадир итеп сайлап куйды.

— Кара энем, үзең дә тырыш, халыкны да эшләт, авылыгызда синнән башка бригадирлыкка куяр кешем юк. Җиңүне якынайту өчен безнең, тылдагы кешеләрнең, көнетөне эшләвебез кирәк. Ашлыкның бөртеген дә әрәм итмәгез, ферма маллары өчен дә кышлыкка җитәрлек азык хәстәрләгез, — диде ул.

— Гали Кәбирович, борчылмагыз, кулыма мылтык тотып көрәшә алмасам да, тылда дошманны дөмектерү өчен барлык көчемне бирермен, — дип җаваплады Зәки.

Мәрьям апаның улына карата ямьсез уйлары акрынлап тарала башлады. «Бәлки тәүбә иткәндер, кылган гамәлләренә үкенәдер», — дип уйлады ул. Зәки башта авылдашлары белән уртак тел табып эшләп киткәндәй

булса да, тора-бара аның бу уңышлары таралып юкка чыкты. Җае туры килгән саен ярдәмчесе булган тол хатыннарны рәнҗетә, аларны азыксыз калдыру белән куркыта иде. Яшь булуына карамастан, бик күп хатын-кызлар белән чуала. Берәүләре ир-ат назына үзләре теләп буйсынса, икенчеләрен куркытып, көчләп үз астына сала. Мәрьям апа исә улының көн дә салмыш кайтуына бик борчыла:

— Нәрсә, әнкәй, әллә син минем белән канәгать түгелсеңме, бригадир әнисе булуың ошамыймы? Ә чәчүгә дигән бодайдан икмәк пешергәндә кулың калтырамый бит.

— Ай-һай, улым, ул икмәкләр аш түгел шул миңа, ә таш. Белеп калсалар, баштан сыйпамаслар. Бөтен ил халкы бер уч он өчен тилмергәндә икмәк ашап утыруыбыз зур гөнаһ бит, улым.

— Ну, әнкәй, кызык син, әйме. Сарыклар да исән калсын, бүреләр дә тук булсын, дисеңме? Ярый, ярый, башка алып кайтмам, әмма син ачыңа кәкрәеп катачаксың. Ә миңа нәрсә, мине ашатыр, эчерер өчен авыл хатыннары чират тора әнә.

— Эй бала, бала, синдә намус, вөждан дигән төшенчә бөтенләй юк мени соң?

— Ярый, күп сөйләшмә. Кыздырма мине, бүген соң кайтырмын, районнан теге контрлар килә, шулар белән очрашасым бар.

Зәки үзен авылның хуҗасы итеп тоя. Ул нәрсә әйтсә, шулай булырга тиеш. Шуңа бүген дә ындыр табагын, ферма тирәләрен карап, тикшереп чыкканнан соң, һәрвакыт җылы кочагы, әче балы әзер булган Сәкинәгә кереп табын хәстәрләргә кушты.

Район вәкилләре озак көттерә торган халык түгел. Бүген тикшерәсе авыллар күп, дип Зәкине клубның кызыл почмагына чакыртып алдылар.

— Я, Зәки энекәш, эшләр ничек бара, уңышлар ниндирәк, маллар ач түгелме? — Гали Кәбирович Зәкине керә-керешкә үк сорауларга күмде.

— Ничек дип әйтергә инде, Гали Кәбирович.

— Ә син, энем, бригадир кеше. Шуңа да ничек бар, шулай әйт, тик дөресен.

— Әлегә түзәрлек, булган ашлыкларны бөртеген дә куймый җыйнап алдык, аз булса да чәчүгә орлык салынды. Тик менә фермада эшләр

авырлашты, корылык булу сәбәпле, мал азыгын җитәрлек хәзерли алмадык.

— Кара әле, бригадир иптәш, без сине шул азны күбәйтергә, тишекне бөтен, юкны бар итәргә сайладык бит. Әйдә, тырыш, тап, эшлә һәм эшләт.

Гадәттәгечә Зәки тәмле, татлы сүзләр сөйләп район вәкилләрен тәмам ышандырды. Аларны авыл халкы белән очраштырасы килми иде бригадирның, чөнки соңгы вакытта эшләре бер дә бармый. Амбарларда ашлык бик аз, фермадагы маллар ач, коры сөяккә калганнар, ятсалар баса, бассалар ята алмыйлар. Хатын-кызның чәче озын, акылы кыска. Гали Кәбировичка сөйләп бирсәләр, бетте баш, калды муен тырпаеп була инде.

Үз күзләре белән күрмәсәләр дә, бригадир юкны сөйләмәс, дип район вәкилләре, тарантаска җигелгән атларга утырып күрше авылга җилдерделәр. Ә Зәкигә шул гына кирәк, басу сукмагы буйлап Сәкинәгә юл тотты. Бар булган сыен өстәлгә куеп, Сәкинә Зәкине күптән көтә иде.

— Кара әле, Зәки бәгърем, Ходай бар бит ул. Үзе генә килсә ярар

иде, дип теләгән идем, кабул булды, — дип юан беләкләре белән Зәкине кочаклап та алды.

— Кит әле, шулкадәр арыдым, күрмисеңмени, тегеләрне алдыйм, дип үзем сөйләгәннәргә үзем ышанып беттем, сал әле теге әче балыңны.

Шуны гына көткән Сәкинә, саллы арт якларын төрле якка уйнатып мич артына кереп югалды.

Бу көнне Зәки рәхәтләнеп ял итте. Дүрт кеше өчен әзерләнгән табынга берүзе хуҗа булып, ир-ат назыннан бер дә туймаган Сәкинә белән көнозыны кроватьта аунап айнырр-айнымас вакыт уздырды. Тәрәзәдән, кояш баюын хәбәр итеп, алсу шәфәкъ төшкәч кенә авыр гәүдәсен чак кузгатып ятактан торды. Сәкинә белән саубуллашып та тормыйча, кайтырга чыкты.

Басу сукмагына борылу белән каршысына кеше килүен абайлап алды ул. «Кем икән бу?» — дип уйларга да өлгермәде, «Каракай, каракай», — дип эндәшүче кыз күренде. Ярый, борчылырга сәбәп юк, көтүдән кайтмый калган сыерын гына эзләп чыккан бу, дип уйлады.

— Ә, Зәки абый, сез икәнсез, безнең мүкләк Каракай көтүдән кайтмады, анда арырак күренмиме?

— Юк, Сәрби, күренмәде. Ә мин әле менә ферма малларын карап, тикшереп кайтып киләм.

— Ярый, безгә язган булса табылыр әле, фермага таба бармыйм инде, этләрдән куркам.

— Син, Сәрби сеңелкәш, дүрт аяклы этләрдән курыкма, ике аяклы этләр бик усал була.

— Бәй, бәй, Зәки абый, ике аяклы этләр дә буламы ни?

—Әйдә, Сәрби, син алдарак атла, яшь кеше җитезрәк була ул.

— Зәки абый, район вәкилләре безнең авыл халкының хезмәтенә шелтә биреп китмәделәрме? Әнә күрше авыл бригадирын бик нык орышып, үзләре белән алып киткәннәр дип сөйлиләр.

— Сәрбиҗамал, кем әйтмешли, без бит төшеп калганнардан түгел, район вәкилләрен ничек каршы алырга беләбез. Ә болай безнең эшләрдән, ягъни миннән, канәгать калып киттеләр.

Алар сөйләшә-сөйләшә байтак кына ара узганнарын да сизми калдылар. Ә комсыз Зәкинең шул кыска гына вакытта да Сәрбиҗамалга нәфсесе уянып: «Кара бу кычыткан чыпчыгын, тәмам өлгереп җиткән бит. Вәт юләр, сукыр бу-

лып йөргәнмен. Сугыш бетеп, түшләрендә орден-медальләр чыңлатып солдатлар кайта башласа бу асыл кош миңа эләкмәячәк лә баса. Ә ул шул әче балына алданып азгын, сасы Сәкинәсеннән башын чыгара алмый. Тукта, бу кадәр зиннәтле товарны кулга эләктерү өчен бүгеннән план корырга кирәк. Пока авыл минем кулда икән, аның асыл кошлары минем куенда булырга тиеш», — дип уйлады.

Сәрбиҗамал Каракайны тапмый кайткач, Гөлбикә апа бик пошаманга төшеп: «Кара син аны, малкайны, бер дә алай кайтмый калмый торган иде. Бик кырыс елларда яшибез. Ике аяклы этләргә генә юлыкмаса ярый ла», — диде.

— Әни, бүген шул сүзләрне икенче кабат ишетәм, ни дигән сүз соң ул, нишләп этләр ике аяклы булсын?

— Әй, кызым, кызым, шушы яшеңә җитеп шуны да аңламыйсың икән. Ике аяклы этләрдән дә яманрагы юк ул.

— Аңлатыбрак сөйләче, әни.

— Ике аяклы эт — адәм заты ул, балам, үзе усал, үзе мәрхәмәтсез, эттән дә куркыныч.



11 17

Сәрбиҗамал, әнисен тәү күргән кебек, күзләрен зур ачып: «Менә нәрсә турында әйткән икән бригадир», — диде.

— Кем, теге адәм актыгы чулак Зәки турында әйтәсеңме, кызым?

— Әйе, бүген Каракайны эзләгәндә басу сукмагында Зәки абыйны очраттым, ул да шул сүзләрне әйтте.

— Кара син аны, мәлгунне, шулай диме? Алай-болай начар сүзләр әйтмәгәндер бит сиңа, югыйсә икенче кулыннан да яздырам мин аны.

— И, әнкәй, әнкәй, кызык инде син, ни дип начар сүзләр әйтсен, ул бит авылыбызның бригадиры.

— Я, я, кызым, белмисең әле син азгын ир-атларны. Авыл бригадиры түгел ул, хатын-кызлар бригадиры гына.

— Юк, әни, мин сине барыбер аңламыйм. Бик арыдым, тыныч йокы, тәмле төшләр күр, әни бәгърем.

Гөлбикә апа түшәккә яткач та Сәрбинең сүзләре турында уйланып ятты. Әллә соң теге адәм актыгы, күз карасы кебек саклап үстергән Сәрбиенә дә нәфсесен сузганмы! Тәүбә, тәүбә, Ходаем, үзең сакла.

Иртәгәсен дә, өченче көнне дә Каракай кайтмады. Сәрбиҗамалның йөрмәгән әрәмәлеге, басукырлары, елга буйлары калмады. Гөлбикә апа, гаиләсен туйдыручы сөтбикә югалгач, бик кайгырды. Ә Сәрбиҗамал һаман булса өметен өзмәде, табылыр, дип эзләвен дәвам итте.

Көн кичкә авышып килә. Каракай, могаен, җәйләүдәге сыерлар янында булыр дип Сәрби шунда юл тотты. Ул килеп җиткәндә сыерлар савылып бетеп, кичке тынлыкта бары тик аларның күшәве, таллыкта ара-тирә кошлар сайравы гына ишетелә иде. И, юньсез, соңга калганмын, монда кеше заты да күренми, дип уйларга да өлгермәде, каравылчы өеннән ава-түнә чыгып килүче бригадир белән каравылчы Әхмәй карт күренде.

—Ә-ә, Сәрбикәй, кара кашкай, әллә сөтбикәгезне әле дә тапмадыгызмы?

—Зәки абый, аптырагач, җәйләүгә килдем менә, бәлки мондагы сыерларга кушылгандыр.

—Сәрбикәй, кара кашкай, бик мөмкин, бик мөмкин, әйдә әле утардан кереп карыйк. Ә син, Әхмәй абзый, бар кереп чәй куй, мондый гүзәл кызны җәйләүнең хуш исле чәе белән сыйламасак гөнаһ булыр.

— Юк, юк, Зәки абый, нинди чәй инде ул. Мин болай да озак йөрдем, әнием югалткандыр.

Берни уйларга да, куркырга да белмәгән Сәрбиҗамал бригадир Зәки артыннан утарга юнәлде. Исерек чулак Зәки исә бу минутларда "Кара син аны, бу асыл кош үзе куеныма килеп керде", — дип уйлана иде.

— Я, кара, Сәрби, Каракаең күренәме?

Сәрби никадәр өметләнеп эзләсә дә, сыерлар арасында аларның мүкләге күренмәде.

— Ярый, әйдә, киттек, булса булыр иде инде.

— Әйе шул, Зәки абый, кайда гына булды инде, әйтерсең, җир йотты.

Күзгә пычрак. Сыерлар таптаудан ныграк баткакка әверелгән утардан Сәрби тизрәк чыгарга омтылды. Тик шул вакыт аны көчле куллар арттан кочып алып җиргә екты.

— Зәки абый, Зәки абый, нишләвең бу?

— Кычкырма, кычыткан чыпчыгы, әле дә бик озак нәфсемне кузгатып йөрдең. Син бүген минеке булачаксың, ишеттеңме? Сез барыгыз да минеке: шушы җәйләүдәге

маллар да, авыл да һәм синең кебек асыл кошлар да.

— Зәки абыкаем, зинһар дим, акылыгызга килегез, тимәгез миңа, кагылмагыз, җибәрегез мине.

— Я, чәпчемә, кычыткан чыпчыгы, сасы Сәкинәдән тәмам туйган идем, кочагыма үзең килеп кердең бит. Мин сине җәйләүгә чакырмадым.

Никадәр өзгеләнмәсен, күз яшьләре аша үзен җибәрүен ялвармасын Сәрби, Зәки аны җирдән торгызмады. Алсу ефәк күлмәге сыер тизәгенә буялды, озын кара чәч толымнары сасы, пычрак суда юешләнде. Берничә минут эчендә чулак Зәки Сәрбиҗамалга ач бүре сымак ташланып, үзенең хайвани теләген тормышка ашырды.

— Зәки, Сәрби кызым, чәй кайнады, әйдәгез, керегез, — дип Әхмәй карт чыкканда утар уртасында ялгызы исен җуйган Сәрби ята иде. Бу коточкыч хәлне күреп акылыннан язган Әхмәй карт бар көченә:

— Ай-һай, коткарыгыз, коткарыгыз, ярдәм итегез, кеше үлә, — дип кычкырырга башлады. Тик тирә-якта беркем дә күренми, чулак Зәкидән җилләр искән.

Әле кайчан гына лалә чәчәгедәй балкып торган Сәрби сулган

чәчәктәй тапталган хәлдә пычрак җирдә аунап ята.

— И, балакаем. Ниләр эзләп монда ялгызың килдең, белми идеңме ни ул ике аяклы этнең күпме хатын-кызны зар елатканын. Я, Ходаем, нишләп бу сабыйны озатырга үзем чыкмадым. Белә торып хараплар иттердем бит, карт юләр, карт юләр, — дип өзгәләнә-өзгәләнә, тал чыбыгыдай бөгелеп төшкән Сәрбине күтәреп каравыл өенә алып керде.

* * *

Килгәч килә икән адәм баласына кайгы-газаплар. Гөлбикә апа кызының мәсхәрәләнүен бик авыр кичерде. Сәрбиҗамал исә шул вакыйгадан соң ике ай кроватьтән тормый авырып ятты. Урамга чыкмас һәм кеше күзенә күренмәс булды. Очкын чәчеп торган кара күзләрдә нур сүнде, чия төсендәге кабарынкы иреннәр мәңге ачылмас кебек йомылды, озын кара толымнарын кыска итеп кисеп бәрде. Ә сигез айдан Сәрбиҗамал үле кыз бала тапты.

Бу коточкыч фаҗиганең чын дөресен авыл халкы белә алма-

ды. Берәүләре чулак Зәки эше дисә, икенче берәүләре «Матур хатын-кызлар азгын була» дип бер гөнаһсыз Сәрбине гаепләде. Ә иң дөресен белгән Әхмәй картны Зәки шул төнне үк сазлыкта тончыктырып үтерде.

Бу дөньяда явызлык кылган адәм баласы үз җәзасын ала һәм алырга тиеш. Коръәннең Ниса сурәсенең 93нче аятендә: «Әгәр бер кеше аңлы рәвештә бер мөъминне үтерсә, аның җәзасы — җәһәннәм. Ул анда мәңге калыр. Ул үтерүчегә Аллаһ ачуланды, аны каргады һәм аңа зур газап әзерләде», диелә. Чулак Зәки дә тиешле җәзасын алды. Аны колхоз малын урлауда гаепләп, төрмәгә озаттылар. Шул китүдән ул башкача авылда күренмәде.

Тән ярасы төзәлә, җан ярасы төзәлми, ди халык. Сәрбиҗамал мәсхәрәләнгәннән соң авылның усал телле кешеләре: «Шаталак исем күтәрә, мыштымнар бот күтәрә» дигән уйдан кызга «Мыштым Сәрби» дигән кушамат тактылар.

Аккан сулар кебек еллар үтә. Әтисе Шәрифулла сугыш кырында ятып калды, әнисе дә күптән гүр иясе. Сәрбиҗамал үзе дә олыгайды инде. Туып-үскән нигездә гомер ки-

черде. Йортлары бик иске булса да аның гомеренә җитәчәк әле.

Вакыт кешене дәвалый диләр. Сәрбиҗамал да яшьлеге фаҗигасен акрынлап йөрәге төпкеленә күмә барды, бүген ашыйм дисә, өстәлендә ризыгы, киям дисә киеме бар. Ләкин ул һәр кешедә була торган гаилә бәхетеннән мәхрүм. Шатлыгын да, кайгысын да уртак итәрдәй кеше юк. Нишлисең, язмышы шулай булгач. Ә язмышлардан узмыш юк. Булганына шөкер итеп, риза булып яши бирә. Тик күршесе Гөлкәй генә йөрәк ярасына янә кагылды. Бу төнне Сәрбиҗамал карчык әллә йоклады, әллә йокламады. Узган гомерен янә бер күз алдыннан үткәрде ул. Сәхәр ашарга ике сәгать вакыт калгач иртәнге чәенә тәмле итеп коймак пешерде, чишмә суыннан чәй кайнатты. «Я, Ходаем, тоткан уразаларым кабул булсын, туасы таңым, килер көнем савапка үтсен», — дип иртәнге уразасына басты ул.

## ТӘКЪДИР БӘЛЛҮР ТҮГЕЛ, ҮТӘ КҮРЕНМИ

Тып-тып тамчылар тама, язның шатлыклы авазлары. Салкын кар бөртекләре никадәр Язсылу белән көрәшергә теләмәсен, көләч кояшның җылы нурлары белән боз сөңгеләрен үзенә буйсындыра. Мансафны әллә тып-тып тамчылар тавышы, әллә тар гына ярыктан сүрән генә төшүче яктылык уятты. Гәүдәсен авырлык белән чак кузгатып, такта сәкедән торды. Ләкин, авыртуданмы, аяклары оюданмы, ул юеш таш идәнгә егылды. Тар гына камера эче, баш түбәсендә, бал кортлары выжлап әйләнгән кебек, таш түшәм әйләнә башлады. Мансаф бик тә каты итеп башын таш диварга бәргән иде. Шушы халәтендә күпме ятканын хәтерләми. Аның өчен хәзер барыбер. Чөнки монда килеп әләккәннәрнең кемгә хаҗәте бар. Мансаф өчен болай яшәүгә караганда үлем артыграк иде. Ләкин ул ничек кенә үләргә теләмәсен, аның тугры җаны ташлап китәргә ашыкмады. Әле аңа тагын да әрнү, сагышлар, бетмәс-төкәнмәс җан сыкравы белән шушы ярым караңгы, сасы камерада унике ел гомер үткәрәсе.

Авырлык белән сәкенең читенә таянып торды да, тагын урынына ауды. Күз-битләре шешенгән, сакал-мыек үскән, киемнәреннән әллә нинди ис килә. Гәүдәсе авыр, әйтерсең бер мичкә су агызганнар. Хәер, Мансаф бу кыяфәтенә үзе өйрәнде булса кирәк. Тик менә тәненең кычытуына түзәр әмәл юк. Ул үзен әкият, кинолардагы хәлсез карт юлбарыска охшата. Мансаф үзенең төс-кыяфәтен күз алдына китереп ята торгач йокыга тала.

Нәсимә болыны. Зур, түгәрәк болын. Бил тиңентен үскән тубылгы, гөлбадраннарны икегә яра-яра Мансаф атлый. Кап-кара бөдрә чәчләрен җил тарый. Күк гөмбәзе кебек ачык зәңгәр күзләрендә нур балкый. Өстенә кигән кыска җиңле ак күлмәге аны тагын да сөйкемле итеп күрсәтә. Ничек күзләреңнән нур бөркелмәсен инде, ул бит биш ел укып, кулына авыл хуҗалыгы белгече дипломын алып кайтып килә. Әнә аңа таныш бөдрә чәчле юкә, аның төбендә ат арбасы, аннан ерак түгел аның яраткан бахбае Йолдызкашка ашап йөри. Тик нигәдер әтисе Мирзанур, әнисе Сәгъдәт күренми. Алардан калган учак кына пыскып төтенләп ята. Әти-әнисенең монда булуы аны бик шатландырды.

Нигә дигәндә, Нәсимә болыны аңа кечкенәдән таныш. Әй ярата иде Мансаф кечкенә чагында каен җиләге белән әнкәләрен сыйларга. Алар эсседә печән чаба, ә Мансаф учак ягып чәй кайната. Карлыган яфраклары салып кайнатылган чәй белән әти-әнисен сыйлый. Мансаф ялгышмаган икән, учак янында хуш исле чәй аның үзен көтеп торган. Үткән ел гүр иясе булган зур әнкәсенең сүзләре хәтеренә төште Мансафның: «Балакайларым, Нәсимә болынына барып, Мансаф улымның хуш исле чәйләрен авыз итсәм, үлсәм дә үкенмәс идем», — дигән иде ул. Тик аның соңгы гозерен үти алмады шул оныгы. Ул вакытта декабрь бураннары котыра иде. Күп тә үтми, изге Рамазан аенда, мәңгелек йортына күчте Шәрига әби.

Я, Ходай, никадәр тәмле, никадәр сагындырган икән туган якның бу шифалы, хуш исле чәйләре. Озак, бик озак кайта алмый торды шул студент егет, әле курс, әле диплом эшләре белән җәй уртасы җиткәнен сизми дә калган.

Мансафның татлы уйларын бүлеп, балачактан таныш чалгы тавышы ишетелде. Әнә бит аның

газизләре, күрше болында гына икән.

— Әй, эхе-хе-хей, әнкәем, әткәем, мин кайттым, мин, каршы алыгыз, сезнең улыгыз Мансаф, дипломлы улыгыз кайтты.

Кызу кояшта йөзләре каралып янган, күлмәк итәкләре кыстырылган ак яулыклы әнкәсе Мансафка каршы йөгерә иде.

— Улым, улым, йөрәк парәм, шатлыгым, колынчыгым кайткан, атасы, күр әле, күр, кем кайткан, — дип улының кочагына ташланды ана. Бала — ана шатлыгы, сагынудан сусаган җаннарның күрешү мизгеленең никадәр татлы икәнен алар үзләре генә белә. Шул арада түбәтәен кырын салып әтисе Мирзанур килеп җитә. Улын аталарча кочаклап аркасыннан сөеп:

— Вәт маладис, улым, вәт маладис, диплом алып кайттым диген, ә, менә бу шатлык, әнкәсе, шатлык. Ямьле кояшлы көнне тагын да ямьләп улыбыз кайткан. Әй, анасы, зур бәхет бит бу. Кемнең улы, Мирзанур улы дияргләр. Өстәвенә, Мирзанурның улы агроном дияргләр. Я, ничегрәк яңгырый, Мансаф Мирзанурович. Вәт, улым, рәхмәт, игелеген күр дипломыңның.

Үз җиребезнең чын хуҗасы бул. Безнең туфрагыбыз кадер-хөрмәтне ярата. Туган төбәгеңдә икмәк үстер, — диде Мирзанур ага.

— Рәхмәт, әткәй, мин авыл баласы, җир улы, ышанычыгызны аклармын, — дип җаваплады Мансаф.

Диплом алып кайтуының икенче көнендә үк кәнсәләргә китте ул.

— Фәрит Галиевич, мин хәзер сезнең карамакта. Мине теләсә нәрсә эшләтә аласыз.

Их, мин үзем бригадир,
Комбайнер һәм тракторист.
Кирәк икән булам танкист,
Ял иткәндә гармонист.

Менә сезгә диплом, ә миңа эш бирегез, — диде ул председательгә.

Фәрит Галиевич сөйкемле, таза гәүдәле егетне бер күрүдә үк ошатты.

— Әйдүк, түрдән уз, энем, син безнең Мирзанур абыйның улы Мансаф буласың бит әле?

— Так точно, Фәрит Галиевич.

— Бик хуп, бик хуп, Мансаф энем. Синең диплом алып кайтуыңны көттек. Укыган кешеләр, авыл хуҗалыгы белгечләре бик аз бездә. Син, энем, яхшылап бер ай ял ит, дәүләт имтиханнары җиңелдән булмагандыр, өегездә

тор, әтиеңнәргә печән хәзерләргә ярдәм ит, соңыннан җиң сызганып эшкә башларсың.

— Фәрит Галиевич, яхшы сүзләрегезгә рәхмәт, әмма кызу эш өстендә бер ай минем өчен бик күп. Ә печәнне, Фәрит Галиевич, хәзерлибез аны, быел гына калмас.

— Мансаф энекәш, син бит бөтенләе белән атаң Мирзанурга охшагансың. Әтиең дә эш өчен җанын бирергә әзер. Шулай да син минем сүзләргә колак сал әле, атнаун көн ял ит, аннан күз күрер, ә болай чын егет икәнсең, Мансаф энекәш, синдәй егетләр күбрәк булсын иде дә бит.

Туган авылының хәтфә болыннарында печән чабып, су коенып, кояшта кызынып атнаның үткәнен сизми дә калды егет. Бу юлы да Фәрит Галиевичның ишеген шакып керергә кыюлык тапты ул.

— Әйдүк, энем, сине көткән идем, сүзеңдә торасың икән, афәрин.

Шулай итеп, Мансаф Мирзанур улы туган авылы, туган колхозының җир хуҗасы, җир белгече булып китте. Көн дә таң белән уянып, басу буйлап мотоциклда җилдерүче егетебез Мансаф үз эшеннән бик

канәгать иде. Озын көн буе, өстәвенә кичләрен китапханәдә укып утырулар, һөнәренең нечкәлекләрен ныклап өйрәнү эшендә бик ярады. Үзе белгәннәрен башкаларга өйрәтте, белмәгәнен теше-тырнагы белән тырышып өйрәнде. Яшь булуына карамастан, күп еллар колхозда эшләгән абзый-агайлар алдында тиз абруй казанды Мансаф. Сәгъдәт апа, Мирзанур абый улларының җирне яратуын, хезмәтеннән ямьтәм табуын күреп, куанып бетә алмадылар. Көзге уңышка, уракка да төште авыл халкы. Иртә таңнан кичке караңгыга кадәр комбайн, машина, ындыр табагында эшләүчеләр янында булды Мансаф.

Авыл яшьләре кино-дискотекада күңел ачканда да ул басукырлар буйлап чапты. Яшьләр берәүләре сокланып, икенчеләре көнләшеп аның турында хәтта такмаклар да чыгарды. Мансафның да йөрәге яшь, ул да җилкенә яшьләр белән күңел ачарга. Тик әтисенең: «Улым, җәйге бер көн елны туйдыра», — дигәне аңа догадай яңгырый. Мансаф басудан кайтканда авыл янындагы Камышлы күлгә төшеп салкын су белән коена. Көне буе кояшта янып, тузанда йөргән егетнең,

елгада коенгач, күңеле күтәрелеп, рәхәтләнеп кала. Бүген дә ул Камышлы күлгә төште. Ләкин үзе коена торган урында сылу кызны күреп, туктап калды.

— Әй, егет, кил әйдә, нигә туктап калдың, мин кеше ашамыйм, — дип энҗедәй тешләрен күрсәтеп көлеп җибәрде кыз.

— Юк, сылу, мин сездән курыкмыйм, сез үзегез минем кыяфәтемнән курыкмагыз. Көнозыны тузанда йөреп, үзем шүрәле кыяфәтендәмен.

— Сезнең исемегез Мансаф бит, әйме, ә мин Гүзәл, таныш булыйк.

— Әйе, мин Мансаф.

— Син миңа гаҗәпләнмә инде, Мансаф, ниндидер таныш түгел кеше сорау ала дип. Мин Уфа кызы, әбиемнәргә кунакка кайттым. Әниемнәр авыл һавасын сулап, ял итеп кайт, дип авылга җибәрделәр. Синең көн саен кич Камышлы күлгә төшүеңне күреп, әбиемнән сорадым.

— Әйтәм аны, күз күргән кеше түгелсең, шәһәр кызы икәнсең шул. Менә нәрсә, гүзәл кыз, син кайта тор, кич клубта очрашырбыз. Югыйсә, минем турыда авыл яшьләре такмак та чыгарганнар дип сөйлиләр.

Өйләренә кайтып, тамак ялгап алгач Мансаф клубка чыгарга киенә башлады. Улын читтән генә күзәтеп торган Сәгъдәт апа, кызыксынуын яшермичә:

— Улым, әллә клубка артистлар килгәнме, театр буламы? — дип сорамыйча түзә алмады.

— Юк, әни, артистлар килмәгән, бүген мин дә урам әйләнеп, егетләр белән гәпләшеп кайтыйм әле, югыйсә, дусларым да үпкәли, кайтканыңа да күпме, безне оныткансың, кайттың да эшкә чумдың, син генә колхоз кендеге диярсең, дип үртиләр.

— Бар, улым, бар, үзем дә күптән шуны әйтмәкче идем, яшьлек ул искән җилдәй, үтә дә китә. Яшьлегеңнең кадерен бел.

Мансафны клубка җитәрәк егетләр куып җитте.

— Ну, Мансаф, иртәгә телефон баганалары яфрак ярмаса ярый инде синең клубка чыгуыңны котлап.

— Ягез инде, егетләр, шаяртмагыз, әллә мин сагынмаган дисезме?

Шау-гөр килеп егетләр клубка керде. Магнитофонда заманча музыка яңгырый. Ярым караңгы клубта биш-алты кыз бии, ә берничәсе үзара чыр-чу килеп гәпләшәләр.

Егетләр янында Мансафны күргәч, кызлар сөйләшүләреннән туктап:

— Карагыз әле, карагыз, Мансаф килгәч караңгы клублар яктырып китте, — дип күңелле көлешеп алдылар. Мансафның күршесе Зәбир: «Яшьти, әйттем мин сиңа, бер генә кабат булса да нурлы йөзләреңне кызларга күрсәт», — дип үртәште.

Ә Мансафның күзләре кызлар арасыннан Камышлы күл буенда күргән Гүзәлне эзли иде. Тик кыз күренмәде. Мансаф: «Вәт юләр, очраклы гына күргән кешенең сүзенә ничек ышанырга була инде», — дип уйлады. Шулай да егеткә бик күңелле иде. Әнә ничек сагынганнар үзен, бер-бер артлы сорауларын яудыралар гына. Бу кичне Мансаф рәхәтләнеп күңел ачты. Тик егетләр янында ничек кенә күңелле булмасын, аңа кайтып ял итәргә кирәк. Шуңа ул, егетләр белән саубуллашып, өйләренә ашыкты.

Кайтып җитәргә бер-ике йорт калгач, «Мансаф, Мансаф», дигән тавыш ишетеп туктап калды.

— Гүзәл, син, нигә бу караңгыда ялгызың, нигә клубка чыкмадың?

— Клубка чыга алмадым шул, әбием мунча яккан иде, шуңа соңга калдым. Әле ишек алдына чыккан

идем, аяк тавышлары ишеткәч, син кайтып киләсеңдер кебек тоелды.

Шул кичтән алып бу ике яшь йөрәк берсен-берсе өзелеп көтеп, сагынып очраша башладылар. Әнисе генә, үзалдына: «Я, Ходаем, улыма бәхет, тәүфыйк бир, шәһәр кызына күңеле төште, югыйсә, үз авылыбызда да уңган, булган, сөйкемле кызлар җитәрлек бит», — дип уйлады.

Мансаф Гүзәлне көннән-көн ныграк яратты. Аның озын керфекләре, дулкынланып торган чәч толымнары әсир итте егетне. Гүзәл белән рәхәт иде аңа. Кыз белән теләсә нинди темага сөйләшеп була. Мансаф Гүзәлне никадәр яратса да, аңа кагылмаска, туй көненә кадәр саф хисләргә тап төшермәскә булды.

Санаулы көннәр бик тиз үтә. Ике көннән Гүзәл үзләренә кайтып китә. Бу көн икесе өчен дә бик авыр буласын алар беләләр иде. Озатканда Мансаф сөеклесенең күзләренә туры карап: «Гүзәлем, мин саф мәхәббәтебезгә тап төшермәвеңә ышанам, тик үзеңне сакла. Мин синсез яшәүне күз алдыма да китерә алмыйм. Кайткач, әти-әниләрең белән сөйләш, аларга безнең никахыбыз буласын әйт.

Нәкъ бер айдан мин сине алырга барам. Мин сине бик-бик яратам, көт мине, бәгърем», — диде. Поезд кузгалып китте. Вагон тәрәзәләреннән күз яшьләре аша елмайган Гүзәл кул болгый иде.

Көн артыннан көн үтте. Ике яшь йөрәкне телефон чыбыклары гына тоташтырды.

«Мансаф, кадерлем, белсәң икән ничек сагынганымны, кил, килеп ал мине, коткар мине бу хәлемнән», — дип ялварды Гүзәл.

Мансаф сөйгәненә туй күлмәге алды. Аны шушы күлмәктә күз алдына китереп, чиксез куанды. Әнисе, улының шулкадәр шашынып, очып йөрүен күреп бер шатланды, бер көяләнде: «Бәхетегез генә була күрсен инде, улым, бәхетегез генә. Ак күлмәккәегезгә кара таплар төшмәсен».

Мансаф шәһәргә якынлашып килә. Тиздән, бик тиздән Мансаф сөйгәне янында булачак. Бүген киләсен шалтыратып әйтеп тормады Мансаф. Сөйгәненә сюрприз эшлисе килде аның. Гүзәлнең язып калдырган адресы белән эзләп китте.

Тукталышта күз явын алырлык чәчәкләр сатып утырган карчыклардан Гүзәлгә иң матур гөлләмә аласы

килде Мансафның. Мәхәббәтебез саф булсын, дип гел кабатлый иде Гүзәлгә, шуңа күрә ап-ак розалар сайлады. Мансафның уйларын укыган кебек: «Кадерле кешеңә бүләк итәсеңдер, улым, барыр юлларың ак, хисләрегез саф булсын», — дип гөлләмәләрне сузды ак яулыклы апа.

Адреста күрсәтелгән йортны табуы авыр булмады аңа. Күрешүнең татлы мизгелләрен тизләтер өчен лифтта гына күтәрелде егет. Лифт ачылуга ук колакларны ярырдай рус музыкасы ишетелде. Ниһаять, ул Гүзәлнең ишек алдында басып тора. Музыка исә шушы фатирдан яңгырый. Дөрес килмәдем, ахры, дип уйларга өлгермәде, ишектән бер-берсен этеп диярлек ике әзмәвердәй егет һәм алар артыннан ук ярым шәрә ике хатын-кыз күренде.

— Нәрсә, Сашка, әллә бердәнбереңә бер сигарет кызганасыңмы, безгә дә давай, — дип егетнең авызыннан сигаретын йолкып алды кыз.

— Син нәрсә, шалава, төн күбәләге булып, әллә үзеңә сигаретлык та эшли алмыйсыңмы?

Мансаф ни уйларга белми торганда икенче, озын чәчле исерек егет:

— Ха-ха-ха, егетләр, карагыз әле, безнең заманда да булыр икән Ромеолар. Ак розалар тотып килгән берәү. Әй, егет, тилерденме әллә, бу вакытта ак розалар бүләк итәрлек кызлар бармыни әле? Вот даешь, ә, ак розалар диген, ә? Слушай, Сашка, бу безнең Гульканың авылдагы Мәҗнүне микән әллә? Ха-ха-ха, бар, кер, нәрсә карап каттың. Гулькаң сине көтеп зарыгып бетте инде, только егеткәем, сиңа айныганын көтәргә туры килер. Ә ул болай вообще-то саран түгел, кер давай, кер, ул сине давно көтә.

Мансаф бу көтелмәгән хәлдән югалып калды. Чәчәкләрен бер кулыннан икенчесенә күчереп, бу ямьсез күренештән нишләргә белмәде. Гүзәлен күреп, татлы очрашу минутлары кичерү урынына букадәр ямьсез исерек егет-кызларны күрү күңелен болгатты.

Йодрыгын йомарлап, сабыр булырга тырышып, фатир ишеген ачып эчкә үтте. Бүлмә эче балта элеп куярлык тәмәке төтене эчендә, күңелне болгатырлык, укшытыр-

лык сасы ис килә. Аш бүлмәсе дип аталган бүлмәдәге магнитофонны ачу белән уттан өзеп бәрде. Өстәлдә эчеп бетерелмәгән аракы шешәсе, лимон кабыклары һәм тозлы балык башлары, тәмәке төпчекләрен күреп, чак косып җибәрмәде. Эчкәрәк үтеп бер ишекне ачса, үз күзләренә үзе ышанмады. Эчке күлмәктән, шәрә диярлек Гүзәлен күреп өнсез калды. Ул мендәрен кочаклаган килеш үкси-үкси елый иде. «Мансаф, кадерлем, кичер мине, мин сиңа лаек түгел, мин фәхишә, мин төнге күбәләк».

Мансафның тәне эсселе-суыклы булып китте. Иреннәре дерелди, тәне тартыша иде. «Я, Хода, Гүзәлем, син нигә мине алдадың, нигә минем саф хисләремнән көлдең?» — дип Гүзәлнең иңнәреннән тотып селки башлады. Күз кабаклары шешенгән, озын толымнары тәртипсез рәвештә таралган, муены тулы үбү эзләре калган хатынны Мансаф яраткан Гүзәл дип булмый иде.

— Син, син килдеңме, я күр инде Гүзәлеңне, ничек, матурмынмы мин? Я, нигә кочагыма ташланмыйсың, иркәләмисең? Яратам, ди идең бит.

— Гүзәл, син нишләдең, нигә минем хисләремнән көлдең, нигә мине алдадың?

— Җитте, Мансаф, башка бер сүз дә әйтмә. Мин сине алдамадым. Мин инде күптән кешелектән чыккан зат, ә авылга кайтуымның сәбәбе, бәлки, бу эшләрне онытырмын, кеше кебек яшәрмен, яратырмын дип уйлаган идем. Юк, булмады, мин инде кеше була алмыйм. Аңлыйсыңмы, була алмыйм, фәхишә мин, төнге күбәләк, ишетәсеңме?

— Төнге күбәләкләр дә ут яктысында очалар-очалар да, канатлары көйгәч, җиргә төшеп үләләр. Минем канатларым көйде инде. Бар, кит, югал күз алдымнан. Әгәр син мине ялгызымны кайтарып җибәрмәгән булсаң, мин яңадан бу хәлгә төшмәгән булыр идем. Ә син, бер-беребезне сынап карыйк, мәхәббәтебезне саф килеш саклыйк, дип миңа кагылырга да курыктың. Я, хәзер татып кара мине, башкаларга җиткән кайнар кочагым сиңа да җитәр.

Гүзәл урыннан торып Мансаф янына килә башлады.

— Тукта, якын киләсе булма, хыянәтче. Син фәхишә генә түгел,

син, син бәдбәхет, син кәнтәй. Килмә, кагылма миңа.

Мансаф бар көченә Гүзәлне этеп җибәрде. Аягында чак басып торган Гүзәл гөрселдәп кире урынына ауды. Акны-караны күрмәгән, күзе тонган Мансаф ишеккә ташланды. Аның артыннан тирә-якка сибелгән ак розалар тапталган хәлдә идәндә аунап калды. Үз гомерендә, үзен белә-белгәннән бирле бер дә елап карамаган егетнең ике яңагы буйлап күз яшьләре ага. Инде кая барырга? Я бер танышы юк. Кире кайтып китеп булмый, поезд иртәгә кичкә генә. Бар нәфрәтеннән арынырга теләп, тиз адымнар белән тукталышка чыкты. Шәһәр үзәгендәге кунакханәнең бер бүлмәсенә урнашты. Көнозыны поездда килү, Гүзәл белән коточкыч ямьсез күрешүдән соң Мансаф тәмам хәлдән тайган иде. Ул өс киемнәрен дә салмый караватка ауды.

Мансаф төшендә Нәсимә болынын күрде. Ямь-яшел болында аллы-гөлле чәчәкләр. Болын уртасында Гүзәл ак туй күлмәгендә аңа каршы йөгерә имеш, кулында исә Мансаф бүләк иткән розалар. Ул да сөйгәненә каршы йөгерә. Менә аларның арасы бер-ике адым гына



12 17

калды. Чү, нәрсә булды, Гүзәле юкка чыкты, аның күз алдында күбәләккә әверелеп очып китте. Ә үзе Гүзәл тавышы белән: «Хуш, җаным, хуш, бәгърем, мин күбәләк, мин төнге күбәләк», — дип канатларын җилпи имеш. Мансаф тирәякка бәргәләнә торгач, саташулы төшеннән арынып, уянып китте. Иреннәре кипкән, башы чатный, йөрәге күкрәк читлегеннән чыгардай булып дөп-дөп тибә. Арыган, талчыккан гәүдәсен чак кузгатып, аягына басты. Тәрәзәдән сирпелеп яктылык керә, таң сызылып килә. Инде нишләргә, кая барырга, дип баш ватты Мансаф. Өс киемнәрен алмаштырам, дип уйлагач, юл чемоданы исенә төште. Аның ул йортны һәм Гүзәлне күрергә бер дә теләге булмаса да, язганы шулдыр дип, кабат Гүзәлләргә китте. Иртә булуга карамастан, шәһәр урамында кеше күп иде.

Никадәр өметләр баглап, сөю тулы йөрәге белән килгән иде бит ул бирегә. Ә бүген күңеле, йөрәге тулы нәфрәт һәм мәхәббәтенә кара тап төшереп кайтып китә Мансаф. «Эх, Гүзәл, Гүзәл, нишләттең син мине, нигә юлларымда очрадың», — дип әрнеп ул яши торган йортка

якынлашты. Мансафны бу иртәдә кичәгедән дә яманрак хәлләр көтеп тора иде. Фатир ишеген ачып керү белән каршына милиционер килеп басты.

— Әһә, асыл кош үзе безне эзләп тапты, иптәш майор.

Мансафка сүз әйтергә дә ирек бирми ике милиционер ике яклап кулларын каерып богау кидереп тә куйдылар.

— Гафу итегез, иптәш майор, сез мине кем беләндер бутыйсыз. Мин бернинди дә җинаять эшләмәдем. Мин бит бары тик кичә онытып калдырган чемоданымны алырга кердем.

— Я, я, күп сөйләшмә, беләбез сезнең кебек кеше үтерүчеләрне. Нәрсә, белмәсләр дип уйладыңмы? Нинди генә булмасын, ул кеше, ә син, бәдбәхет, кеше гомеренә кул сузгансың.

— Иптәш майор, мин аңламыйм, кемне үтергәннәр?

— Нәрсә, авыл йолкышы, әллә мин түгел дияргә уйлыйсыңмы? Йосыпова Гүзәлияне яки кем анда, сезнеңчә Гулькамы әле, мин үтермәдем димәкче буласыңмы?

— Гүзәл, Гүзәлне үтергәннәр?

Мансафның бер мәлгә күз аллары караңгыланып китте. Ул

шунда гына бүлмә уртасында акбур белән сызылып эшләнгән кеше кыяфәтендәге сурәтне күрде.

— Гүзәлне үтергәннәр? Ничек, нишләп, ул бит кичә генә исән иде.

— Әйе, Йосыпова Гүзәлне үтергәннәр һәм ул кеше син.

— Иптәш следователь, нәрсә сез аның белән сөйләшеп торасыз. Әйдә бүлектә сайрар, бик тәти егет күренә. Әнә шундый йолкышлардан чыга инде җинаять. Гафу итегез, мин җинаять эшләмәдем, дигән була бит әле.

Мансаф нинди генә дәлилләр китермәсен, ничек кенә аңлатмасын, үз-үзен яклардай сүз таба алмады. Ә битараф, гамьсез закон кешеләрен гади авыл егетенең үз-үзен яклый алмавын күреп, шаһитлар юклыгын файдаланып, тикшерүне озакка сузмадылар. Мансаф исә үзеннән бигрәк әти-әнисе өчен янып көйде. Якты дөньяга тудырган газиз кешеләре алдында бер генә гаебе булмаса да, аларга азаккы көннәренә кадәр бетмәс-төкәнмәс кайгы-хәсрәт һәм уллары «кеше үтерүче» мөһере белән яшәячәкләрен уйлап, җаны әрнеде. Әнкәсенең: «Улым, йөрәк парәм, инсафлы, тәртипле, гадел бул дип

исемне дә Мансаф дип куштык», дип иркәләве бүгенгедәй күз алдында.

Мансафны унике елга хөкем иттеләр. Бөтен җиһанны үз кочагына алырдай булып яраткан, изге күңелле, миһербанлы егетнең тормышы чәлпәрәмә килде. Ирексездән Мансафның, Шамил Хәмәдинуровның «Тәкъдир, тәкъдир бәллүр түгел, үтә күренми, әле дә ярый киләчәгем алдан беленми», дигән җыр юллары колагында яңгырагандай булды.

Камера эче акрынлап караңгылана башлады. Кайдандыр ярык юл табып кергән күбәләк тоткынның баш очында очты-очты да, аның вакытыннан алда агарган чал чәчләренә кунды. Тоткын күбәләкне әллә тойды, әллә юк, аны үз иркенә куып тыныч кына ята бирде.

Иртәгәсен тоткынга ашарга алып килгән сакчы аның җансыз гәүдәсенә тап булды. Мансафның эчкә баткан зәңгәр күзләре зур итеп ачылган һәм ул күзләр гүя: «Әй, кешеләр, гаепсез кешеләрнең ләгънәтләреннән, ата-аналарының бәддогасыннан куркыгыз», — дигән кебек иде.



# ӘЛФИС ШАКИРОВ

**Шакиров Әлфис Шартдин улы**

Мин 1950 елда күп балалы гади крестьян гаиләсендә тудым. Әти ветеринария фельдшеры, ә әни — гади колхозчы, әмма дини эшчәнлеге өчен кулак мөһере тагылган һәм Себергә (Ачинск шәһәре) җибәрелгән указлы мулла Сәләмов Зиязетдин кызы буларак, Коръәнгә табынып, Шәригать законнары буенча яши. Кече яшьтән үк безне әти-әниләребез укырга өйрәтте һәм бөтен көчләрен балалары белемле булуга юнәлтте. Чакмагыш районының Рапат авылында яшәүче олы апамның агроном, тагын ике апам һәм абыемның табип булып эшләве, ә энем Әлфир Шартдин улының әле дә Карман урта мәктәбендә укытуы һәм аның БРның атказанган укытучысы булуы — шуның ачык мисалы.

Мин күп балалы гаиләдә туып үскәнем өчен бик шат, чөнки төрле вакытта һәм шартларда аларның игътибарына һәм ярдәменә ышана алам. Урта мәктәпне тәмамлагач, үземнең хезмәт юлын 1968 елда Яңавыл районының «Заря коммунизма» гәзитендә әдәби хезмәткәр буларак башладым, анда беренче көннәрдән үк үземнең иҗади

остазларым Әсхәт Нигъмәтҗан улы Әхмәтҗанов, Мәгади Хуҗин, Рэвил Исламшин белән таныштым, алар минем хәтеремдә мәңге саклаa-ныр.

Район гәзитендә бер ел эшләгәннән соң армия сафларына алындым, анда да журналистика эшчәнлеген «За Родину» гәзитендә хәрби корреспондент буларак дәвам иттем.

Кулга каләм алуыма, күрәсең, минем олы абыем Алберт Шартдин улының яшь чагында яхшы гына шигырьләр, хикәяләр иҗат итүе этәргеч булгандыр. Аңардан, бәлки, яхшы гына журналист чыгар иде, әмма ул, апам Зәлилә кебек, икенче юл — медицина юлын сайлады һәм чын табиб булды. Армиядән соң мин Карман ГРЭСында слесарь булып эшләдем. Ә Краснокама районының «Вперед» гәзите ачылганнан соң 1973 елдан хәбәрче, авыл хуҗалыгы бүлеге мөдире, мөхәррир урынбасары, ә соңыннан исеме алыштырылган «Кама таңнары» татар гәзитендә реклама агенты вазифасын башкардым.

Әлфис Шартдин улының журналист тәҗрибәсе 20 елдан артык. Ул «Вперед», «Красное знамя»,

«Контакт» гәзитләрендә хезмәт салган.

2007 елда Әлфис Шакиров зур булмаган «Ради нескольких строк» китабын бастырып чыгара, ул берничә бүлектән тора. Ул Бөек Ватан сугышының 60 еллыгына багышланган һәм үз эченә журналистлар, табиблар, әдәби тәҗрибәләр турында хикәяләрне алган.

Хәзер исә аның тагын берничә китабы басмага әзерләнә. Моннан тыш, журналист Әлфис Шакиров үткән елны, Николо-Березовка мәчетенең мөхтәсибәте буларак, «Иман Нур» гәзите чыгара башлый. Соңрак ул бу гәзитнең редакторы итеп сайлана, хәзерге вакытта гәзит имам-ахуд Сабирҗан хәзрәт Сәлемгәрәев таләбе буенча өч районга (Краснокама, Калтасы, Янаул) һәм Нефтекамага таратыла.

## САК БУЛЫГЫЗ: БАЛ КОРТЛАРЫ

Бал кортларының кешегә күпме файда китергәнен һәммәбез дә беләләр, ә бөтен дөньяга даны таралган башкорт балы турында риваятьләр яшәп килә. Бал корты үзе дә легендар бөҗәк. Тырыш һәм уңган кешене юкка гына бал кортына тиңләмиләр. Безнең ихатада да берничә бал корты умартасы бар иде. Әти-әниләребез тыныч, җылы кичләрдә корт караганда без аларның эшләвен тын да алмыйча, дөрес, ерактан гына, күзәтә торган идек. Бал кортлары белән шаярырга ярамый — бер генә саксыз хәрәкәт ясасаң да, ул шунда ук сиңа угын кадаячак. Корт чагу файдалы, ә аның агуы бик күп чирләрдән дәвалый дисәләр дә, беребезнең дә ирекле рәвештә корттан чактырасыбыз килми иде. Корт караганда төрле мәрәкәле очраклар да булгалаштырды. Аларның берсе бал суыртканда булды, ә бал кортлары бу вакытта аеруча усаллаша.

Ул елны авылларда мөгезле эре терлекләрнең тоякларын зарарлаучы ящур чире таралды. Аңа каршы көрәшү өчен районга

Мәскәүнең үзеннән (нидидер фәнни-тикшерену институтыннан диделәр), белгечләр килде. Печән җыеп беткәннән соң чираттагы ял көне иде. Әтием, буш вакыты булуыннан файдаланып, умартадагы табышны карарга булды һәм бер уңайдан суыртыр өчен гәрәбәдәй бал белән мичәтләнгән берничә рамны алды. Эшнең иң кызган мәлендә капка алдыбызга колхоз зоотехнигы Шәях абый һәм Мәскәүдән килгән ветеринария табибы, хәтерем ялгышмаса, Аркадий Семенович Ильин килеп туктады. Алар колхозда ветеринария фельдшеры булып эшләүче әтием янына килгәннәр иде. Кунаклар анымоны абайламыйча, атларын бәйләп капканы ачулары булды, ачулы бал кортлары аларга ябырылды. Шул чакта мәхшәр купмасынмы! Кыска җиңле җәйге күлмәк кигән бахыр Аркадий Семенович баскан урынында сикерде һәм ферма ягына чапты, аның янында яңгыр сулары җыелып яткан, үрдәк-казлар йөзеп йөргән бәләкәй генә күл бар иде. Бал кортлары чагуыннан акылдан язган кунагыбыз киемение белән күлнең болганчык суына сикерде һәм, тын алу өчен вакыт-

вакыт кына башын калкытып, бер сәгатьләп әлеге зур күлләвектә ятты. «Һава башкисәрләренең» һөҗүме туктаганына инангач кына Аркадий Семенович үзенең ышанычлы «бассейныннан» чыкты һәм кичкә кадәр тигәнәк арасында ятты. Урындагы начальство урнаштырган фатирына ул эңгер-меңгер төшкәч кенә кайта алды. Хуҗабикә Нәсимә апа, үзенә фатирга куелган кешене шундый хәлдә күргәч, ушын җуеп егыла язган, диләр. Ә эшнең нәрсәдә икәнлеген белгәч, ул шунда ук мунча ягып җибәргән һәм үләннәрдән төрле төнәтмәләр, мазьләр ясаган. Ә ат һәм зоотехник Шәяхабый нәрсә эшләгән соң? Аларга бит кортлар шулай ук котырынып ябырылган. Кортлар холкын яхшы белгән Шәях абый тиз генә атын тугарып, аңа атланып чапкан. Ул үзе дә, аты да кортлардан артык зыян күрмәгән. Бу хәлдән соң, өйдә иртәгәге көнне көтүдән авыр тынлык урнашты. Бөтенебез дә, әтиебезне алда күңелсезлекләр көтәдер, дип уйладык. Бәхеткә, барысы да яхшы тәмамланды. Аркадий Семенович яхшы күңелле һәм шаян кеше булып чыкты. Ул колхоз идарәсендә әтигә бармак белән янау

һәм «Абзый, киләчәктә капкагызга: «Сак булыгыз: усал бал кортлары!» — дигән элмә такта куегыз» — дию белән генә чикләнгән. Озакламый Ильин Мәскәүгә кайтып китте, әнием аңа юлга кучтәнәчкә өч литрлы банка белән бал бирде.

Бер ел диярлек вакыт үтте. Ә бер көнне хат ташучы безгә Мәскәүдән Ильиннан хат китерде. Аркадий Семенович хатында былтыргы хәлләр турында шаяртып язган, һәм бал, иң мөһиме, корт чаккан өчен рәхмәт әйткән иде. Корт чагу аңа файдага киткән икән: ул үзен инде берничә ел бимазалаган радикулиттан һәм аяклары авыртудан котылган. Менә шулай да була! Бәхет көтмәгәндә елмаеп куя.

## СӘҮДӘ ИТҮ — БУРЛЫК ТҮГЕЛ
### Юмореска

Бакча күршебез ел эчендә бөтенләй башка булды да куйды, әлегечә әйткәндә, «текәләнде». Хәтта атлап йөреше дә үзгәрде. Элек безнең участокка киңәшләшергә, кайда нәрсәне арзанрак хакка сатып алырга мөмкин булу турында белешергә еш керә торган иде.

Хәзер исә безнең Гошаны, дөресрәге, Георгий Платоновичны таный торган да түгел.

Чынлап та үзгәрешләр күзгә ташлана. Әгәр элек ул бишекле иске мотоциклында йөрсә һәм «Прима» тәмәкесе тартса, хәзер исә ул унынчы модельле «Жигули» да җилдерә, модага ярашлы һәм иминлек билгесе итеп миңа таныш булмаган токымлы йөнтәс эт асрый. Минем сәламләвемә ул башын гына селки һәм демонстратив рәвештә артын бора. Хәзер аңардан элеккечә тәмәке дә «сугып» булмый.

Бервакыт мин аңардан үз итеп:

— Гоша, тәмәкең юкмы? Минеке беткән иде. Икенче көн инде изаланам, — дип сорадым.

— Мин сиңа нинди Гоша булыйм, — диде күрше кистереп. Шуңа күрә тәмәке шунда ук онытылды. Бу очрактан соң берничә көн узгач, мин арзан тәмәке алырга шәһәр базарына кердем. Бәй! Кемне күрәм! Безнең Гоша, гафу итегез, Георгий Платонович, палаткада сәүдә итә. Юкса, вак-төяк белән генә дә түгел, кыйммәтле туннар белән. Шунда миңа да барып җитте: акча һәм власть кешене һәрвакыт үзгәртә шул. Бу очрактан соң мин

тирән уйга калдым: «Ике сүз бәйли алмаган күршемнән ни җирем ким соң? Бәлки, миңа да үз эшемне ачаргадыр? Өметсез — шайтан, ди. Өстәвенә кайчандыр элек ишеткән «сәүдә итү — бурлык түгел», — дигән сүзләр дә исемә төште.

Үз эшемне мин корт балы сатудан башларга булдым. Процентын арттырып түләү шарты белән бурычка акча алып, күрше районнан арзанракка бал юнәттем. Бездә базарда «әре» чыгарып булмаячагын белеп, апам яшәгән Екатеринбургка барырга карар иттем.

Бер атнадан шимбә көнне мин Екатеринбург базарында басып тора идем инде. Биредә тиешле булганча балга анализ ясадылар һәм миңа «Башкортстаннан килгән чәчәк балы, экологик яктан чиста», — дигән кәгазь бирделәр.

Кызганычка каршы, сатучыларның берсе дә бу кәгазьгә игътибар итмәде, барысы да балны янәшәдә сәүдә итүче һәм «шифалы Ташкент балы», — дип кычкырып торучы үткер хатыннан сатып алырга тырышты.

Минем умартачылыкта бераз тәҗрибәм бар һәм Үзбәкстанда мамык балы гына булганын беләм. Ул нинди шифалы булсын инде.

Икенчедән, майда Үзбәкстанда яңа суыртылган бал булмый. Бу шикләрем белән мин янәшәдә торган үзбәк хатыны белән уртаклаштым, ул минем якташым булып чыкты һәм саф татар телендә болай дип пышылдады:

— Тик тор, юкса сатып алучыларымны куркытырсың. Ә мин сине «Ташкент балы» әзерләргә өйрәтермен. Авызга су кабарга туры килде. Аның каравы, «фирма серен» белдем. Барысы да гади икән: балны талгын утта бераз җылыту гына таләп ителә.

Икенче көнне мин иртән иртүк башыма түбәтәй киеп (аны шунда ук базарда сатып алдым) бугазымны киереп:

— Ташкент балы, шифалы, яңа гына бал суырткычтан! Алып калыгыз — отылмассыз! — дип кычкырып басып тора идем инде.

Ике сәгатьтә савытым бушады, ә кесәмдә шактый гына «әре» җыелды. Бу акчага товар сатып алдым һәм кич вокзалга юнәлдем. Бу товарларны саткач, тагын «Ташкент балы» сатып алырмын да яңадан Екатеринбургка китәрмен. Иң мөһиме — товарны мактый белү, һәм эш барачак. Бәлки, мин дә унынчы

модель машина алып утырырмын һәм күршемнең борынына чиртермен. Сатып алучыга килгәндә, аның эше акчасын бирү, ә безнең эш — аны «Ташкент балы» белән тәэмин итү.

## ЭЧТӘЛЕК


ФӘРИТ СУФИЯРОВ . . . . . . . . . 9
Илгә булган сөюем . . . . . . . . . 12
Җырлар калсын . . . . . . . . . . . 13
Өлгерергә кирәк . . . . . . . . . . 14
Заман шаукымы . . . . . . . . . . 15
Шөкер итәм . . . . . . . . . . . . . 16
Барысы да кирәк кешегә . . . . . 17
Моң чишмәсе тынмас . . . . . . . 18
Мөмкин булса . . . . . . . . . . . . 20
Дала моңы . . . . . . . . . . . . . . 21
Елмаюың калсын . . . . . . . . . . 22
Вакыт сагында тора . . . . . . . . 23
Дусларым табын кора . . . . . . . 24
Дөнья чикләре . . . . . . . . . . . . 25
Бер син генә түгел . . . . . . . . . 26
Соңгы юлга озата . . . . . . . . . 27
Хәерниса әби кызы . . . . . . . . 28

ГӨЛ МИРҺАДИ . . . . . . . . . . . 29
Белсәң икән . . . . . . . . . . . . . 31
Үткәннәр . . . . . . . . . . . . . . . 33
Бәлки . . . . . . . . . . . . . . . . . 34
Озын . . . . . . . . . . . . . . . . . 36
Гомер үтә ике арада . . . . . . . . 37
Сагындым, сагындым . . . . . . . 40

НӘФИСӘ ХӘБИБДИЯРОВА . . 41
Былтыргы кар . . . . . . . . . . . . 45
Сөю калыр . . . . . . . . . . . . . . 46
Гафу үтенсәң . . . . . . . . . . . . 47
Танымадың . . . . . . . . . . . . . . 48

Алдатма, яз . . . . . . . . . . . . . . . . 49
Җәйнең соңгы сулышы . . . . . . . . 50
Күз кочагы . . . . . . . . . . . . . . . . 51
Буран күткәндә . . . . . . . . . . . . . . 52
Наз бит үземдә . . . . . . . . . . . . . . 53

КАҺИМ ӘҮХӘТОВ . . . . . . . . . . 54
Сыныйлар . . . . . . . . . . . . . . . . . 56
Мин синнән канәгать, язмышым . 57
Улыма . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 58
Күтүче . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 59
Гомерем буе мин кызыгып йөрдем 60
Иске гадәт . . . . . . . . . . . . . . . . 61
И, гөлләрем . . . . . . . . . . . . . . . 62
Пенсиягә мәдхия . . . . . . . . . . . 63
Галстук турында . . . . . . . . . . . 64
Арыш басулары . . . . . . . . . . . . 65

ФӘНИЛ МИҢНЕГАЛИЕВ . . . 66
Әй, мөкатдәс туган ягым . . . . . 70
Кайтам әле . . . . . . . . . . . . . . . . 72
Рәхмәт, әнкәй! . . . . . . . . . . . . . 74
Шагыйрьләрне күктән төшкән, диләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 75
Буйладым иген кырларын . . . 77
Вакыт чаба, гомер ага . . . . . . 78
Баланнар . . . . . . . . . . . . . . . . . 79

АЛИЯ ХАЙРУЛЛИНА . . . . . . . 80
Бораема — туган ягыма . . . . . 83
Әллә картаямы еллар да . . . . . . 84
Могҗизалар бардыр, ышансаң . . 85
Әйләнә дөньялар . . . . . . . . . . . 86

Сагышлардан юк шул чаралар . . 87
Коела кызыл миләшләр . . . . . 89
Язны көткәндә . . . . . . . . . . . 90
Картаймасын бары күңелләр . . . 91

ГӨЛСИМӘ ЗИННӘТУЛЛИНА 92
Шалашта да яшәү оҗмах, диләр . . 96
Гаиләң бар, димәк син бәхетле . . 97
Тормыш арбасында . . . . . . . . 98
Аерылу сагышы . . . . . . . . . . 99
Йөрәк бәйге аты . . . . . . . . . . 100
Язмышларның кулы каты . . . . 101
Дуслар кулы кирәк . . . . . . . . . 102
Сез кайдасыз,
яшьлек дусларым . . . . . . . . . . 103

РӘФИС
МӨХӘММӘТДИНОВ . . . . . 104
Кояш нурым син . . . . . . . . . . 106
Кайтам . . . . . . . . . . . . . . . . . 107
Көзге җилләргә . . . . . . . . . . . 108
Аклык кочагында . . . . . . . . . 109
Сагындыра . . . . . . . . . . . . . . 110
Күңел көзем . . . . . . . . . . . . . 111
Ямьле ай . . . . . . . . . . . . . . . . 112
Көрәшәм . . . . . . . . . . . . . . . . 113
Моңсуланмыйк . . . . . . . . . . . 114
Авылда туй . . . . . . . . . . . . . . 115

ИНСИЯ МУХАНОВА . . . . . . 116
Гомерләрнең үтүе . . . . . . . . . . 118
Төрләндердем . . . . . . . . . . . . 120
Оныкларым – минем шатлыгым . 121

Солдат егеткә . . . . . . . . . . . . . . 122
Сугыш яралары күңелдә . . . . . 123
Улыбыз хезмәткә бара . . . . . . . 124
Рәнҗетмәгез аналарны . . . . . . 125

ДАМИР ХӘЙРТДИНОВ . . . . 126
Реклама . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 129
Бензин . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 130
Маймыл әйтте кешегә . . . . . . . 131
Их, бөлгенлек, бөлгенлек . . . . 132
Журналист хатасы . . . . . . . . . . 133

ӘДИС ЗИННӘТУЛЛИН . . . . 135
Авылыма . . . . . . . . . . . . . . . . . . 139
Әтиемне искә алам . . . . . . . . . 140
Егетлек бит яшьтә түгел . . . . . 141
Нефтекамам . . . . . . . . . . . . . . . 142
Кызгану . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 143
Теләгем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 144
Сандугачым . . . . . . . . . . . . . . . . 145
Күңелем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 146
Яшьлек нуры . . . . . . . . . . . . . . . 147

НАҖИЯ БАСЫЙРОВА . . . . . 148
Туган як . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 150
«Замандаш»ка . . . . . . . . . . . . . . 151
Миләш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 152
Ташландык йорт . . . . . . . . . . . . 153
Мин таш инде . . . . . . . . . . . . . . 154
Өйрәттең, дисең, балам . . . . . . 155
Минем кояш . . . . . . . . . . . . . . . 156
Тукай — Кояш, Тукай — Җир шары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 157

МӘСҮФӘ ӘЮПОВА . . . . . . . . . 159
Кара мунча . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 161
Чүп шигырь һәм чын шигырь . . . 162
Гомер юлым . . . . . . . . . . . . . . . . . 163
Кызыл күлмәкле балачагым . . . . 164
Өч таган . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 165

ТАҺИР МИНГАЛИН . . . . . . . 167
Кодашым (җыр) . . . . . . . . . . . . . 171
Күзләрең (җыр) . . . . . . . . . . . . . 173
Краснокама җирендә (җыр) . . 175

КАМИЛ ГӘРӘЕВ . . . . . . . . . . 176
Әбине талаганнар . . . . . . . . . . . 178
Кем ул? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 182
Шәфкатьле Жулик . . . . . . . . . . . 185

АИДА ХӘЙРТДИНОВА . . . . 188
Сугышны үткән. Новелла . . . . . 190

РИМА КАҺАРМАН . . . . . . . . 196
Ерак сәфәр мажаралары . . . . . 198

ФИРҮЗӘ ИБАТУЛЛИНА . . . 217
Кайту . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 219
Мыштым Сәрби . . . . . . . . . . . . . 232
Тәкъдир бәллүр түгел, үтә
күренми . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 253

ӘЛФИС ШАКИРОВ . . . . . . . . 274
Сак булыгыз: бал кортлары . . . 278
Сәүдә итү — бурлык түгел.
Юмореска . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 281

*Литературно-художественное издание*

**СУФИЯРОВ** Фарит Суфиярович

Серебряный звон родников
Литературный сборник
На татарском языке

Басарга кул куелды 15.04.2013. Кәгазь форматы 84x100 $^{1}/_{32}$.
Шартлы басма табагы 12,6. Тиражы 400 данә. Заказ № 17.
Башкортстан Республикасының «Матбугат дөньясы»
нәшрияты казна предприятиесында басылды.
450076, Уфа шәһәре, Аксаков урамы, 45.
Телефон 8 (347) 251-72-95.